PRESSA.RU

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№5 (293) – МАЙ 2016

# ТАТАРСТАН

1920 елдан нәшер ителә

«Заречье» җәйгә әзерләнә

Фронт хатлары – сугыш еллары фаҗигасе көзгесе

Болгар иленең үзәк мәчете

# ТЫНЫЧЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

PRESSA.RU

16+

**Редакция:**
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

**Баш мөхәррир:** Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
**Шеф-редактор:** Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
**Баш мөхәррир урынбасарлары:**
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Рөстәм Шакиров
**Чыгарылыш мөхәррире:**
Фәридә Әхмәтҗанова
**Бүлек мөхәррирләре:**
Владимир Матылицкий
Татьяна Колчина
Ольга Туманская
Линар Закиров
**Әдәби мөхәррир:** Луиза Янсуар
**Веб-редактор:** Олеся Бондаревская, bond@tatmedia.com
**Авторлар:** Хәмидә Гарипова, Айсылу Хаҗиева, Фаяз Хуҗин
**Фотографлар:** Ната Смирнова, Александр Эшкинин
**Дизайн-макет:** Леонид Гобәйдуллин
**Вёрстка:** Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
**Препресс:** Игорь Глушков
**Корректор:** Айсылу Корманова
**Офис-менеджер:** Ләйсән Әхмәрова
**Тышлыктагы фото:** Александр Эшкинин

**Журнал 1920 елдан нәшер ителә**

1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ №ФС77-37630, 01.10.2009.

**Тираж:** **3500** данә,
шул исәптән татар телендә – 1100.

**Бәясе ирекле**

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**:

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-1156

Басарга кул куелды: 18.05.2016

**Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:**
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
**Коммерция директоры:**
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76
**Коммерция директоры урынбасары:**
Айваз Диндаров, aivazid@tatmedia.com
**Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:**
Юлия Фәсәхова, тел. (843) 222-06-05
**Махсус проектлар бүлеге белгече:**
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
**Бухгалтерия:**
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

# ТЫНЫЧ КҮК СЕЗОНЫ

Май бәйрәмнәргә, ялларга бай ай, шулай ук ул һәртөрле сезоннарны ачып җибәрү вакыты да – дача, шашлык, су коену сезоннарын... Май сезоннары арасында күңелгә ятышсызы берәү генә – талпанлысы. Шуңа бу хакта артык тирәнгә кереп сөйләп тормыйк. Тешләшүчеләрне Ходай хөкеменә тапшырыйк та табигать матурлыгына күмелик: сирень чәчкәләренә, шомырт исләренә, сап-сары башлы тузганакларның купшылыгына... Бары май гына безгә барысын да һәм берьюлы бүләк итә – рәхәтләнеп иснә, соклан, кагылып кара һәм бу зиннәтнең айга бер тапкыр гына булуын ваемлап, рәхәтен татып калырга ашык. Табигать, күрәсең, 45нче елгы Җиңү яулап алынган сезонны да хәтерендә саклыйдыр – һәм һәр елны безгә бу матурлыкны баш өстебездәге тыныч күк йөзе белән бергә бүләк итә. Ул безгә шуңа да аеруча кадерле. Шулай була гына күрсен. Һәрвакыт. Чөнки тыныч күк йөзе – безгә җиңүчеләрдән калган май васыяте.

**СЕЗНЕҢ МАЙ РЕДАКЦИЯСЕ**

**Редакция советы:**
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла**

**«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә**
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
**892 сум 32 тиен**




Фото Әлмәт районы администрациясе сайтыннан алынды

# ЭЧТӘЛЕК

## АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

**4. «Заречье» яңарыш кичерә.**
Балаларыбыз кайда ял итәр

**8. Тормыш химиясе.**
Минераль ашламалар житештерү буенча иң заманча производствоны ничек төзеделәр

**16 Миллионер студент.**
Уңышка ирешүнең серләре нинди

## ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

**20 Җиңү каһарманнары.**
Бөек Ватан сугышы ветераннары безгә нәрсә васыять итә

**24 Күңел көрлеген җуймаган ветеран.**
91 яшендә парашюттан сикергән ветеран кайда яши

**28 Фронт хатлары.**
Тере шаһитлар ни хакында сөйли

**32 Сугыш кичкән соңгы татар язучысы.**
Без белмәгән кырыс чынбарлык

## МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

**38 Татар халык ашлары.**
Иң тәмле кыстыбыйны кайда пешерәләр

**42 Археологик казыну нәтиҗәләре.**
Биләр туфрагында сакланып калган Җәмигъ мәчете хәрабәләре турынданиләр беләбез

**50 «Соңгы кыңгырау» уңаеннан уйланулар.**
Бүген мәктәптә намус белән укыту мөмкинме

**54 «Кече ватан патриотлары».**
Маршрутның беренче тукталышы

**58 «Татар театрының атасы».**
Г.Кариев татар театрын нинди итеп күрергә теләгән

**62 Күз яшьләре аша елмаю.**
Татарның беренче Алтынчәче

**66 Китап киштәсе.**
Без сугышны каян белеп үстек

**69 Алексеевск районы**

**70 Тукучылар, игенчеләр... һәм бадминтончылар ягы**

PRESSA.RU

## АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

## 22.04

**Владимир Путин, РФ Президенты, – Казанда дзюдо буенча Европа чемпионатын ачканда:**

«Казанга һәм Татарстанга әлеге спорт бәйрәмен оештырган өчен аерым рәхмәт сүзләре. Монда спортның нәрсә икәнен беләләр, аны яраталар һәм мондый масштабтагы чараларны оештыра алалар».

## ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘР

## 17.04

**Мэттью Андерсон, Казанның «Зенит» клубы волейболчысы, – Чемпионнар лигасы финалындагы җиңүдән соң:**

«Бу команда Чемпионнар лигасында җиңде, бу команда Россия Кубогын, чемпионатны һәм Суперкубокны отты – боларны санарга уйласагыз дип әйтүем. Без һәр ярышта диярлек җиңә килдек һәм шушы дәрәҗәдә чыгыш ясарга әзер идек, ләкин бу җиңел түгел – безне җиңәргә теләүчеләр күп. Яхшырак булу уен саен кыенлаша бара».

## МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

## 26.04

**Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга:**

«Төрле мәдәни традицияләрне югары шигърият күперләре белән тоташтырып, Тукай төрле милләт һәм дин кешеләрен тынычлыкка, дустанә күршелеккә һәм хезмәттәшлеккә өндәп, Россиягә һәм бөтен дөньяга татар рухының байлыгын ачып бирә алды».

# АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

**БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:**

«Заречье» **НИНДИ** яңарыш кичерә

Бөек химик революция **КАЙДА** бара

**НИЧЕК** миллионер булырга

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Мәктәп һәм балалар бакчаларын капиталь ремонтлау Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау Спорт мәйданчыклары төзү «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау **Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү** Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Модуль-блоклы ветеринария пунктлары төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Сыер абзарларын капиталь ремонтлау Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

**ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ. НӘТИҖӘЛӘР**

# ГИМН ЯРАТТЫРУЧЫ ЛАГЕРЬ

**Автор:** Линар Закиров

Совет чорында ил гимнын белмәгән бала-чага сирәк булган. Бүген хәл алай ук шатлыклы түгел. Шулай да Казанның «Заречье» лагеренда ял иткән балалар, гимнны белмичә килсәләр дә, 18 көнлек сменадан соң, иртәләрен Россия һәм Татарстанның тантаналы җырларыннан башлыйлар икән. Әти-әниләре исә: «Нишләттегез безнең балаларны?» – дип шакката, ди.

Фото: Ната Смирнова



## «АЧЫК ҺАВАДАГЫ БАССЕЙН КҮП МӘШӘКАТЬ ТУДЫРАЧАК»

Баксаң, моның сере бик гади. Лагерь башлыгы Константин Крайнов сөйләвенчә, нинди генә юнәлеш булмасын – җырмы ул, спортмы – беренче көнне үк, балаларны җыеп, ил һәм республика гимннарын җырлаталар.

– Бездә ял итүче балаларның 40–60 проценты бирегә ел саен килә, шуңа да лагерь тәртипләре белән яхшы таныш. Әтиәниләрнең: «Балам иртә таңнан гимн җырлый», – дип әйтүе, бер караганда, көлкедер, икенче яктан караганда, эшнең нәтиҗәсен ишетү, күрү – рәхәт, – ди Константин.

1963 елда бу урында – «Спартак», ә 1979 елда «Светлячок» лагерьлары оешкан. 80нче еллар ахырында икесен берләштереп, «Заречье» барлыкка килгән. Бүген ул үз кочагына берьюлы 400 баланы сыйдыра ала.

Константин белән лагерьны күздән кичереп йөрибез. Бермәл муеннарына кызыл галстук бәйләгән һәм кулларына шундый ук төстәге әләм тоткан малай белән кыз сынына күзем төште.

– Заманында бу урында линейкалар узган. Сынны ел да буйыйбыз, быел җитешмәдек әле. Монда ачык һавада бассейн да булган. Балалар анда барып җәрәхәтләнә күрмәсен өчен, тирә-ягын читән белән әйләндереп алдык. Хәзерге вакытта мондый бассейнны тоту бик мәшәкатьле булыр, ачык һавада булганга, суы да гел пычранып торыр иде. Бассейн була калса, әйдәманнарның җаваплылыгы да арта, дигән сүз, – дип сөйли әңгәмәдәшем.

PRESSA.RU





### «ДИҢГЕЗГӘ ИСЛӘРЕ КИТМИ»

2012 елда баштанаяк төзекләндерелгән беренче корпуска кердек. Ремонтка чаклы бинада бер генә бәдрәф белән душ булса, хәзер – бүлмә саен. Санитар нормалар һәм кагыйдәләр буенча бер балага 4 квадрат метр туры килергә тиеш, шуңа да һәр бүлмәдә 6–10 кеше яши.

Константин Крайнов «Заречье»да бер елдан артык эшли, башка лагерьларда да үзен әйдәман буларак сынаганы бар. Балачакта Казанда да, көньякта да ял иткән.

– Студент чакта «Заречье»да еш була идем. 2006–2007 елда мин яшәгән икенче корпуста агач тәрәзәләр тора, кайнар су килми иде. Ә икенче корпуска, торышы бик начар булганга, якын да килергә курка идек. 10–15 ел дәвамында лагерь башлыгы булып эшләүчеләр белән очрашсак, үзгәрешләр турында хәйран калып сөйләшәбез. Барлык җиһазлар яңартыла, проблемалар хәл ителә. Чит өлкәләрдән килүчеләр, бездәге шартларны күреп таң калалар. Ышандырып әйтә алам, бу Татарстанда гына шулай. Республика программасыннан кала, ел саен һәр лагерьны төзекләндерүгә бер миллион сум бирелә. Шәһәр читендәге сәламәтләндерү лагерьларына ихтыяҗ елдан-ел арта. Ата-аналарның көньяктагы диңгезгә элеккеге сыман исе китми, балаларын үзебездәге лагерьларга ышанып җибәрәләр, – ди Константин Крайнов.

### ЛАГЕРЬДА НӘРСӘНЕ АЕРУЧА ЕШ АЛЫШТЫРАЛАР?

Сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү кысаларында «Заречье»да 25 миллион сумга ике катлы өр-яңа ашханә төзиләр, мәйданы – 1185 квадрат метр. Инженерлык челтәрләрен сузу өчен Казан бюджетыннан өстәмә рәвештә 5 миллион сум бүлеп бирелгән. Бинаны гыйнварда сафка бастыра башлаганнар, майның 20ләрендә, алмагач чәчәктә утырган мәлдә, ул файдалануга тапшырылачак. Кагыйдә буенча, 400 балага тугыз аш-су остасы ашарга пешерергә тиеш, тик лагерьда алар, гадәттә, күбрәк – 12 кеше була.

– Совет чорында ашханәдә ике генә кулъюгыч кую рөхсәт ителсә, яңа таләпләр буенча, 25 балага берәү туры килергә тиеш, монда алар 16 булачак. Икенче катта 150 кеше сыярлык актлар залы урнашачак. Ул безгә кирәк, чөнки аерым залыбыз юк. Һава торышы бозылса, чараны шунда үткәреп булачак. Иске ашханәдә салатлар әзерләргә мөмкинлек булмаса, яңасында андый шартлар да тудырыла. Салат цехы өчен таләпләр бик катгый бит: медицина кабинетындагы сыман билгеле бер вакытта дезинфекция үткәрелә, бүлмә ультрашәмәхә лампа белән эшкәртелә, – дип аңлата әңгәмәдәшем.



Лагерьда көнгә биш тапкыр ашаталар. Балаларны кабул итәр алдыннан, лагерь белгечләре, бөтен витаминнарны туры китереп, 18 көнгә меню төзи дә Роспотребнадзорның Татарстан буенча Идарәсенә җибәрә. Уңай җавап алынгач, аш-су осталары шуның буенча балаларның тамагын туйдыра.

Кызык өчен, иске ашханәгә дә сугылдык. Таушалган тышын күргәч: «Саумы, мин телевизордан гына күреп белгән совет чоры», – дип әйтәсе килеп китте. Идәнгә яңа плитка түшәлгән. Бина әллә ни зур булмаганга, балаларны ике-өч төркемгә бүлеп ашатканнар. Әмма бу ашау сыйфатына берничек тә тәэсир итмәгән. Яхшы хәлдәге өстәлләр, җиһазлар яңа ашханәгә күчереләчәк. Ә шушы иске бинаны бүгенге көндә зур популярлык яулаган квест бүлмәсе итеп үзгәртеп корырга ниятләнә.

– Лагерьда нәрсәне аеруча еш алыштырасыз? – дип сорыйм.

– Савыт-сабаны. Бала-чага аны поднос белән күтәреп бара да төшереп җибәрә. Былтыр пружиналы өр-яңа матраслар кайтарттык, быел мендәрләр, юрганнар, урын-җир япмалары алачак-

быз. Бөтен нәрсә вакытында алыштырыла, – дип ышандырды безне Константин.

### БЫЕЛ ПРЕЗИДЕНТ БҮЛӘГЕН СЫНЫЙЛАР

Былтыр «Заречье»да геология буенча республикакүләм олимпиада үткәрелгән. Ачылышына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов килеп, лагерь тирәли йөреп чыккан да юлларга асфальт түшәргә күрсәтмә биргән. Шуңа да быел, яңа сукмакларны сынау өчен, 20 пар ролик белән 6–7 велосипед кайтартканнар, балалар шуларда җилдерәчәк. Воркаут белән шөгыльләнү өчен заманча мәйданчык та урнаштырылган. Волейбол мәйданчыгына яңа ком китертеп, таратасы гына калган. Пейнтбол белән лазертаг өчен дә урын әзерләнә.

– Без кечкенә чакта лагерьларда куркыныч хәлләрне яратып сөйлиләр иде. Хәзерге буын мистикага тартыламы? – дим, балаларны инде биш бармагыдай өйрәнеп бетергән лагерь башлыгына.

– Юк, көне буе чабып арыйлар, дискотекада биергә дә хәлләре калмый диярлек. Әйдәманнар төнлә чиратлашып кизү тора, шуңа күрә лагерьда һәрвакыт тыныч. Кичен табиб балаларны йөреп чыга, температураларын тикшерә, – дип җавап бирә ул.

– Талпаннар тынгысызламыймы соң? – дип төпченуемне дәвам итәм.

– Талпаннарга, тычканнарга каршы дезинфекцияләү үткәрелә. Бер смена балалары өйләренә кайтып киткәч үк, икенче смена килер алдыннан, тирә-якны тулысынча эшкәртәләр. Моннан башка лагерьны ачарга рөхсәт бирмиләр. Мин эшләгән чакта талпаннарның да, тычканнарның да күренгәне булмады, – дип горурланып сөйли Константин Крайнов.

Лагерь уртасында ямь-яшел чирәмдә «чайкалып» торган көймәне күргәч, лагерь башлыгы, аптыраган карашымны сизеп:

– 2015 елда Казанда узган Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты ачылышыннан калган декорацияләрне лагерьларга тараттылар. Безгә шушы көймә һәм башка берничә әйбер туры килде, аларны, матурлык өчен, кече архитектура формасы итеп кулланачакбыз, – дип аңлатты.

«Заречье» һәм башка җәйге сәламәтләндерү лагерьларына 4 июньдә җан керәчәк. Җәй дәвамында биредә 18 көнлек – өч, 7 көнлек ике смена узачак. Теләүчеләр чамадан тыш күп, мисал өчен, 400 кешелек сменага инде 600ләп гариза килгән.

**Илсур Хисмәтуллин, Казанның «Ял» үзәге директоры:**

– Быел Казанның 24 шәһәр яны сәламәтләндерү лагеренда (14е – муниципаль, 10сы – предприятиеләр һәм оешмалар карамагында) 37088 яшь казанлы ял итәчәк, шуларның 27660ы – җәйге чорда. Төрле юнәлештә барлыгы 86 смена оештырылачак. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыра торган «Ял» үзәге карамагында – 12 муниципаль лагерь. 2015 елда шуларның берсе – «Березка» лагеренда ашханәне 16 миллион сумга капиталь төзекләндерделәр. Ул 300 урынга исәпләнгән. Бина авария хәлендә булу сәбәпле, 2014 елда лагерь эшләмичә торды.

«Заречье» – Казандагы иң зур муниципаль лагерь, анда ел саен ике мең бала ял итә. Лагерьны 2013 елдан төзекләндерә башладылар. Башта беренче корпусны, коймаларны, территорияне тәртипкә китерделәр. 2014 елда ике миллион сумга кайнар су челтәрләрен рәтләделәр. 2015 елның җәендә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе нигезендә, 27 миллион сумга тулысынча асфальт юлларны, ял мәйданчыкларын, паркингларны эшләделәр. Шулай итеп, «Заречье» ел әйләнәсе эшли торган лагерьга әйләнеп, анда елына җиде мең бала сәламәтлеген ныгыта алачак.

Моннан тыш, биредә Җиңү көненә, Сабан туена күмәк хореография номерлары әзерләнә. Универсиада вакытында лагерьда мәдәни волонтерлар яшәп, үз чыгышларын әзерләде.

Күпчелек бала һәм ата-аналарның теләкләрен исәпкә алып, җәй көне лагерьларның шактыенда бию сменалары узачак. «Безнең белән бие» сменасында балаларны биергә тәҗрибәле хореографлар, Казан дәүләт мәдәният институты мөгаллимнәре һәм студентлары өйрәтәчәк. Балалар үзләштергән күнекмәләрен дискотекаларда, иҗади чараларда күрсәтә алачак.

«Ново-Юдино» лагеренда быел беренче сыйныфка керәчәк укучылар өчен аерым смена эшләячәк. Анда 8 яшькә кадәрге 50 баланы көтеп калабыз. Сменаның максаты – сабыйларны бер-берсе белән аралашырга өйрәтү һәм мәктәп тормышына әзерләү. Җиде көн эчендә педагоглар, психологлар һәм логопедлар уен формасында сабыйларны көн тәртибенә, коллективта эшләүгә күнегергә, укырга, язарга, рәсем ясарга, әвәләргә өйрәтәчәк.

**Илдус Насыйров, ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының эксплуатацияләү идарәсе башлыгы:**

– Татарстан Төзелеш министрлыгына капиталь төзекләндерү үтмәгән балалар сәламәтләндерү лагерьларын шушы программага кертү турында муниципаль берәмлекләрдән гаризалар күп килә. Бүген республикада 50 лагерь ремонт көтә, моны башкарып чыгу өчен, 700 миллион сум кирәк. Татарстанда барлыгы 75 лагерь исәпләнә.

Быел ремонт шушы балалар лагерьларына барып җитте: «Пионер» (Казан), «Сосенка» (Кукмара районы), «Лесная сказка» (Алабуга районы), «Березка» (Әлмәт районы), «Лесная страна» (Мөслим районы), «Солнышко» (Чистай районы), «Дубки» (Әлки районы), «Чайка» (Тәтеш районы), «Болгар» (Спас районы). Төзекләндерү эшләре 1 июньгә кадәр тәмамланырга тиеш.

Ремонт үткәреләсе лагерьлар берничә принцип һәм шартка нигезләнеп сайлап алына. Беренчесе – программага Татарстанның һәр территориаль зонасыннан лагерь кертелә. Шулай ук аларның ел әйләнәсе эшләү принцибы, күпме баланы кабул итә алуы, уртак финанслау, ягъни республика гына түгел, район җитәкчелегенең дә акча кертү ягыннан кызыксындыру белдерүе исәпкә алына. Быел программа тәмамлана, әмма ТР Төзелеш министрлыгында да, ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында да аның дәвам иттереләчәгенә өмет баглыйлар. Безнең тарафтан тормышка ашырыла торган программа социаль әһәмияткә ия. Балаларыбыз өчен бик мөһим программа бу. Без башкара торган эштән балалар да, аларның әти-әниләре дә канәгать калсын өчен, бөтен көчебезне куябыз.

PRESSA.RU



# БӨЕК ХИМИЯ РЕВОЛЮЦИЯСЕ

**«Аммоний» комплексы – Россиядә совет чорыннан соң сафка бастырылган иң заманча азот минераль ашламалары җитештерүге ул. Карбамид җитештерү җайланмасының куәте – елына 717 мең тонна.**

Автор:
Татьяна Колчина

«Аммоний» комплексының җитештерү мәйданы 42 гектарны били: биредә төп җайланмалар, һәм шулай ук ярдәмче цехлар да урнашкан.

Гаҗәп хәл, әмма «Аммоний» индустриаль гигантка бер дә охшамаган: берничә җайланма нибары 42 гектар җиргә сыеп беткән. Җитештерүне мавыктыргыч дип тә әйтеп булмый – барлык физик-химик процесслар реакторлар эчендә бара. Башка нәрсә таң калдыра: тирә-юньдә кеше күренми – бары тик асфальт юллар, инглиз газоннары һәм кояшта ялтырап торган көмеш төсендәге җайланмалар гына.

### ДӨНЬЯДА ИКЕНЧЕ

Иң күп хезмәткәр – операторлар үзәгендә (егерме бишләп). Биредән торып барлык технологик процесслар белән идарә итәләр, мониторларда аларның барышын вакытында күзәтеп була. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: «Аммоний»ның баш инженеры Эдуард Еремеев миңа комплекс территориясендә бары шул үзәккә генә керергә рөхсәт итте. Цехларга исә предприятие хезмәткәрләренә генә керергә рөхсәт ителә, алар да анда бары ике сәгать була – план буенча җайланмаларны тикшереп чыга.

Комбинатның үзәге – берләштерелгән җитештерү уникаль технологиясе буенча эшли торган аммиак-метанол җайланмасы: зур куәтләр белән «уйнарга» мөмкинлек бирә торган мондый җитештерүләр хәзер дөньяда икәү генә – Татарстанда һәм Малайзиядә. Әмма Малайзиядәге җитештерүнең куәте берничә тапкырга кимрәк – тәүлегенә 200 тонна метанол, «Аммоний» исә 660 тонна җитештерергә сәләтле.

– Ихтыяҗга карап (ә аммиак, шулай ук аңардан җитештерелә торган аммиак селитрасы һәм карбамид та – сезонлы продуктлар), линия йә «аммиак/метанол», йә «аммиак» кына режимында да эшли ала, – дип аңлата Эдуард Еремеев. – Моннан тыш, «аммиак/метанол» режимында куәтләрне үзгәртеп була – аммиакны күбрәк, метанолны азрак җитештереп, яки киресенчә.

### ЗУР УРТАК ПРЕДПРИЯТИЕ

«Аммоний» тарихы безнекеләрнең озак җигеп, аннары бик тиз баруы турындагы әйтемгә күрсәтмә иллюстрация була ала: һәртөрле сөйләшүләр, килешүләр, партнерлар эзләү төзелешнең үзенә караганда вакытны күбрәк алган.

...2006 елда аммиак (ул Россиядә иң популяр ашлама – аммиак селитрасы, азот кислотасы, шулай ук карбамид җитештерү өчен кирәк) җитештерү буенча комбинат төзү мәсьәләсе бигрәк тә кискенләшә. 1989 елда төзелгән «Менделеевсказот» читтән китерелгән аммиак чималында эшли, ягъни үз көндәшләрен баета, аларның бәяләр сәясәтенә тулысынча бәйле була. Һәрвакытта да бердәй булмаган сатып алу бәяләре, транспорт чыгымнары белән бергә, Менделеевскида җитештерелә торган селитраны көндәшлеккә сәләтсезгә чыгара.

2006 елда булачак комплекс өчен үз технологиясен тәкъдим итәргә әзер компанияне эзләү башлана. Нәтиҗәдә лицензиар итеп Даниянең Haldor Topsoe* компаниясе сайлана, чөнки бары тик ул гына аммиак һәм метанолны берләштереп җитештерү технологиясен тәкъдим итә. Төп подрядчы сыйфатында даниялеләр Mitsubishi Heavy Indastries** корпорациясен сайларга киңәш бирә, аның белән партнерлыкта дөньяда аммиак һәм метанол җитештерү буенча берничә предприятие инде төзелгән була.

Башта монтажлауны Россия компанияләренә тапшырырга ниятләсәләр дә, проектның төп кредитчысы «Тышкы икътисадый банк» «башыннан алып ахырына кадәр төзеп бетерүне» күздә тоткан контракт таләп итә. Шуңа күрә мәйданчыкта China National Chemical Engineering Co*** (CNCEC) Кытай дәүләт төзелеш компаниясе вәкилләре пәйда була, чөнки алар инде Mitsubishi Heavy Indastries белән күптәннән һәм уңышлы хезмәттәшлек итә. Сүз уңаеннан, контрактның гомуми бәясендә

* Хальдор Топсе
** Мицубиши Хеви Индастрис
*** Чайна Нешнл Кемикл Инжиниринг Ко

CNCEC хезмәтләре бәясе тәкъдим ителгәннәр арасында иң арзаны булып чыга.

Россиялеләргә инфраструктура өлеше кала: «Карбамид һәм органик синтез продуктлары ФТИ» ААҖ белән килешүгә Mitsubishi Heavy Indastries кайтарткан җиһазларны сертификатлаштыру һәм япон корпорациясе әзерләгән эш документларын Россия норма һәм кагыйдәләренә яраклаштыру кертелә; Татарстанның берничә төзелеш предприятиесе гомумзавод хуҗалыгы объектларын төзү һәм монтажлауда катнаша.

– CNCEC белән контракт бәясе чагыштырмача арзан булуга карамастан, кытайлар иң югары дәрәҗәдәге җитештерү культурасын, армиядәге кебек ныклы дисциплина һәм югары хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәтте, – дип сөйли «Аммоний» ААҖ генераль директоры Сергей Шевченко. Бәйләнерлек бердәнбер нәрсә – аларның кышын эшләмәүләре: декабрьдән февральгә кадәр кытайларның күпчелеге өйләренә кайтып китә, биредә ике мең ярым кешедән өч йөзләбе генә кала иде. Әгәр болай булмаса, комплекс 2014 елда ук файдалануга тапшырылырга мөмкин иде.

#### ТАРТЫЛЫШ НОКТАСЫ

2016 елның 1 гыйнварында «Аммоний» ААҖ «Менделеевсказот» ЯАҖ белән берләштерелә, предприятиедә эшләүчеләр саны 1300 кешегә якынлаша, шулардан 120се – чакырып китерелгән белгечләр, күпчелеге югары белемле.

**«Аммоний» – совет чорыннан соң БДБ территориясендә төзелгән бердәнбер минераль ашлама җитештерүче ул.**

– Татарстандагы техник һәм технологик югары уку йортларында кафедраларның күпчелеге нефть табу һәм нефть эшкәртү буенча белгечләр әзерләү белән шөгыльләнә, – дип аңлата Шевченко. – Ә минераль ашламалар җитештерү буенча хәзергә кадәр бер кафедра да юк. Якын арада ул Түбән Кама химия-технология институтында ачылыр, дип өметләнәбез. Һәрхәлдә, бу мәсьәлә буенча хәзер актив эш алып барыла.

«Аммоний»дагы кадрлар вазгыяте республика өчен яңа түгел: 1989 елда «Менделеевсказот» файдалануга тапшырылганда, аның хезмәткәрләренең 80 процентын читтән – Кирово-Чепецк, Пермь, Башкортостаннан, башка шәһәрләрдән килүчеләр тәшкил итә. Предприятиедән 25 километр ераклыкта урнашкан Менделеевск шәһәрендә яшәүчеләр санын шул экспатлар 18 меңгә җиткерә дә инде: шәһәрдә комбинат хезмәткәрләре һәм аларның гаиләләре өчен шактый үсештәге социаль

«Аммоний» ААҖ генераль директоры Сергей Шевченко һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов булачак комплексның төзелеш мәйданында.

**– Аммиак һәм метанол җитештерә торган Россия предприятиеләре арасында безнеке – экологик яктан иң чисталардан берсе.**

һәм мәдәни инфраструктурага ия тулы бер микрорайон төзелә.

Дәүләт торак фонды акчасына комплекс хезмәткәрләре өчен Менделеевскида 275 фатирлы йорт төзелә, аның ике подъезды чит илләрдән килгән белгечләргә бирелә. Калган фатирлар завод төзелгән чорда символик бәягә арендага бирелә: хезмәткәр бер бүлмәле фатир өчен – 500 сум, ике бүлмәлегә – 800 сум, өч бүлмәлегә 1200 сум түли. Файдалануга тапшырылганнан соң, йортны предприятие сатып ала, һәм хәзер фатирлар белгечләргә социаль ипотека программасы кысаларында бирелә.

### ЙӨКЛӘМӘСЕЗ ГЕНӘ

«Аммоний» – совет чорыннан соң БДБ территориясендә төзелгән бердәнбер минераль ашлама җитештерүче ул. Әмма дөньяда, бигрәк тә Һиндстанда һәм Якын Көнчыгыш илләрендә, мондый комплекслар шактый актив төзелә: җитештерүләргә югары табышны арзан чимал – табигый газ, шулай ук диңгезгә якынлык тәэмин итә, чөнки аларның транспорт һәм логистика чыгымнары булмый диярлек. Европа исә, киресенчә, экологиягә бәйле рәвештә, мондый җитештерүләрне яба. Һәм менә монда урынлы сорау туа: Европа, әйләнә-тирә мохиткә йөкләмәне киметү өчен, мондый җитештерүләрдән котылган вакытта, ни өчен Россия аммиак җитештерү буенча иң куәтле комплекс төзи?

«Аммоний» ААҖ генераль директоры ышандыруынча, моның үз сәбәпләре бар:

– Аммиак һәм метанол җитештерә торган Россия предприятиеләре арасында безнеке – экологик яктан иң чисталардан берсе. Аммиак һәм метанолның берләштерелгән җитештерү схемасы, карбамидны параллель җитештерү белән бергә, асылда калдыксыз җитештерүне тәэмин итә: аммиак җитештерү процессында эшләнгән углерод оксиды һәм двуокисе һавага чыгарылмый, бәлки метанол һәм карбамид җитештерүдә чимал сыйфатында кулланыла.

Предприятиедә сыек калдыклар проблемасы да юк. «ТатНИПИнефть» минераллашкан суларны, алардагы тотрыклы катлам басымын саклау өчен, файдаланылган нефть скважиналарына кертү схемасын эшләгән. Бүген «Аммоний» – Россиядә мондый технология куллана торган бердәнбер аммиак һәм метанол җитештерү предприятиесе; калган барысында да минераллашкан суларны якындагы елгаларга агызалар. Якын Көнчыгыштагы предприятиеләр исә пычрак суларын йә чүлгә, йә океанга агыза. Басым ясап шуны әйтергә кирәктер: бу тулысынча – безнең инициатива, лицензиар да, подрядчылар да экологиягә кагылышлы беринди таләп тә куймаган иде.

Шевченко әйтүенчә, экологиягә кагылышлы карарлар төзелешнең бәясен арттырмаган: әлеге максатларга берничә йөз миллион сум тотылып, шулардан 500 миллион сумы федераль Табигый байлыклар һәм экология министрлыгы бюджетыннан «Тышкы икътисадый банк» кредиты буенча процент ставкасының бер өлешен субсидияләштерү юлы белән бүленгән.

### ГАДӘТ КӨЧЕ

«Тышкы икътисадый банк» комплекс төзелешенә биргән тулаем кредит чит ил консорциумы өлешендә 1,06 миллиард долларга һәм Россия подрядчысы өлешендә 325 миллион долларга тәңгәл. Төп җитештерүләрне комплексның рәсми ачылышыннан (ул февральдә ачылды) ярты елга алданрак эшләтеп җибәрү һәм шул вакыт эчендә тупланган керем күләме (4,7 миллиард сум) компаниягә кредитны вакытыннан бер елга иртәрәк түләп бетерү мөмкинлеге бирә: банк килешүе буенча, «Аммоний» беренче траншын 2016 елның дүртенче кварталында күчерергә тиеш.

Беренче ярты елда ук графикны узарга предприятиегә дөнья базарындагы вазгыять һәм Россия аграрийларының азотлы ашлама урынына карбамид түгел, аммиак селитрасы куллану гадәте ярдәм иткән. Соңгысы карбамидтан арзанрак, әмма анда азот та кимрәк, шунлыктан тәэсир итә торган матдәгә күчереп исәпләгәндә аларның бәяләре тигезләнә диярлек. Өстәвенә, бездәге авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре, АКШ аграрийлары белән чагыштырганда, азотлы ашламаларны кимрәк күләмдә сатып ала. Бездә бер гектар чәчүлек җиренә уртача 40 килограмм, Европа һәм АКШта исә 130–140 килограмм тәэсир итә торган матдә кертелә. Һәм алар моны «сәнгатькә мәхәббәт» йөзеннән эшләми.

Шунлыктан «Аммоний» кеременең иң зур өлешен экспортка карбамид чыгару тәэмин иткән, ул чит ил кырларыннан аммиак селитрасын тулысынча кысрыклап чыгара язган. Ә якын киләчәктә экспертлар азот төркеме ашламаларына ихтыяҗның ел саен бер миллион тоннага арта барачагын фаразлый (тәэсир итә торган матдәгә күчереп исәпләгәндә). Сәбәпләрнең берсе – Көнчыгыш Европа, Үзәк, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Азия илләрендә ашлама куллануның һаман арта баруы.

Дөнья базарында ихтыяҗның арта баруы яңа предприятиенең ашламаны сату буенча проблемалары булмас, дигән ышаныч тудыра (һәрхәлдә, якын киләчәктә). Ә бу инде, үз чиратында, валюта кредитын түләүдә кыенлыклар килеп чыкмас, дигән артык зур булмаган ышанычны уята. Төп чимал – табигый газ бәяләренә

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!

«Аммонийда» җитештерү процессларының барысы да тулысынча автоматлаштырылган.

4. Комплексны аякка бастыруда 2,5 меңнән артык чит ил белгече катнашты.

**– CNCEC белән контракт бәясе чагыштырмача арзан булуга карамастан, кытайлар иң югары дәрәҗәдәге җитештерү культурасын, армиядәге кебек ныклы дисциплина һәм югары хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәтте.**

бәйле рәвештә карбамидка дөнья бәяләре соңгы дүрт елда тоннасына 500 доллардан (кайвакытта әле 600 дә) 200 долларга төшсә дә, хәлләр өметсез түгел. Энергия чыгымнарының шактый киметелгән булуы да комплексның өстәмә табышлылыгын тәэмин итә: куптәннән эшләгән предприятиеләрдә энергия сыешлык бер тонна аммиак җитештерүгә 10–12 гКал тәшкил итсә, Haldor Topsoe берләштерелгән җитештерү технологиясе әлеге күрсәткечне 7,5 гКал га калдырырга мөмкинлек биргән.

...Хәзерге вакытта республика һәм компания җитәкчелеге шул ук күләм, технология һәм подрядчылар белән тагын бер нәкъ шундый комплекс төзү мәсьәләсен күтәрә. Бары тик финансларга бәйле кыенлыклар ул гамәлгә кертелгәндә пәйда булырга мөмкин: «Аммоний» янәшәсенә куярлык зур инвестпроектларга кредит бирүче Россия банкларының күпчелеге көнбатыш финанс институтларында Көнбатыш чикләүләре кертелгәнчегә кадәрге дәрәҗәдә фондка теркәлә алмый.

– Японнардан турыдан-туры кредит алу варианты тикшерелә, – дип сөйли Шевченко. – Әмма бу очракта кредитны тәэмин итү проблемасы пәйда була – кредит түләп бетергәнчегә кадәр комплексның бөтен мөлкәте «Тышкы икътисадый банкта» залогта санала. Комплексның икенче чиратын төзүгә кредит турыдан-туры республика гарантиясенә алынырга да бик мөмкин. Биредә проектлау офислары калган японнар да, әле тулысынча демобилизацияләнмәгән һәм үз шәһәрчекләрен сүтмәгән кытайлар да төзелешне башларга әзер. Шунлыктан, без финанслау схемасын төзеп бетерүгә үк, төзелеш башланачак – бу инде якын киләчәктә үк булыр, дип өметләнәм.

PRESSA.RU



# «ТҮБӘН КАМА НЕФТЕХИМ»: БАРЫСЫ ДА ФӘН БУЕНЧА

**«Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыятенә (ГАҖ) җитештерүнең фәннилеге һәм инновациялелеге күптәннән генә түгел, бәлки аның төзелгән вакытыннан бирле хас. Шунлыктан «Түбән Кама Нефтехим» оештырган чираттагы, ягъни тугызынчы «Нефть химиясе инновацион үсешенең хәзерге халәте һәм перспективалары» халыкара фәнни-гамәли конференциясенең компаниянең бөтен инновацияләре йөрәге саналган Фәнни-технологик үзәкнең 50 еллыгы билгесе астында үтүе бер дә очраклы түгел.**

Предприятиенең технологик кораллану динамикасын бәяләү шактый гади. Һәрхәлдә, конференциядә чыгыш ясаучылар моны «Түбән Кама Нефтехим» (ТКНХ) җитештерүләренә карата күп мисалларда күрсәтте. Әйтик, төп җиһаз берәмлекләре саны нибары өч тапкыр арткан чакта бутилкаучук чыгаруның алты тапкыр артуы, алар сүзләренчә, тик бер нәрсәне аңлата: яңа җиһазлар монтажлау белән бер үк вакытта технология дә камилләштерелгән.

Мондый үсешкә юнәлгәнлек ТКНХ-да корпоратив стратегиянең төп элементы сыйфатында кабул ителә. Бераз артка борылып караганда исә, синтетик каучук, пластик һәм мономерларның яңа җитештерүләре биредә соңгы унъеллыкта ел саен диярлек файдалануга тапшырылуын күрергә мөмкин.

### ИННОВАЦИЯЛӘР ЙӨРӘГЕ

«Түбән Кама Нефтехим» Фәнни-технологик үзәге (ФТҮ) үзе уртача зурлыктагы предприятие санала. Ул 12 тикшеренү лабораториясен, тәҗрибә-сәнәгать цехын һәм ярдәмче хезмәтләрне үз эченә ала. ФТҮндә эшләүче 285 кеше җитештерү өчен үтә кирәкле барлык этаплар белән шөгыльләнә: яңа төр продукция һәм технологик процесслар уйлап табу, продукциянең тәҗрибә партияләрен чыгару, үлчәмнәр методикасын эшләү, шулай ук нефть химиясе җиһазларын коррозиядән саклау һәм калдыкларны үтилләштерү.

Бүгенге заманның химик-технологы нәкъ менә шул эш фронты өчен җавап бирергә тиеш тә инде. «Кызганычка, химия технологияне 200 елга узып китте. Без продуктларны синтезлый беләбез, әмма аларны ала белмибез, – дип сөйли КМТТУ «Панхимтех» фәнни-җитештерү үзәге директоры Х.Харлампиди. – Шунлыктан, химик-технолог уйлап табучы гына түгел, бәлки технологияләрне җитештерүгә кертүче дә булырга тиеш. Бу исә бик зур хезмәт сорый, моңа кайвакыт 8–10ар ел вакыт китә». (ТКНХ да яңа материаллар күпкә тизрәк кулланышка кертелә. – Ред. иск.)

Соңгы вакытларда ФТҮ нинди инновацияләр керткән һәм кертә соң?

Беренчедән, бу «неодим» полибутадиены, ул «яшел» шиннар җитештерүдә кулланыла. «Неодим» полибутадиены, башка каучуклар белән чагыштырганда, болай да шактый өстенлекләргә ия. Әмма, моңа карамастан, ФТҮндә соңгы елларда «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә чыгарыла торган «неодим» полибутадиенының технологиясен камилләштерү һәм сыйфатын яхшырту буенча эш алып барылды. Бу эш нәтиҗәсендә 2015 елда яхшыртылган каучукның тәҗрибә партияләре алынды, аның сыйфатын Россия һәм ерак чит илләрнең «Түбән Кама Шин» һәм Continental кебек әйдәп баручы шин компанияләре уңай бәяләде.

Икенчедән, дивинил-стирол синтетик каучугы (ДССК). Шин сәнәгате материалларга һаман саен яңа таләпләр куя, шунлыктан ФТҮ, лабораторияләрдә барлык кирәкле экспериментларны һәм сынауларны үткәреп, узган елда пилот җайланмасында ДССК каучугының үрнәкләрен чыгарды, ул үзеннән алына торган протектор резинасының динамик характеристикаларын шактый яхшыртты. Алар сыналу өчен «Кама» ФТҮнә («Түбән Кама Шинның» фәнни-технологик бүлекчәсе) тапшырылды. Бу бергәләп үтелгән шактый зур юл иде, аның нәтиҗәсендә технология камилләштерелде, һәм 600 тонна яңа ДССК җитештерелде.

Әмма шинчылар моның белән генә канәгатьләнмәделәр: алар үзләренә «яшел» шиннар җитештерү өчен тагын да «алга киткән» каучук кирәклеген белдерде, ул шинны файдалану вакытын арттырырга,

Реклама

**БЕЛЕШМӘ**

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ – Россиянең әйдәп баручы нефть химиясе компанияләренең берсе. Продукциянең база мономерларыннан алып синтетик каучук һәм пластикларга кадәр киң ассортиментын җитештерә һәм сата.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең рәсми сайты мәгълүматлары буенча, компания дөньяда синтетик каучук җитештерүчеләрнең ТОП-10лыгына керә, дөньяда иң эре полиизопрен җитештерүчеләрнең берсе булып тора (дөнья базарының 43 проценты), бутил һәм галобутил каучуклар җитештерү буенча дөньяда иң зур өч компаниянең берсе санала*.

2015 елда компания 150 миллиард сумлык продукция саткан (шулардан дүрттән өче полимерларга туры килә). Бу 647 мең тонна каучук һәм 718 мең тонна пластмасса дигән сүз.

ягулыкны янга калдырырга һәм һавага зыянлы матдәләр чыгаруны киметергә тиеш иде. «Яңа буын ДССК» дип аталган әлеге технология өстендә ФТҮ хәзер актив эшли. Бу каучукның пилот үрнәкләре әйдәп баручы чит ил һәм Россия шин компанияләрендә сынала инде.

Өченчедән, газ һәм нефтьүткәргечләрне коррозиядән саклау өчен полиэтилен композиция эшләнде. «Кама полимер материаллар заводы» ҖЧҖ белән бергәләп эшләнгән магистраль газ һәм нефтьүткәргечләрне изоляцияләү өчен полиэтилен Түбән Кама нефть химиячеләрендә аеруча горурлык тудыра. Ике елдан азрак вакыт эчендә лаборатория тикшеренүләреннән сәнәгать җитештерүенә кадәр юл үтелгән. Хәзер ул Россиянең эре торба заводларында актив кулланышка кертелә.

– Бу продуктка «Транснефть ФТИ» ҖЧҖннән уңай бәяләмә һәм сыйфат сертификатлары алынды инде, – ди ФТҮ директоры Игорь Беланогов. – Аны шулай ук «Газпром ВНИИГАЗ» ҖЧҖндә сыный, чөнки без «Себер көче» магистраль газүткәргече төзелеше проектында да катнашырга телибез. Боларның барысы да инде 2016 елда ук 10 мең тоннадан артык яңа маркалы полиэтилен җитештерүне планлаштыру мөмкинлеге бирде.

ФТҮндә полиэтиленның Россиядә аналоглары булмаган башка маркалары да эшләнә. Мәсәлән, чатнауга югары чыдамлылыкка ия капкач һәм кечкенә япкычлар җитештерү өчен полиэтилен. Әлеге продукт импортны алыштыру линиясе буенча алкогольсез газлы эчемлекләр, чәй һәм соклар җитештерү белән шөгыльләнә торган Россия предприятиеләре заказы буенча эшләнә.

Моннан тыш, катлаулы конструкцияле эре габаритлы савытлар җитештерүдә кулланыла торган уртача тыгызлыктагы полиэтилен маркасын үзләштерү дә тулы куәтенә бара.

Полипропиленның яңа маркаларын эшләүдә дә импортны алыштыру төп мотивациягә әйләнә. Кагыйдә буларак, аларның заказчылары – автокомпонентлар, азык-төлек һәм сәнәгать упаковкалары җитештерүчеләр. 2014 елда ФТҮ «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ пластиклар заводы һәм коммерция хезмәте белгечләре белән берлектә полипропиленның биштән артык яңа маркасын сәнәгатькә керткән. Ә 2015 елда ТКНХнда автомобиль

* www.nknh.ru/products/

Реклама

PRESSA.RU

сәнәгате һәм төрү материаллары җитештерүе өчен пропилен һәм этиленның бәрелүгә һәм суыкка чыдам сополимерларының өч яңа маркасы чыгарылган.

Дүртенчедән, АБС-пластиклар. 2013–2015 елларда ФТҮндә АБС-пластиклар җитештерүдә кулланыла торган каучук уйлап табу буенча күппланлы эш алып барылган. Һәм кабат импортны алыштырырга туры килгән. «АБС-пластик җитештерү технологиясе читтән кертелгән каучук куллануны таләп итә иде. Бу АБС-пластикның табышлылыгын шактый киметә, – дип аңлата Беланогов. – Без үзебезнең технологияне эшләдек һәм дивинил-стирол каучугын алдык. Ул читтән кертелгәннәрнең күбесеннән шактый арзанрак, кулланылыш үзлекләре буенча алардан калышмый диярлек һәм технологиясе дә гадирәк».

Бишенчедән, полистирол. Фәнни-технологик үзәктә даими рәвештә бәрелүгә чыдам полистиролның яңа маркаларын эшләү бара, аерым алганда, азык-төлек продуктлары һәм көнкүреш техникасы упаковкалары җитештерү өчен майларга һәм фреонга чыдам маркаларны. Пластиклар заводында беренче сәнәгать үрнәкләре алынган инде, алар Россия һәм Татарстан сәнәгать предприятиеләрендә сынау үтә.

Тулаем алганда исә ТКНХда стирол пластиклар җитештерү схемасы бәрелүгә чыдам полистироллар һәм гомумкуллану полистироллары чыгару күләмен базар конъюнктурасына бәйле рәвештә җайларга мөмкинлек бирә.

### киләчәккә

ТКНХның киләчәктәге инновацион үсешенә килгәндә, бирәдә түбәнкамалыларның өмет һәм планнары барыннан да бигрәк пластик җитештерүләре интеграцияләнгән яңа олефин комплексы төзелеше белән бәйле. Шулай ук синтетик каучуклар җитештерү куәтен арттыру һәм мономерлар чыгару җитештерүен киңәйтү планлаштырыла.

**Владимир Капустин, ВНИПИнефть генераль директоры, РТФА академигы:**

– «Түбән Кама Нефтехим» – Россиядә нефть химиясе лидерларыннан берсе. Һәм, әлбәттә инде, илнең нефть химиясе бергәлеге предприятиенең үзе ниятләгән зур яңартуларны башлавын түземсезләнеп көтә.

—

**Александр Ламберов, КФУның А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты директорының сәнәгать бәйләнешләре һәм коммерция эшчәнлеген җәелдерү буенча урынбасары:**

– «Түбән Кама Нефтехим» ФТҮ барлык технологик процессларны җайлау һәм яңа продуктлар эшләү буенча гаять зур йөкләмә алып бара. Публикация һәм патентлар, яклaнган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре саны бу эшнең югары квалификацион дәрәҗәсе турында сөйли.

—

**Әнәс Сәхәбетдинов, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ баш технологы:**

– «Түбән Кама Нефтехим»-ның стратегик максатлары – глобаль базарларда диверсификацияләнгән синтетик каучуклар җитештерүче сыйфатында урын алу, Россиядә һәм БДБдә пластиклар базарының эре катнашучысы статусын ныгыту, импортны алыштыру, түбән өстәмә кыйммәтле продукция сатудан китү.

Җитештерү бурычларын хәл иткәндә ФТҮгә зур роль бирелә. Ул безнең ми үзәгебез, бирәдә прдукциянең яңа төрләрен җитештерү технологияләре туа, җитештерү, технология һәм экология тармакларында схемалар һәм проект вариантлары эшләү өчен башлангыч мәгълүматлар эшкәртелә.

Реклама

# ЮШКЫН ЯШЕ 60ТАН 100 ТӘҮЛЕККӘ КАДӘР БУЛГАН **ЧИСТАРТУ КОРЫЛМАЛАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ**

## Үткәргечләрдән аккан суларны чистарту корылмаларының табигатькә тискәре тәэсирен киметүнең төп юнәлешләре: чистартылган суның сыйфатын яхшырту һәм утырмаларның күләмен киметү максатыннан аларны эшкәртү ысулларын камилләштерү.

«МосводоканалНИИпроект»* АҖндә үткәргечләрдән аккан суны тирәнтен чистарту һәм биологик чистарту стадиясендә барлыкка килгән юшкын микъдарын киметүгә юнәлтелгән технология эшләнгән. Технологиянең нигезендә биологик чистарту корылмаларында – биотопта (аэротенкларда һәм икенчел тондыру бассейннарында) бердәм актив юшкын-биотип биоценозын төзү һәм аларны киләчәктә әлеге корылмалар өчен оптималь дип табылган актив юшкын яшен исәпкә алып файдалану ята. Актив юшкын яше даими, тотрыклыландырылган булган биологик чистарту корылмаларыннан файдалану биохимик оксидлашу тирәнлегенә һәм корылмалардан чыгарыла торган артык юшкын күләменә тәэсир итәргә мөмкинлек бирә.

Актив юшкын яшен арттыру аның аэротенктагы дозасын да шактый арттыра, дип санала, әмма болай эшләргә ярамый, чөнки икенчел тондыру бассейнында юшкынны утыртуда кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин. Әмма тикшеренүләр күрсәткәнчә, юшкын дозасының яшенә бәйлелеге кәкресе синусоид рәвешендә була.



1нче рәсем.

Мондый картинаның сәбәбе булып актив юшкынның яшенә бәйле рәвештә физиологик халәте үзгәрүгә нигезләнгән үзеннән-үзе җайлануы тора.

Курьяновск чистарту корылмаларында һәм Уфа шәһәре чистарту корылмаларының 3нче блогында үткәрелгән тикшеренүләр актив юшкынның артуы билгеле бер яшьтәге актив юшкын өчен даими зурлык булуын һәм аның корылманың оксидлаштыру куәтенә бәйсезлеген исбатлаган.


2нче рәсем.

Алынган нәтиҗәләр актив юшкынның яше 60 тәүлектән 100 тәүлеккә кадәр булган чистарту корылмаларыннан файдаланганда сусызландыру корылмаларына бирелә торган юшкын күләмен киметү нәтиҗәлелелегенең 55тән 90 процентка кадәр тәшкил итүен расларга мөмкинлек бирә. Юшкыннарны эшкәртү схемасында метатенклар кулланып, чистарту корылмаларындагы аэротенкларда актив юшкынның яшен киметеп файдалану технологиясе аларның санын якынча 2,5–3 тапкырга киметергә һәм файдалану чыгымнарын шактый азайтырга мөмкинлек бирә.

Сусызландыруга фаразланган еллык чыгымнарны киметү һәм, утырманың яшен 100 тәүлек циклләрендә тотып, аннары чистарту корылмаларындагы юшкынны тәүлегенә 100 000 кубометрлап зарарсызландыру файдасы елына 80–90 миллион сум тәшкил итәчәк.

Торбалардан аккан суларның утырмаларын сусызландыруга эксплуатацион чыгымнарны киметү һәм киләчәктә зарарсызландыру хисабына капиталь кертемнәрнең үзләрен аклау вакыты яңа аэротенклар төзү варианты өчен 3–4 ел, күләмнәрен арттырып, гамәлдәгеләрен реконструкцияләгән очракта исә 4–6 ел тәшкил итәчәк.

**Авторлар: Степанов М.А., Платонова О. А., Шеломков А. С., Климова Л. А.**

Акционерное общество “Институт МосводоканалНИИпроект”
**АО «МосводоканалНИИпроект»**

105005, Мәскәү шәһәре, Плетешков тыкрыгы, 22нче йорт, +7 (499) 261-53-84, +7 (495) 956-93-90,
факс: +7 (499) 261-77-75 e-mail: post@mvkniipr.ru www.mvkniipr.ru

*«МосводоканалНИИпроект» – су белән тәэмин итү, су бүлү, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын эшкәртү тармагындагы барлык инженерлык мәсьәләләрен комплексы хәл итә торган Россиядәге иң эре проектлау оешмаларының берсе. Табигый һәм агым суларны чистарту технологияләре, су чистарту һәм калдыкларны эшкәртү технологик процессларын автоматлаштыру, сүүткәргеч һәм канализация челтәрләрен яңарту һәм үстерүне планлаштыру һәм инвестицияләрне нигезләү тармакларындагы һ.б. инновацион чишелешләргә хуҗа.

Реклама

# «АКЧА МИНЕ ЯХШЫ ЯККА ҮЗГӘРТКӘНДЕР»

Автор:
Линар Закиров

Аяз Шәбетдиновның тормышы әкиятне хәтерләтә: 20 яшендә ул гап-гади студенттан миллионерга әйләнә. Ә быел 24 яшьлек эшкуар бер миллиард сум акча эшләү максаты белән янып йөри. Шушы чиккә былтыр ук үрелергә талпынган, әмма кереме «нибары» 724 миллионны тәшкил иткән. «Быел, һичшиксез, бер миллиардка ирешәчәкбез», – дип ышандырды ул безне.

Фотолар Аяз Шәбетдинов архивыннан алынды

Аяз Шәбетдинов Пермь крае Куеда бистәсендә туа. Миллионер булып җитешкәнче, кече яшьтән эшкуар буларак үзен төрле өлкәләрдә сынап карый. 15 яшендә әти-әнисенә, Ижауга күченеп китәсем килә, мәктәпне дә сайлап куйдым инде, дип әйтә. Алар исә, хәер-фатихаларын биреп, улларын җибәрә.

Егетнең шәһәрдә бер таныш-белеше дә булмый. Дуслар табу максаты белән ул мәктәпнең КВН командасында уйный башлый, алып баручы буларак та акча эшли. Мәктәпне тәмамлагач, Ижауның югары уку йортына керә.

Куеда бистәсенә әйләнеп кайтып, Аяз лимонад заводына эшкә урнаша. Шундагы тынгысыз көннәрнең берсендә аның башына хостел ачу уе килә. Ике ай ярым вакыт эчендә егет максатына ирешә. Ахыр чиктә, хостеллары бөтен ил буенча тарала. Бүген ул берничә дистә оешманы берләштергән Like* холдингын җитәкли.

### ХИКМӘТ ИСЕМДӘ ДӘ

– «Лайк» төшенчәсе һәркемгә таныш, ул дөньяда кешеләр иң яратып куллана торган сүзләрнең берсе дә әле. Социаль челтәрләрдә дә зур эш алып барабыз (социаль челтәрләрдәге йөрәк рәвешендәге билгеләр дә «лайк» дип атала бит – авт.), әмма исемне уйлап чыгаручы мин түгел. Иң яхшы атамага конкурс оештырып, күпчелек кеше шушы вариантны сайлады.

Соңгы арада бизнес-проектларыбызның артык күп булуы аркасында, шактый уңышлы эшләп килгәннәре дә аксый башлады. Шуның өчен киләчәктә һәр проектны аерым исем белән атарга уйлап торабыз. Кайбер проектларыбызга Like атамасы бөтенләй туры килми. Әйтик, Санкт-Петербургта «Лайк Барбершоп» (сакал-мыекны тәртипкә китерә торган урын – авт.) ачтык, анда йөрүче кешеләргә бу сүз ул кадәр якын да түгел. Бу проектның исеменә статуслылык кирәк, аның концепциясендә герб та, эчке символика да бар, клиентларга шуңа бәйле аксессуарлар бүләк итәбез, ә лайк массалылыкка ишарә ясый.

### КИРӘК ВАКЫТТА, КИРӘК УРЫНДА

– Тәүге проектларыбызның берсе каһвә сату нокталарына бәйле, иң күп керемне дә шунысы китерә. Әлеге бизнесның менеджменты яхшы, идарә итү компаниясендә 50гә якын кеше эшли. Кем әйтмешли, без кирәк вакытта һәм кирәк урында барлыкка килдек. Каһвә базары үсә бара. Аяк-кулыгыз белән башыгыз эшләсә, бу базарда уңышка ирешмичә калу мөмкин түгел диярлек. Кризис вакытында күпчелек проектларыбызның күрсәткечләре кимеде, ә каһвәнеке – никтер, киресенчә, үсте. Юкса, аңардан да кимү көткән идек.

«РосБизнесКонсалтинг» оешмасы тикшеренүе буенча, Россиянең туклану базарында каһвәханәләр арасында без – беренче, базарның 8,2% өлешен тәшкил итәбез. Тулы форматлы каһвәханәләр арасында безне «Шоколадница» гына уза. Көндәшлеккә фәлсәфи яктан карарга тырышабыз. Яңа компания ачылса, аларның эш алымнарын өйрәнеп, кызыклы тоелганнарын үзебездә кулланабыз.

Мин каһвә җанлы кеше, көненә бишәр стакан эчәм. Бер кеше белән шундый хәл килеп чыккан: ул өч долларга каһвә алган, ә өстендә ике долларлык майка булган. Эчемлекне ялгыш өстенә түккән, ә каһвә майкадан кыйбатрак бит. Футболкадан бигрәк, каһвә әрәм булды инде, дип кайгырган ул.

Каһвә – тормышымның зур өлеше, аңардан баш тартырга да теләп карадым, барып чыкмады. Ул – дөньядагы иң күп сатыла торган эчемлек, хәтта «Кока-кола»дан да уздыра.

Минем кофе плантацияләрендә булганым юк, ләкин күп сортларын татып карарга туры килде. «Никарагуанский марагоджип»

* Like-яшь миллионер Аяз Шәбетдиновның бизнес-проекты.

PRESSA.RU



дип аталганы компот сыман, бераз үтә күренмәле, юшкыны күп. Аны беренче тапкыр татып карагач, нәрсә китердегез сез миңа, дип канәгатьсезлек белдердем, ә хәзер бик яратып эчәм.

### «МИҢА БЕРКЕМ КОМАЧАУ ИТӘРГӘ ТИЕШ ТҮГЕЛ»

– Миннән, бизнеска акчаны каян табарга, дип сораганда, телефон кенәгәсен ачыгыз да барысына да шалтыратып чыгыгыз, дим. Әгәр бизнеста тәүге адымыгызны гына ясыйсыз икән, сезгә 10 миллион кебек зур сумма кирәк тә түгелдер. 500 мең таман гына була.

Мин дә хостел ачу өчен акча сорап, дустыма шалтыраттым, финанс моделемне күрсәткәч, ул аны ошатты. Дөресен әйткәндә, аңардан 200 мең сум сорадым, ә ул 100 меңне генә бирә алды. Әле анысын да сөйгән ярыннан сораган, ә теге кыз акчаны кредитка алган булып чыкты. Акчаның алдан уйланылганнан ике тапкыр азрак булуы аркасында төрлечә борганалырга туры килде. Минемчә, бизнесыбызның уңышы бөтен чыгымнарны мөмкин кадәр киметүгә бәйле.

Хезмәт күрсәтү өлкәсендә исә эш берничә факторга бәйле: сервис, бәя, уңайлылык, тынычлык һ.б. Бөтен нәрсәне яхшы итеп көйләп куйсаң, мисал өчен, аерым номерлар ясасаң, плазма телевизор урнаштырсаң, бәясе дә кыйммәт булырга тиеш була, 300 сумга гына хезмәт күрсәтә алмыйсың. Безнең хостеллар иң яхшылары, дип әйтә алмыйм, әмма алар очсыз. Без, беренче чиратта, бәягә игътибар бирә торган кешеләрне күздә тотып эшлибез. Кайбер көндәшләребездән шуның белән аерылабыз.

Үзем дә кайчандыр ярлы студент идем. Кесәндә 500 сум булганда, уңайлылык турында уйламыйсың да. Дөньяда андый кешеләр күп. Элегрәк үзебезнең хостелларда кунып чыксам, хәзер инде кунакханәләргә урнашып, уңайлылыкка игътибар бирәм. Диванга аугач, миңа беркем комачау итәргә тиеш түгел, тиз эшли торган Интернет кына кирәк, моның өчен өстәп түләргә дә әзермен.

Хостелларыбыз даими рәвештә 60 процентка тулы, кайбер өлкәләрдә күбрәк, кайберләрендә азрак. Казан – туристик юнәлеш, шуңа да монда күбрәктер. Ә менә Мәскәүдә эшебез бармый, анда аренда ставкасы югары. Бераз күтәргә, башта төбәкләрдә эшне ныгытырга кирәк. 2018 елгы Футбол буенча дөнья чемпионатына башкалада да, бөтен нәрсәне уйлап бетереп, зур хостел ачарга нитялибез. Анда инде уңайлылык турында уйлыйсы булыр.

### МОНДА ҺӘМ ХӘЗЕР

– Уңыш сүзен бәхет сүзе белән бер күрәм. Минемчә, һәр кеше бәхеткә омтыла. Ә бәхет ул – эшләгән эшеңнең нәтиҗә китерүе. Кайбер яңа ачылган бизнес-проектларга зур өметләр баглыйбыз, ә алар, киресенчә, безгә зыянга эшли булып чыга. Шуңа да карамастан, хаталарны төзәтәбез. Һәр кеше эшне беренче урынга куярга тиеш.

2015 елда компаниядә кризис булды. Бик күп кайгырдым, йокым качты. Депрессиядән тәмам җан бирмәс өчен, вак-төякләргә сөенергә өйрәндем. Циферблатына «монда һәм хәзер» дигән сүзләр язылган сәгатькә махсус заказ ясаттым, шул язудан башка анда бүтән берни, хәтта саннар да юк. Сәгатьнең фотосын социаль челтәрләргә элеп, фәлсәфәсен аңлаткач, берничә егет идеяне эләктереп алды да, «Аязныкы сыман сәгать сатып ал», дип, аны күпләп җитештерә башлады.

Теләсә нинди уңыш команда эшенә бәйле. Дуслар һәм туган-тумача белән бергә эшләргә ярамый, аралар бозыла, диләр. Мин дә бер проектны дустым белән башлап җибәрдем, әмма, ахыр чиктә, юлларыбыз аерылды. Булгалый инде...

Безнең компаниядә йөздән артык кеше эшли. Иң яхшы идарә итү моделе – турыдан-туры биш кеше белән эшләү. Мин дә биш кеше белән эш итәм. Аларның һәркайсысы бишәр топ-менеджер белән хезмәттәшлек итә, тегеләр исә тагын бишәр белән. Менә шундый иерархия.

### «ӘТИ-ӘНИЕМӘ КЫЧКЫРГАНЫМ БУЛМАДЫ»

– Татарларның бөтен чалымнары миндә чагыла. Әйтик, миңа да иң беренче һәм иң яхшысы булу теләге хас. Казанны яратам. Россиянең башка шәһәрләренә килгәч, мине аэропортта каршы алып, юлдан барганда, беренче чокырга эләккәч үк, озата баручылар: «Аяз, гафу ит, бездә юллар бик начар инде...» – диләр. Казанда шулай дип әйткән кеше булмады. Мондагы сыман үз шәһәре, төбәге белән шулкадәр горурланган кешеләрне күргәнем юк әле. Бәлки, Чечняда да шулайдыр.

Татар гаиләсендә тәрбияләнгән балалар әти-әниләренә күтәрелеп бәрелми. Үз-үземне тәэмин итсәм дә, әти-әниемә беркайчан да кычкырганым булмады. Бу бизнеста да үзен сиздерә, хезмәткәрләремә тавыш күтәрә алмыйм.



Гаиләм – әти-әнием, абыем белән Интернетта аралашабыз, шалтыратышабыз. Кызганыч, сирәк очрашабыз. Алар да бизнес белән шөгыльләнә. Эш буенча Мәскәүдә, Ижауда кисешсәк күрешәбез. Әтием-әнием Пермь краендагы Куеда бистәсендә яши. Анда инде өч ел булганым юк.

### «ЭШТӘН СОҢ ӨЙГӘ ТҮГЕЛ, ЧИТ ИЛГӘ КИТКӘН ЧАКЛАР БАР»

– Акча янчыгымда бер атнага җитәрлек кенә акча йөртәм. Кемдер байлыгын саунага, хатын-кызларга тотып бетерә. Бәхеткә, безнең беркайчан да болай кыланганыбыз булмады. Барлык ихтыяҗларны канәгатьләндерә башлагач, тормыш, билгеле, үзгәрә. Акча мине яхшы якка үзгәртмәде.

Күптән түгел бизнес буенча остазларымның берсе белән күрештем. Ул: «Минем янга эшкә урнашырга килгән кеше мода буенча, энәдән-җептән киенгән икән, аны алмыйм, чөнки ул бөтен энергиясен матур күренүгә сарыф итә», – дип аңлатты.

Буш вакытта сәяхәт итәргә тырышам. Берсендә шундый цитатага тап булдым: «Өйдән чыкканда, кирәге булса, дип чит ил паспортын ала торган булсаң, тормышың барып чыккан, дигән сүз». Минем дә эштән соң өйгә түгел, аэропортка барып, берничә көнгә чит илгә ял итәргә очканым бар.

Туганнарым, дусларым бурычка акча ала иде, әмма бер ел инде сорамыйлар, чөнки бирми башладым. Әҗәткә бирү дөрес түгел. Дуслардан үзем акча сораган очракта да процентка гына алам. Безнең бит кредитларыбыз да күп. Акча белән базар шартларына таянып эш итәргә кирәк.

Заманында әни белән болай дип сүз куешкан идек: акча эшли башласам, аның сәяхәткә киткән чыгымнарын күтәрәчәкмен. Кеше итәр өчен башта әти-әнием миңа акча тотты, ә хәзер мин шул акчаны кайтарам.

# ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

**БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:**

Җиңүчеләр буыны безгә **НӘРСӘ** васыять итә

Парашютны иярләгән сугыш ветераны **КАЙДА** яши

Татарстанда орден **НИНДИ** казанышлар өчен бирелә

PRESSA.RU



# ҖИҢҮЧЕЛӘР ВАСЫЯТЕ

**ТАУ АСТЫ ТӘКЕРМӘН АВЫЛЫ, МИНЗӘЛӘ РАЙОНЫ**

## РАВИЛ РИЗАЭТДИНОВ:
## – БЕЗ КӨРӘШЕП АЛГАН ТЫНЫЧЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

Равил Ризаэтдин улы Ризаэтдинов. Ерак Көнчыгышта 183нче укчы полкында хезмәт итә, пехотачы. Япония белән сугышта катнаша. 1950 елда демобилизацияләнгәннән соң, туган ягына – Минзәлә районы Тау асты Тәкермәнгә әйләнеп кайта. «Марс» колхозында терлекче, көтүче, балта остасы булып эшли.

АЛЕКСЕЕВСК БИСТӘСЕ,
АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ

## МИХАИЛ ВАРЛАМОВ:
## – МИН ЯШЬЛӘРНЕҢ СУГЫШ КҮРМИЧӘ ГЕНӘ ТОРМЫШ ИТҮЛӘРЕН ТЕЛИМ.

Михаил Иванович Варламов. Хәрәкәттәге армиягә 1943 елда чакырыла. Автомобиль полкында шофёр булып хезмәт итә. Хәрби юлы Витебскидан Көнчыгыш Пруссиягә кадәр сузыла. Җиңүне Кенигсбергта каршылый. Демобилизацияләнгәннән соң, туган җире Алексеевскига әйләнеп кайта, коры сөт җитештерү заводында эшли. Хезмәт стажы – 49 ел.

ЮГАРЫ ТӘКӘНЕШ АВЫЛЫ,
МАМАДЫШ РАЙОНЫ

## ГЫЙЛЬФАН НАСЫЙБУЛЛИН:
## – ВАТАННЫ САКЛАГЫЗ! АРМИЯДӘ ХЕЗМӘТ ИТӘРГӘ КУРЫКМАГЫЗ!

Гыйльфан Насыйбулла улы Насыйбуллин. Армия хезмәтен 1943 елда Мәскәү күген саклый торган зенит-артиллерия полкында башлап җибәрә. Фронтта – 1944 елдан. Артиллерист Насыйбуллин танкларга каршы торучы бригада составында Чехословакия белән Австрияне фашистлардан азат итә. 1950 елда демобилизацияләнгәннән соң, туган җире Татарстанга кайта. Мамадыш районы Югары Тәкәнеш авылында комбайнчы булып эшли.



АКСУБАЙ БИСТӘСЕ,
АКСУБАЙ РАЙОНЫ

## АНАТОЛИЙ МАТРОСОВ:
## – ӘГӘР БЕЗ СУГЫШНЫ ОНЫТСАК, УЛ ТАГЫН КИЛЕРГӘ МӨМКИН. СУГЫШ БЕРКАЙЧАН ДА КАБАТЛАНМАСЫН!

Анатолий Васильевич Матросов. Армиягә 17 яшендә – 1943 елның ноябрендә чакырыла. Аерым ранецлы огнемётлар батальонында көрәшә. Җиңүне Латвиядә каршылый. Сугыштан соң Байконурны төзи, Ерак Төньякта эшли, аннан соң туган Аксубаена кайта.

PRESSA.RU

АЛГА АВЫЛЫ, АКСУБАЙ РАЙОНЫ

## РӘШИТ МОСТАФИН:
## – ҺӘРКЕМ ВАТАН ИМИНЛЕГЕ ӨЧЕН ХЕЗМӘТ ИТСЕН ИДЕ!

Рәшит Мостафа улы Мостафин. Аны армиягә 1942 елда Тельман (хәзерге Аксубай) районы Алга авылыннан чакыралар. Беренче хәрби чыныгуны Курск сугышында ала. Белгород, Харьков, Полтаваны азат итүдә катнаша, берничә тапкыр яралана. Җиңүне Нарофоминскида госпитальдә каршы ала. Туган авылына 1947 елда әйләнеп кайта, «Кызыл маяк» колхозында тракторчы булып эшли.

СУБАШ АВЫЛЫ, ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫ

## ИВАН ЕГОРОВ:
## – КҮБРӘК БӘБИ АЛЫП КАЙТЫГЫЗ! БАЛАЛАРСЫЗ КИЛӘЧӘК ЮК.

Иван Иванович Егоров. 1942 елның декабрендә авиация механиклары курсын тәмамлаганнан соң, Ленинград фронтына җибәрелә. 159нчы авиация истребительләре полкында хезмәт итә. Техник Егоров әзерләгән машиналар 1000нән артык хәрби очыш ясый. 1948 елда демобилизацияләнә, туган ягына – Теләче районы Субаш авылына кайта. Укытучы, мәктәп директоры булып эшли.

КАЗАН

## РАИСА РОМАНОВА:
## – БЕЗНЕҢ ИЛ ЕГЕТЛӘРЕ АРМИЯГӘ БАРУДАН КУРЫКМАСЫННАР ИДЕ! БУ – ҺӘР ЧЫН ИР КЕШЕНЕҢ БУРЫЧЫ!

Раиса Ивановна Романова. Фронтта элемтәче була. Өченче Белорус фронты гаскәрләре белән Литваны азат итә. Җиңүне Кенигсбергта каршылый. Сугыштан соң Казанга әйләнеп кайта, сөт комбинатында эшли.

Фото: Александр Эшкинин

МЕЛЬНИЧНЫЙ ПОЧИНОК АВЫЛЫ,
БАЛЫК БИСТӘСЕ РАЙОНЫ

## ЛЕОНИД КУКАРОВ:
## – БАРЫГЫЗГА ДА МИНЕМ ЯШЬКӘ КАДӘР ЯШӘРГӘ ТЕЛИМ!

Леонид Семенович Кукаров. Армиягә 1944 елда чакырыла. Снайперлар мәктәбен тәмамлагач, Ерак Көнчыгышка 188нче артиллерия дивизиясенең укчы батальонына җибәрелә. Япония белән сугышта катнаша. 1951 елда демобилизацияләнә, туган авылы Балык Бистәсе районы Мельничный Починокка әйләнеп кайта. Колхозда тракторчы булып эшли.



Алар бик аз калды,
Алар юк диярлек.
Берничә елдан тик
Искә алып сөйләрлек...

Ул чакта аларга
Кирәкмәс берни дә.
Хәер, ул көн килеп
Җитәчәк һәр өйгә.

Кояш гел елмаер,
Биектән карар да.
Ә бездә тынычлык
Булсын һәр заманда!

## ТЫНЫЧЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

Иллюстрация: Игорь Кравцов «Последний салют»

PRESSA.RU

91 яшьлек Бөек Ватан сугышы ветераны, бүген дә парашюттан сикерүче Павел Клетнёв белән аның өендә әңгәмә корабыз. Бермәл, дивардагы картинага ымлап: «Бу кешене таныйсыңмы», – дип сорап куйды ул миннән. «Ленин», – дим. «Дөрес. Яшь коммунист булган чакта кибеттән алдым мин аны. Менә нинди бөек кешеләр булган, «җир – крестьяннарга» дигән гадел фикерләр алга сөрелгән бит, ә», – ди ветеран.

Фотолар П. Клетнёв архивыннан алынды

# «СИКЕР ДИСӘЛӘР, ХӘЗЕР ҮК СИКЕРЕР ИДЕМ»

Автор:
Линар Закиров

### «ТУПСА ЯНЫНДА БӨГӘРЛӘНЕП ЙОКЛЫЙ ИДЕМ»

Павел Кузьмич 1924 елда Лаеш районы Рогозино авылында дөньяга килә. Балачак хәерчелектә үтте, ипине дә туйганчы ашый алмадык, дип сөйли ветеран. Укырга биш километр ераклыктагы Смолдеярово авылына йөри. Гаиләләрендә балалар күп туа, әмма шактые иртә үлә, бишесе генә исән кала.

– 1940 елда олы абыем Казанга күченеп китте. Әти-әнием: «Өйдә ипи дә, сыер да юк. Абыең янына китәрсең инде», – дип карар кылды. Абыем ул вакытта «полуторка» дип аталган ГАЗ-АА машинасын йөртә иде. Хатыны һәм ике баласы белән Казанның Краснококшайск урамындагы йорт флигелендә яшәде. Мин шәһәр мәктәбендә укый башладым. Кышын башка кимичә генә йөрдем, киярге берни дә юк иде бит. Өйдә тупса янында бөгәрләнеп йоклый идем. Кышкы каникулда әти, шәһәргә килеп, нинди шартларда яшәгәнемне күрде дә, толыпка төреп, мине ат чанасында авылга алып кайтып китте. Җидееллык мәктәпне авылда тәмамладым, – дип сөйли Павел Клетнёв.

Сугыш башлангач, егет янә абыйсы янына килә. Аны фронтка алып киткәч, шәһәрдә ир-аттан башка яшәп булмас, дип, хатыны ике баласы белән үз авылларына кайтып китә. Бу вакытта фатирда берьялгызы калган егеткә 17 яшь була. Павел Казанның 22нче заводына слесарь булып эшкә урнаша.

– Безне цехтан берәр, икешәр атна җибәрмәгән чаклар да булды. Мастер манный боткасы алырга талон биргәч, ашханәгә тиз генә барабыз да, ботканы чәйнәп тә тормыйча йотып, кире киләбез. Йоклыйсы килә башлый, әмма безне өстерәп чыгаралар да эшләргә кушалар. Менә шундый авыр көннәр булды. Боерыкларны үтәү мәҗбүри иде. Завод директорына тәүлегенә 30 очкыч җитештерү бурычы куелган икән, әмерне үтәми кара әле. Безне тәртиптә тотар өчен, цех башлыгы үзе белән пистолет та йөртте, – ди әңгәмәдәшем.

### «ӘНИ БЕЛӘН КАЗАНГА ҖӘЯҮ КИТТЕК»

1942 елда «1924 елда туучыларны фронтка җибәрергә» дигән карар чыга. Августта завод Клетнёв белән исәп-хисап ясый. Сугышта бер-бер хәл була калса дип, егет берничә көнгә туган ягына кайтып килә. Элек Лаештан Казанга автобуслар йөри торган була, ә Лаеш белән Рогозино арасы – тагын 15 километр.

Иртәгә Казанның хәрби комиссариатына барырга кирәк, дип, Паша иртән торып, әнисе белән Лаешка җәяү китә. Килеп җиткәч, Казанга автобусларның инде күптән йөрмәүләре турында ишетеп, хәйран калалар. Әгәр дә егет хәрби комиссариатка билгеләнгән вакытка килмәсә, аны дезертир дип кабул итәчәкләр. Ә андыйлар белән озак сөйләшеп тормыйлар – аталар гына.

– Әнием белән Казанга җәяү киттек. Мин аңа: «Син кал, төне буе барып, военкоматка иртән җитәрмен әле», – дисәм дә, әни үземне генә җибәрмәде. Юлга дип бик күп пәрәмәч пешергән иде. Бәхетемә, офыкта машина күренде, рульдә – хатын-кыз. Аны туктатып, йомышымны аңлаттым. «Ала алмыйм, тәгәрмәчләрнең тыны болай да аз. Җитмәсә, кузов тулы кыяр», – ди ул. «Мине бит дезертирлык өчен атып үтерәчәкләр. Кызганмыйсыңмы?» – дигәч кенә, шоферның күңеле йомшарып китте. «Ярый, кереп утыр», – диде. Әнигә капчыгымнан пәрәмәчләр, кыярлар биреп калдырдым. Аңа без туктаган урыннан Лаешка кадәр башта – 12, аннары авылга тагын 15 километр кайтасы иде...

### «100 ГРАММ БИРГӘН ӨЧЕН, АНЫ АТАРЛАР ИДЕ»

Павел военкоматка вакытында килеп җитә. Бөтен тикшеренүләрне узгач, башка егетләр янына хәрби комиссариат каршындагы чирәмлеккә чыгып утыра. Берзаман капитан: «Клетнёв! Кил монда!» – дип, 100ләп чакырылучының документын тапшырып, шулар өчен аны җаваплы итеп билгели. Егетләрне поездга утыртып, Горький (хәзерге Түбән Новгород өлкәсе – ред.) өлкәсенең Гороховец лагерьларына җибәрәләр.

– Урманда урнашкан дүртенче артиллерия полкына килдек. Командирга документларны биргәч, ул барыбызны тезеп бастырды да исемлек буенча тикшереп чыкты. Хәзер генә армиядән качалар ул, элек беркем сызу ягын карамый иде. Лагерьда хәрби күнекмәләрне, Америка машиналарын өйрәндек. Шуннан соң Уралга, Чибәркүлгә җибәрделәр. Хәтерләсәгез, берничә ел элек шунда метеорит төшкән иде. Кызык бит ә, без һәр иртә шул күлгә барып юына идек, – дип, хатирәләре белән уртаклаша ветеран.

Павел Клетнёв, Ленинград полкына эләгеп, шәһәр блокадасын өзүдә катнаша – тракторда пушкалар ташый. Егет шунда чакта якыннары белән хат алыша. Бөтен язганнар цензура аша үткәнгә, Клетнёв: «Мин сезгә беркем кайтмый торган урыннан язам», – ди. Әнисе исә авыл хәлләрен тасвирлап, күпме бәрәңге алулары, ничә табык тотулары турында яза.

– Беренче майда бәйрәм хөрмәтенә 100 грамм аракы бирә иделәр. 30 апрель көнне складка ризык алырга килгәч, шыпырт кына 100 грамм сорадык. Склад мөдире: «Бүген берничек тә бирә алмыйм, иртәгә генә», – ди. Менә нинди каты тәртип иде. Әгәр ул безгә

PRESSA.RU

аракы биргән булса, ике дә уйламый атарлар иде үзен…

Каткан ипине ун кешегә бүлә идек. Кирпечне пычкы белән кискәч, отделение командиры бармагы белән бер кисәккә төртеп, «моны кем ала», дип сорый, фәлән кеше «мин алам», ди. Менә шундый демократия, бөтен нәрсә гадел иде, – дип сөйләде ветеран.

Көннәрдән бер көнне Ленинград полкының артиллерия начальнигы яшь, укымышлы солдатларны артиллерия училищесына җибәрә.

– Бишенче майда тезделәр дә яңа кием-салым, капчык бирделәр. Ладога күленә безне бер офицер озата барды. Шулчак өере белән нимес самолетлары килеп чыкты һәм ата башладылар. Без яр буйлап таралыштык. Кичен, катер килеп, безне утырттылар да өстән люкны ябып куйдылар. Эчтә кап-караңгы, ни булса, шул булыр, дип кузгалып киттек. Берзаман люк ачылып, күзне кояш чагылдыра башлагач, шулкадәр рәхәт бер тойгы кичердек, – дип, шул чактагы күңел халәтен сурәтләде Павел Клетнёв.

### «АБЫЕМ НИМЕСЛӘРГӘ ӘСИРЛЕККӘ ЭЛӘКТЕ»

Егетләр Ленинград өлкәсенең Тихвин шәһәреннән поезд белән Свердловскидагы артиллерия училищесына китә. Әмма анда укырга имтихан белән генә кабул итәләр.

– Иртән исемлектә үз исемемне күреп, бик сөендем. Мин бит җиде класс укыдым, ә дүрт-биш класс тәмамлаучылар, алгебраны белмичә, сынауны уза алмады. Укырга кермәүчеләрне кабат фронтка җибәрделәр. Озакламый Сталин фәрман чыгарды: Советлар Союзындагы хәрби училище курсантларын десант гаскәрләренә күчерергә. Теплушкаларга утыртып, Иваново өлкәсенең Тейково шәһәренә алып бардылар. Анда парашют төзелешен, аны ничек җыярга кирәклеген өйрәттеләр. Бу 1943 елның көзе иде. Бераздан дивизиябезне Калинин өлкәсенең Андреаполь шәһәренә күчерделәр. Шунда парашют белән ике тапкыр сикерергә насыйп булды: беренчесендә – аэростаттан, икенчесендә – «Дуглас» самолетыннан, – ди Павел Клетнёв.

Сугышта егет Уралдан килгән Саша Усанов исемле егет белән шулкадәр дуслашып китә, хәтта ботканы да бер котелоктан ашыйлар. Саша «Виллис» машинасында майорны каядыр алып барганда, минага эләгеп, тәмам теткәләнеп бетә, хәтта җирләргә гәүдәләре дә калмый.

Сугыш тәмамланса да, Клетнёв Венгрияне, Австрияне, Чехословакияне азат итүдә катнаша. Туган ягына 1947 елның мартында әйләнеп кайта. 1927 елгы энесе дә, японнар белән сугышта катнашып, өйгә шактый соң кайтып керә. Павел Клетнёвның Казанда бергә яшәгән абыйсы исә сугышта немецларга әсирлеккә эләгә. Ул медсанбатта хезмәт итә. Берзаман солдатлар белән бер авылда кунып кала. Иртән торсалар, аларны немецлар әйләндереп алган да: «Хенде хох!» («Кулларыгызны күтәрегез!»), – ди икән. 50ләп солдатны колоннага тезеп, Германиягә алып китәләр дә бер алпавытта эшләтәләр. Егетләр шуның бакчасында редис, кишер, башка төрле яшелчәләр үстерә. Көне буе эшләтеп, хуҗа кеше аларны сарайга кертә дә капкага зур йозак элә торган була. Сугыш беткәч, егетләрне америкалылар азат итә. Әмма аларны шул мизгелдә үк өйләренә кайтармыйлар, Кавказга урман кисәргә җибәрәләр. Сугыштан соң бөтен нәрсә җимерелгән, яндырылган, ә йортлар төзү өчен агач кирәк була.

– Безне Эстониядән демобилизацияләделәр. Кая кайтасың, дип сорагач, туган ягыма – Лаешка, дидем. Фронтка Казаннан киткән идем бит.

Авылга кайтып, ике көннән 22нче заводка эшкә урнашырга киттем. Башта хәрби комиссариатка кердем. Документларыма карап, «монда Лаеш районы дип язылган, без сине эшкә ала алмыйбыз», – диделәр. Хәрби комиссариат башлыгы янына кереп, хәлне аңлаттым. «Авылга кайтсам, анда ашарга да берни юк бит», – дидем. Комиссариат башлыгы, кызганыптыр инде, мине теркәп куярга кушты. Шуннан соң яңадан заводта эшли башладым, – дип сөйләде сугыш ветераны.

### «ОЧКЫЧТА ҮЗЕМНЕ ТРАМВАЙДАГЫ СЫМАН ХИС ИТӘМ»

Павел Кузьмич 1953 елда Казанның Төньяк бистәсендә йорт төзеп куя. Бүген дә шунда тора. Өч улы бар, ә менә оныкларының һәм оныкчыкларының төгәл санын да белеп бетерми. Алар бертуктаусыз үрчи бит, дип шаярта.

Павел Клетнёв сугышта самолеттан ике тапкыр сикерсә, өченче тапкыр һавага 88 яшендә генә күтәрелә. Дөрес, бу да шаккаткыч күренеш, әмма иң гаҗәбе – ул бүген дә, ягъни 91 яшендә, парашютны рәхәтләнеп иярли.

– Якыннарыгыз каршы килмиме соң? – дип сорыйм.

– Юк, алар холкымны белә, мин үзсүзле бит. Алдыма куйган барлык максатларга ирешә киләм, – дип елмая әңгәмәдәшем.

Былтыр сугыш ветераны ике тапкыр очкан. Аңарчы комиссия сәламәтлеген, кан басымын яхшылап тикшергән.

– Сикер, дисәләр, хәзер үк сикерергә әзермен. Самолётка кереп утыргач, берсендә инструктор миннән: «Кузьмич, үзеңне ничек хис итәсең?» – дип сорады. «Трамвайдагы сыман», – дип җавап бирдем.

– Җиргә очканда, нәрсә турында уйлыйсыз?

– Хәзер төшәрмен дә, мине каршы алырлар, ашханәгә алып барып котларлар, шуннан соң өйгә кайтырмын, дип. Бу мәсьәләдә мин тыныч. Десантчы дустым бар минем. «Коркачык» аэродромына баргач, ул: «Кузьмич, ничек йокладың?» – дип сорады. «Ничек булсын инде, кич белән арып кайттым да ятып йокладым», – дим. Ул: «Ә мин, син ничек сикерерсең икән, дип борчылып, төне буе керфек тә какмадым», – ди.

Павел Клетнёв бу елның апрель башында Минзәлә аэродромында парашюттан алтынчы тапкыр сикерде. Инструктор белән бергә. Икенче августта – десантчылар көнендә – ул кабат күккә күтәрелергә ниятли. Бабасының батырлыгын оныгы Настя ике тапкыр кабатларга өлгергән.

– Урамнан барганда таныйлар, «парашюттан сикергән теге бабай сез буласызмы инде», дип, сораулар бирәләр, – дип көлә Бөек Ватан сугышы ветераны.

Левченко бистәсендәге махсус мәктәптә тәрбияләнүче балалар, 33нче мәктәп укучылары, студентлар да, Павел Клетнёв янына килеп, бакчасын казыйлар, карын чистарталар. Десантчының бакчасында киви, әстерхан чикләвеге, гранат шаулап үсә.

Бөек Ватан сугышы ветераны Павел Клетнёв бүген дә аркасын туры тотып, егетләрчә нык басып йөри. Башында – зәңгәр берет, өстендә – сырлы-сырлы тельняшка. Нәкъ 70 ел элек йөргән сыман, диярсең. Сугышта аеручa ныгыган иң бөек хисләр – ватанпәрвәрлек белән тәвәккәллек тәгълиматларын Павел ага бүген, очрашуларга йөреп, яшьләргә төшендереп калдырырга тырыша.

PRESSA.RU

# «ӨСТӘЛДӘГЕ КАТЫК ТА ИСКӘ КЕРЕП ЧЫГА»

Фронт хатлары – Бөек Ватан сугышының ветераннар белән бергә бүгенге көнгә кадәр яшәп килгән тере шаһитлары. Килер бер көн: бер ветеран да калмас, әмма аларның йөрәк җылысын шушы хатлар саклар. Алар – шул еллар фаҗигасенең көзгесе. Сезнең игътибарга Кызыл армия сафларына Татарстаннан китеп, туган-тумачалары, хезмәттәшләре белән күңел җылысын алышкан каһарманнарның татар телендәге хатларын тәкъдим итәбез.

**Автор:**
Линар Закиров

**НӘБИУЛЛИН ФӘТТАХЕТДИН НӘБИУЛЛА УЛЫ**

1908 елда Әгерҗе районы Тәбәрле авылында туа. Сугышка кадәр колхозда эшли. Кызыл Армиягә 1941 елның 13 июлендә алына, шул ук елның августында вафат була.

Сез ки, сөекле булган бәгырькәем, җанкисәгем Рәхимә.

Сезгә без ки, Казан шәһәрендә Кызыл Армия сафында яшәүче хәләлең Фәттахтан кайнар сәлам сөйләп калам. Һәм шулай ук йөрәк җимешем, кадерле бәбкәм һәм күз алмам Мөнәвәрәгә һәм шулай ук Фәрдетдингә йөрәгемнең иң нечкә тармакларыннан кайнап чыккан сәламнәремне сөйләп калам. Һәм сәлам турында күп язып тормыйм, вакыт бик аз, мине сораган кешеләргә сәлам диген.

Ярый, хәзер үземдәге хәлләргә килсәк, хәзергә ничава, таза-сау. Мин сезне дә шулай ук дип беләм. Ярый, хәзер менә нәрсә, 23ендә язган хатыңны алдым. Ни язган – бар да аңлашылды. Түлкә бик аз язгансың, тормышта нәрсәләр бар – барын да аңлата алмагансың, авыл хәлләрен дә язмагансың. Аннан соң Әгерҗедән ничек кайтканны да әйтмәгәнсең. Оланнарның тазалыгын да, аннан соң ашау якларын да язмагансың...

*1941 ел, июль.*

* * *

Сөекле симияләрем! Сезгә исәнлек хаты.

Бәгърем, күз алмам Рәхимә! Сиңа әйтәм шуны: оланнарны, зинһар, какма, ничек тә тәрбия итәргә тырыш. Аллага шөкер бит, безнең илдә тыныч бит әле хәзергә. Сыер исән-сау булса, боерган булса, балаларга җитәр әле. Пусть, түләсе бар дип, аларны тилмертеп торма, ашат. Алар хәзер син эшкә җөргәндә өй саклый торганнардыр инде. Әлфия бик ябыкмадымы? Фәрди тазарып җиттеме инде? Син Әгерҗедән кайткач бик еламадыңмы? Хат салган чагында кәгазь салырга тырыш, монда юк. Аннан соң хатны тиздән язып салыгыз. Менә минем монда язган сүзләрне онытма. Аннан соң кеше арасында яхшы йөр! Эшкә йөргәндә кеше белән сүзгә килеп йөрмә, кеше көлмәсен. Кеше арасында көлкегә калма, ярыймы! Монда сүз ишетелмәсен.

*1941 ел, 20 август.*

## ҖӘЛИЛОВ МУСА МОСТАФА УЛЫ

Шагыйрь, Советлар Союзы Герое (1956 елда, үлгәннән соң). 1906 елның 15 февралендә Оренбург өлкәсе Мостафа авылында туа. «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларының мөхәррире. 1939-1941 елларда татар опера студиясенең әдәби бүлеген, Татариянең совет язучылары берлеген җитәкли.

1941 елда армиягә алынып, хәрби-сәяси курсларга җибәрелә. 1942 елның мартыннан – Волхов фронтында икенче Удар Армиясенең «Отвага» газетасы редакциясендә хәрби корреспондент вазыйфасында. Июньнең икенче яртысында яраланган Муса Җәлил әсирлеккә элгә. Германиядә совет әсирләренең яшерен оешмасын булдыра. 1944 елда Плетцензее төрмәсендә җәзалана.

Муса Җәлилнең ТАССРның Югары Совет Президиумы рәисе Г.А.Динмөхәммәтовка хаты.

Хөрмәтле Динмухаметов ага!

Казанда мине язучы, композитор, артист иптәшләр искиткеч җылы каршы алдылар һәм бик зурлап озаттылар. Аеруча партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре. Сезнең тарафтан миңа шундый тирән игътибар һәм сизгер кайгыртучанлык күрсәтелүгә мин чиксез нык шатланам. Бу, әлбәттә, ялгыз бер миңа күрсәтелгән игътибар түгел. Моны мин татар совет культурасы сәнгате һәм әдәбиятына карата күрсәтелгән кайгыртучанлык дип аңлыйм. Мин сезнең һәм Казаннан бөтен иптәшләремнең бу игътибарына, киләчәктә әдәбият һәм фронттагы зур эшләрем белән җавап бирергә тиешмен.

Мин китәсе көнне иптәшләр зур мәҗлес җыйган иде. Сез районда булып, килә алмадыгыз булса кирәк. Мөхәмметов (Әнәс Мөхәммәтов – партия эшлеклесе – иск.) һәм Тинчурин (Закир Тинчурин – Казан шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе – иск.) иптәшләр дә бар иде. Монда махсус кичә җыеп, анда Имамутдинов (Тәхфәт Имаметдинов – ТАССР Совет язучылары союзы җаваплы сәркатибе – иск.) һәм Кутуйның (Гадел Кутуй – язучы – иск.) миңа карата артык зурайтып, күтәртеп речь сөйләүләре миңа, әлбәттә, бик уңайсыз булды. Бу инде артык эшләнгән эш иде. Мин моның өчен борчылдым. Бик уңайсызландым. Оялып, кая керер тишек тапмый аптырап утырдым. Чөнки артыграк мактап, артыграк куертып җибәрделәр. Шулай да иптәшләрнең миңа шундый җылы карашы һәм чын күңелдән әйткән теләкләре мине бик дулкынландырды.

Семьям мин юкта хөкүмәт кешеләре тарафыннан үзенә зур игътибар һәм кайгыртучанлык күрсәтелгәнен сөйләде. Моның өчен шулай ук сезгә зур рәхмәт укыйм.

Фронттан сезгә шиксез язып торачакмын. Хушыгыз! Кайнар сәлам белән, сезнең Муса Җәлил.

*1942 ел, 23 гыйнвар.*

* * *

Хөрмәтле Динмухаметов ага!

Сезгә йөрәгемнән чыккан кайнар боевой сәламемне сөйләп калам.

Мин армиягә киткәннән бирле фронт эшеннән бушаган арада сезгә шундый сәлам хатлары язуны гадәт иттем. Сез моның өчен миңа ачуланмый торгансыздыр бит? Моннан элек язган хатларымны вакытында алгансыздыр дип ышанам.

Военкор эше болай тыныч эштер кебек тоелса да, ләкин фронтта алай ук түгел. Миңа военкор буларак атнага 2 генә көн редакция землянкасында (шалашында), ә 5 көн рәттән фронтның алгы позицияләрендә, полк, батальон, рота рубежларында, блиндажлардан блиндажларга боевой походта йөреп үткәрергә туры килә. Чөнки шунсыз газетаны оператив һәм боевой итеп чыгарып булмый. Фронтның чын геройларын, командир һәм сугышчыларны шулай ук газетада яктырту, анализ ясау өчен боевой эпизод һәм боевая операцияләрне бары фронтның алгы сызыгында гына күреп була. Зур батырлыклар күрсәтеп орден-медаль алган байтак татар егетләрен дә күрдем. Алар турында «Кызыл Татарстан»га язам, шулай ук әдәби әсәр язарга җыенам. Шулай итеп, монда чын-чынлап шигырьдә әйткәнчә, бер үк вакытта каләм һәм автомат белән сугышырга туры килә. Мин үз эшемнән бик разый. Тик шулай да мин, Фадеев тәкъдим иткәнчә, «Кызыл Татарстан»ның махсус военкоры булып милли частьләрдә йөрергә, татар геройлары турында

PRESSA.RU



язарга теләр идем. Мин татар язучысы булганга, рус газетасында күп файда китерә алмыйм. Бу турыда «Кызыл Татарстан»га хат яздым. Барып чыкса яхшы булыр иде, көтәм. Әгәр сез бу эштә ярдәм итсәгез, бәлки, чынлап та, барып чыгар иде.

Сезгә, Гали ага, тагын бер зур үтенечем бар. Минем тормыш иптәшем Әминәгә Москвага барып килергә пропуск кирәк иде. Аның әти-әнисе Москвада. Ул 5 яшьлек кызым Чулпанны әти-әнисенә илтеп куеп, үзе эшкә урнашырга тели. Аның әтисенең саулыгы начар, шуңа борчыла. Сез, мөмкин булса, Әминәгә кызым белән Москвага барып килергә ничек тә пропуск алуда ярдәм күрсәтсәгез икән. Моны инде бик үтенеп сорыйм.

Үзем язу эшемне дәвам иттерәм. Байтак шигырь һәм җыр яздым. Буш арада сезгә күчереп җибәрермен әле.

Хушыгыз. Сәлам һәм ихтирам белән, Муса Җәлил.

*1942 ел, 2 июнь.*

## ЗАЛАКАЕВ ИСХАК ШӘРӘКЫЙ УЛЫ

1924 елда Аксубай районы Яңа Ибрай авылында туа. Сугышка кадәр – Аксубай районы «Үсәр» колхозы әгъзасы. Кызылармияче. 1943 елның 13 февралендә вафат була. Ленинград өлкәсенең Калинин районы Красный Бор авылында җирләнә.

Сагынычлы хат башы.

Исәнмесез, кадерле әти һәм дә әнигә бик сагынып, бер күрергә зар булып, бик күп санда булган сәламнәремне сезгә кайтып ирешүен теләп сагыну хисе белән ышанып калам.

Мин әти һәм дә әни өйдә вакытта армиягә алынуымны, елларның ничек икәнен белә торып та, яшьлек белән сезгә бернинди дә ярдәм итәлмәдем. Армиягә китү күрше авылга китеп кайту иттереп уйланылган. Шулай да мин сездән сорыйм миннән кимчелек уйламавыгызны. Мин сезнең хезмәтегезне үлгәндә дә онытачак түгел. Киләчәк көндә исән-сау әйләнеп кайтып, бергә шатлыклы гомер кичерергә ходай язсын иде. Әни минем өчен елый торгандыр инде. Ничек кенә уйласам да, күз алдыма килеп тора. Мин әтине дә армиягә алганнардыр, дип уйлый идем. Инде Зиак әзи сезнең турыда бернәрсә дә язмаса да, исәнлегегезне белеп, шатлыгым эчемә сыймады. Әти дә өйдә икән әле, мин мондагы чамага чагыштырдым. Миннән хат сирәк алабыз дигәнсез, госпитальдә вакытта көн дә диярлек хат язып тордым. 10 нчы майда язган хатыгызны 10 нчы июньдә алдым.

*1942 ел, 11 июнь.*

## ВӘЛИЕВ БАРИ КАДЫЙР УЛЫ

1921 елда Апас районы Коштаулы авылында туа. Җидееллык мәктәпне һәм бухгалтерлар курсын тәмамлап, колхозда бухгалтер булып эшли. 1942 елда Кызыл Армия сафларына алына. Суслонгер (Мари АССР) лагеренда снайперлар курсын тәмамлап, Сталинград фронтына җибәрелә, шул ук елда вафат була.

Исәнмесез!

Сез ки якын булган әткәй белән әнкәйгә улыгыз Баридан бик сагынып, бер күреп туйганчы сөйләшәселәрем килеп, бик күптин күп сәлам.

Мин сезгә барын да язып хат салган идем, алгансыз. Сезгә генә түгел, авылга бик күп кешегә салган идем. Берсенә бармаса, берсенә баргандыр.

Шушы атнада без фронтка керәбез. Ниләр булыр. Без берни уйлаган юк. Кызык төсле. Күләбез дә, сөйләшәбез дә, авылны да искә төшерәбез. Киткәндә өстәл өстендә калган катык та искә кереп чыга. Алдагы көндә 1942нче елны сугышны бетереп, шатлык белән кайтабыз төсле. Аларны да уйлыйбыз.

Ашау ягы көнгә 650 грамм 3 аш. Хәзергә 500 сум акча да бар әле. Мин ашау ягына аптыраган юк. 650 граммны 65–70 сумга сатып алып була. Килү белән бөтен икмәкне сатып акча итеп куйган идем, итү (юкса – иск.) икмәкне урлыйлар. Мин алдатмадым анысы белән. Хәзер кирәк вакыт яңадан-яңа икмәк алып кына торам.

Башка Татарстаннан бер кеше дә юк. Бар да үзбәк, кыргыз, казакъ, таҗик һәм ике урыс бар – вәт инде минем иптәшләр. Минем өчен кайгырмагыз, мин әлегә кадәр бернинди кыенлык күрмәдем. Ярый, барын да язмам, кәгазь җитми. Белеп булмый, бәлкем, кайтсам барын да сөйләрмен.

*1942 ел, 12 июль.*

## БАКИРОВ ГОСМАН ФӘТХУЛЛА УЛЫ

1896 елда Арча районы Югары Курса авылында туа. Педагог, балалар язучысы һәм журналист. 1942–1945 елларда Госман Бакир – миномет батальонында корал командиры, «Ватан намусы өчен» фронт газетасының хәрби корреспонденты, подразделениенең партия оештыручысы була. 1982 елда вафат була.

Госман Бакирның язучы Афзал Шамовка язган хатлары.

Афзал дус!

Якын дус итеп күреп, җылы язылган хатларың миңа яңа көч, яңа дәрт кертә. Дус-ишләрдән бик аерым яшим мин, татарлар бөтенләй юк диярлек (бер татар егете бар, ләкин ул әдәби хезмәттән ерак кеше), шуңа күрә фикер алышып, әдәби эшләр өстендә эшләү турында гәпләшеп утырырлык кешеләр гомумән биредә юк. Кайчакта иске иптәшләрне күрү өчен әллә кайларга барасы килә.

Афзал дус, бәлки, исән калсам, очрашырбыз. Әгәр мин сугыш кырларында ятып калсам, минем үтенеч: минем басылган һәм басылмаган әйберләрне карап чыгып (билгеле, төзәтү кертү кирәк булыр) балалар өчен бер җыентык кебек нәрсә оештыруда инициатива күрсәтсәң иде. Бу – кечкенә генә булса да, мин ярап эшләгән балалар өчен, яшь буын өчен миннән бер кечкенә генә истәлек булыр иде…

Их, Афзал дус, белсәң иде, яшисе килә! Менә без торган хуторның исән калган чия агачлары хәзер ап-ак чәчәк җибәрде, һәр якта яшеллек, табигать үзенекен итә, гамьсез кошлар сайрый, тирә-юньгә ямь кертә. Ләкин бу күренешнең ямен кинәт туп тавышлары, баш очыннан очып киткән пуля сызгырулары гына боза. Дошманга каршы нәфрәт уяна, аны изеп ташлыйсы килә. Афзал дус, син минем табигатемне беләсең, элек тә мин кеше үтерү түгел, тычкан үтерүгә дә кулым бармый иде. Ә хәзер немец кабахәтләрен өере белән кырып ташлыйбыз, моны, теңкәгә тигән озынборын-черкине сытып ташлагандагы булган бер ләззәт белән эшлибез. Аларның үлек гәүдәләре аркылы атлап алга барганда төкереп үтәбез.

Болар турында язмасам да, син аңлыйсың инде, яза башлагач, тыйнаксыз каләм барын да яза бирде… Җитәр, землянканы караңгылык басты, күзләр начар күрә.

Афзал дус, кулыңны кысып сәлам белән калам.

*1944 ел, 16 май.*

Афзал дус!

Без Германия эченә кереп барабыз. Яңадан-яңа шәһәрләр, авыллар үтелә. Ләкин немец халкы качып беткән. Йортларда беркем дә юк. Үзебез хуҗа булып йөрибез. Йорт җиһазының, чүпрәк-чапракның чиге юк. Бөтен илне талап, бай яшәгәннәр икән кабахәтләр.

Афзал дус, сине минем положение белән кызыксынып, «офицерлар хокукы белән файдаланасыңмы?» дип сорыйсың. Мин һәм башка минем кебек иптәшләр (без бишәү шундыйлар) килгәннән бирле офицерлар хокукы белән файдаланабыз. 2350 сум хезмәт хакы алам. Шуннан 1000гә якыны өйгә җибәрелә. Безгә Германиягә килгәннән бирле марка белән түлиләр. Ул 4700 марка чамасы.

Тизрәк сугыш бетүен генә көтәбез. Хуш, дустым, ашыгычрак булды.

*1945 ел, 18 март.*

## ХАННАНОВА ҖИТЕЗ ШАҺГАЛИ КЫЗЫ

1924 елда Әлмәт районы Яңа Кәшер авылында туа. Сугышка кадәр Мәскәүнең юридик институтында укый. Сугыш елларында Ярославль шәһәренә, әти-әнисе янына кайтып, заводта эшли. 1943 елның 22 июнь төнендә Ханнановлар йортына бомба төшеп, барысы да вафат була. Җитез Ханнанова фронтка үз теләге белән китә. 1945 елда, сугыш тәмамлангач, хәбәрсез югала.

Исәнмесез, кадерле Әминә апа (Әминә Каюмова – Җитез Ханнанованың апасы – иск.)

Сагынып хат язам һәм тормышында бәхет теләп калам. Авыр, начар якка әйләнде тормыш – кайгы артыннан кайгы бара. Ярар, хәерлегә булсын. Апа, син үзең күрәсең, әз хат язам, йөрәк яна, ә сүз юк, йөрәк урынына әллә кем таш куйдымы күкрәккә. Аңларсыңмы апа, юкмы – белмим, бүре төсле берүзем тора алмыйм, ә монда, халык арасында, эш белән вакыт үтә. Ярар, апа, күрәсем килә туганнарның каберен, сезне, аннары күренер. Хәзер укыйм санинструкторга, укырга авыр түгел. Апа, син бер дә язмыйсың үзеңнең тормышың турында: ничек балалар, ашау-эчү ягы ничек – барысын да яз. Уку беткәч, үземне кайсы якка озатырлар, белмим. Кайсы фронтта булды жизнәй, извещение килдеме, ничек, – апа, яз. Минем өчен борчылма, үлсәм – үләрмен, ләкин гарьлек әти-әни, сезнең йөрәгегезгә китермәм.

*1945 ел, 14 март.*

*Хатлар кыскартылып бирелде. Авторларның стиле, орфографиясе һәм пунктуациясе сакланды.*



**Материалны әзерләүдә ТР Тарихи-сәяси документлар Үзәк архивы һәм Әгерҗе районының Тәбәрле авылы музее ярдәм күрсәтте.**

PRESSA.RU

# ҖИДЕ КАТ ЙОЗАК АСТЫНДАГЫ **КОНСТРУКТОР**

Автор:
Ольга Туманская

**«ТР алдындагы казанышлар өчен» ордены – ТРның иң югары дәүләт бүләге. Табигый ки, бу бүләккә лаек булган кешеләр – күренекле һәм гадәти булмаган шәхесләр. Аларның гаҗәеп язмышлары хакында алга таба сез махсус язмалар циклы аша белерсез. Ул язмаларның беренчесе – исеме озак еллар дәвамында яшереп сакланган Илдус Мостюков турында. Үзенең төп казанышы – ил оборонасы өчен гаять әһәмиятле булган Радиолокацион танунының бердәм гомумгаскәри системасы турында Илдус Шәйхелисламович безгә Җиңү көне алдыннан сөйләде.**

**«ТР алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

**Илдус Мостюков** – галим, Россия Хәрби фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, Социалистик Хезмәт Герое, «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасы рәисе. СССРда аның турыдан-туры җитәкчелеге астында (1962–1989 елларда) гомумгаскәри «Пароль» дәүләт радиолокацион тану системасы эшләнде һәм производствога кертелде. Бу система бүген дә, илнең оборона сәләтен нәтиҗәле төстә ныгыта барып, Россия армиясе һәм флотына хезмәт итә.

### ҮЗЕБЕЗНЕКЕ! ӘЛЛӘ ЧИТНЕКЕМЕ?

**– Илленче елларда СССР оборона сәнәгате өч ел саен дер селкенеп ала иде.** «Үзебезнеке – читнеке» радиолокацион тану системасы белән җиһазландырылган хәрби техникабыз ни өчендер нәкъ менә шундый периодик кабатлану рәвешендә чит илнең хәрби разведкасы кулына эләгә килде. Бөтен бәла шунда булды – «трофей» аппаратурасын дошман бик ансат кына, әйтик, үз самолетына урнаштырып куя ала иде. Ул очракта безнең ПВО «сукырая», читләрне үзенеке итеп кабул итә. Еш кына безнең чик буйларында америкалылар провокацияләр оештырды. Бу хәл килеп чыгу белән бөтен системаны ашыгыч рәвештә үзгәртеп корырга кирәк булды, ә бит ул барлык корабльләрдә, су асты көймәләрендә, самолетларда, радиолокацион станцияләрдә урнаштырылган була иде... Эшнең күләме ни дәрәҗәдә булганын күз алдына китерү дә кыен!

**1960 елда хәлиткеч киңәшмә булды** – КПСС ҮКның оборона сәнәгате бүлеге мөдире Иван Сербин трибунага – Оборона һәм радиосәнәгать министрлыклары вәкилләре алдына чыгып басты: «Кайчанга кадәр илне тезләндереп тотачаксыз?! Аппаратура дошман кулына төшкән очракта дискредитациядән курыкмый торган система эшләгез!» Системаны камилләштерү буенча иң яхшы тәкъдимгә ябык конкурс оештырырга карар чыгарылды. Һәм без моңа ирештек.

**Идеябезнең нигезен криптографик кодлаштыру тәшкил итте.** Кодлар очраклы закон буенча секундына күп тапкырлар алышынып торды. Аппаратураны кулына төшергән дошман инде берни дә эшли алмады – анда программа юк иде. Программа махсус методика буенча көн саен яңартылып барды. Безнең 294нче Тәҗрибә-конструкторлык бюросы моны уйлап тапкач, аны илнең баш институты итеп үзгәрттеләр, ә мине генераль конструктор итеп билгеләделәр. Без төзегән «Пароль» системасы алдагы 15 ел дәвамында барлык радиоэлектрон сәнәгать үсешенә этәргеч бирде – фәнни-тикшеренү институтлары, заводлар эшли башлады. Татарстанда гына да уннарча мең кешегә эш урыннары барлыкка килде.

### ИСӘН КАЛУ ӨЧЕН ТЫРЫШТЫК...

**– «Сугыш чоры балалары» дигән төшенчә бар.** Сугыш башланганда миңа унөч яшь иде. 22 июньдә әтием фронтка китте. Ә безгә исән калыр өчен тырышырга кирәк булды... Бәхеткә, тегү машинабыз бар иде. Нәрсә генә текмәдек без аның белән! Бияләйләр, телогрейкалар. Минем хезмәт эшчәнлегем шулай башланды. Бер партиясен тегәм дә өйдә эшләүчеләр артеленә тапшырырга йөгерәм. Әмма эшләүче булып бер әни генә исәпләнгәч, безгә иң аз сандагы азык карточкасы гына эләкте. Ул чакта Тукай урамындагы агач корылманың ярымподвалында яши идек. Аннан мин конструкторлык бюросы җитәкчесе булгач кына күченеп киттек.

### СЫНАУЛАРНЫ ТУКТАТЫРГАМЫ?

**– Системабызның гаскәри сынауларына ике атна калганда җәнҗал чыкты.** Аның... тотрыксыз эшләве ачыкланды. Уңышлы башкарылган дәүләт сынауларыннан соң бит! Безнең институт Ленин премиясенә лаек булганнан соң! Миңа инде Социалистик Хезмәт Герое исемен биргәннәр иде. Авиация маршалы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Евгений Савицкий да бик борчылды – ул дәүләт комиссиясе рәисе иде. Хәтта СССРның оборона министры Гречкога: «Гаскәри сынауларны туктатуыгызны, сәнәгатькә хәлне ачыкларга вакыт бирүегезне сорыйм» дигән телеграмма да җибәрде. Мин мәсьәләнең нәрсәдә икәнен аңладым, әмма хәл бик киеренке иде, беркем дә ишетергә теләмәде.

**Мине радиосәнәгать министры Петр Степанович Плешаковка чакырдылар.** Аңа дәүләт сынаулары вакытында аппаратурага шактый күп үзгәрешләр кертелүен аңлаттым. Ул үзгәрешләрне сериялэп чыгарыла торган аппаратурага кертергә кирәк булганлыгын, әмма хәрбиләрнең ашыгуларын һәм гаскәри сынауларга аның тиешле дәрәҗәгә җиткерелмичә эләгүен әйттем. «Ә син нәрсә тәкъдим итәсең?» – дип сорады министр. «Барлык комплектларны алыштыруны», – дидем. Плешаков башта моңа ышанырга да теләмәде – сынауларга нибары ике атна вакыт калган бит! Аннары безгә ике самолет бирделәр, һәм бригадаларыбыз чартерлы рейслар белән безнең система средстволарын җитештерүче заводларның һәммәсеннән яңа аппаратура алып кайтты. Шуннан эш башланды.

**1980 ел. Одесса. Дүрт йөздән артык сугыш техникасы катнашындагы гаскәри сынаулар уңышлы төгәлләнде.** Шуннан соң менә инде утыз биш ел дәвамында «Пароль» дәүләт тану системасы сугышчан сакта тора. Россиядә генә түгел – Коллектив куркынычсызлык турындагы килешү оешмасы илләрендә дә. Бу вакыт эчендә аппаратураның дошман кулына төшкән чаклары күп булды, ләкин аның өчен ул инде гади металл өеме генә иде. Бүгенгә кадәр бу системадан да яхшырагын уйлап табучы юк әле.

### СЕРЛӘР ҺӘМ БУТАЛЧЫКЛЫКЛАР

**– Без дәүләт югарылыгында әһәмиятле булган бурычларны үтәдек, ә моның өчен ил тиешле күләмдә акча бүлеп бирә иде.** Бу акчаны без эшләнмәләр өчен генә түгел, социаль үсеш өчен дә файдаландык. Торак йортлар, балалар бакчалары, тулай тораклар, пионер лагерьлары, ял базалары төзедек... Бервакыт, 60нчы елларда, мин Казанның башкарма комитеты рәисе Александр Бондаренко янына кердем. Фәнни-тикшеренү институты хезмәткәрләренә йорт төзү өчен җир сорадым. «Җир бирәм, тик торбаукәргечне үзең саласың», – диде. «Водоканал» 700 тонна чуен торба сорады! Коточкыч дефицит вакыт, әмма без Министрлар Советы аша бу мәсьәләне хәл итә алдык. Торбалар Казанга кайта башлады – барлык тимер юлларны тутырдылар. «Торбаларны алып китегез!» – дим «Водоканал»га. Ә анда: «Безгә хәзер чуен түгел, корыч торбалар кирәк», – диләр... Өлкә комитеты секретаре Михаил Троицкийга кадәр барып җиттек. Ә ул көлде: «Әй, ахмаклар! Тотам да чуен торбаларны Яр Чаллыга бирәм, ә Казанга корычны кайтарырлар». Нәкъ шулай эшләде дә.

**Бик «яшерен» кеше булгач, минем белән буталчыклыклар да килеп чыккалады.** Ничектер Урман хуҗалыгы министрлыгына ял базасы төзү өчен җир сорарга бардым. Таләбем зурдан: Идел ярыннан биш гектар җир сорыйм. «Кем соң син ул кадәр?!» – диләр миңа. Ә мин кем икәнемне әйтә алмыйм – менә шундый хәл. Өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табеевтан ярдәм сорарга бардым. «Уйлап карармын», – диде. Һәм менә бервакыт мине өлкә комитетына киңәшмәгә чакырдылар. Табеев берәүне тезелешне начар оештырган өчен сүгә. Аннары кинәт кенә: «Ә Мостюков кайда?!» – дип сорады. Торып бастым, эчемнән: «Хәзер миңа да эләгә», – дип уйлыйм. Ә ул: «Менә кемгә ярдәм итәргә кирәк! Дәүләт мәсьәләләрен менә кем хәл итә!» – диде. Шуннан соң һәр җирдә минем өчен «яшел ут» яна башлады.

**Безнең «Радиоэлектроника» Фәнни-тикшеренү институты хәзергәчә дәүләт тануы өлкәсендә баш булып исәпләнә.** Әле эшне башлаган гына вакытта ТКБнда 500ләп хезмәткәр бар иде. Эш төгәлләнгәндә 3500дән артык кеше булды. Югалтулар белән булса да, институт СССР җимерелгәндә һәм авыр 90нчы елларда исән кала алды. Бүген анда меңнән артык кеше эшли, һәм институт РФ оборона министрлыгы куйган бурычларны уңышлы хәл итә. Әгәр иртәгә хәзерге заманныкыннан мең тапкыр тизрәк эшли торган исәпләү машиналары уйлап тапсалар? Моңа алдан хәзерләнү зарур. Шуңа күрә системаны модернизацияләү буенча эш алып барырга кирәк. Һәм бу шулай эшләнә дә.

Фото: Ольга Туманская

PRESSA.RU



# СУГЫШ КИЧКӘН СОҢГЫ ТАТАР ЯЗУЧЫСЫ

**«Аягын өч тапкыр кискәннәр бит аның. Сызланудан кычкырып яткан солдатка морфий кадагач, «син бит болай үләчәксең», – дип, Ася исемле медсестра кыз, аңа морфий салмыйча, алдына утыртып юата, тынычландырып йоклата торган булган. Кыз кеше алдында утырган егет тешен кысып түзгән инде», – дип сөйли язучы, сугыш ветераны Хисам Камаловның башыннан үткәннәрен хатыны Роза ханым. Бу – аның китапларына кергән эпизодларның берсе. Мондый вакыйгалар Хисам аганың әсәрләрендә байтак. Алар – бизәлмәгән, акшарланмаган чынбарлык.**

Автор:
Рузилә Мөхәммәтова

Бөек Ватан сугышында катнашкан, сугыш газапларын кичергән язучылар Татарстанда өчәү генә: Арча районының легендар колхоз рәисе, документаль әсәрләр авторы Фәйзи Галиев, балалар шагыйре, тәрҗемәче Аркадий Мельников һәм Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, өч дистәдән артык китап авторы Хисам Камалов.

Татарстанның халык язучысы Хисам аганың дөнья белән алыш-биреше хәзер хатыны Роза апа аша. Үзе сөйләшми. Хәлен белешергә, күрешергә-сөйләшергә килүчеләрне тыңлый – үзе дәшми.

– Роза апа, ул бөтенләй дә сөйләшмимени, – дим, Хисам ага белән 57 ел гомер кичергән хатыны Роза Сәетовнага кат-кат.

– Сөйләшми... Колагына якын килеп әйткәч, миңа җавап бирә үзе. Хәтере дә начарланды инде. Әле былтырларын бергәләп кинолар да карый идек, «Казан утлары» журналын башыннан ахырына кадәр бөртекләп укып чыга иде. Хәзер юк инде. Биш ел урын өстендә...

Татарстанның халык язучысы, ТР Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Хисам Камаловка быел 90 яшь тулды. Ул сугыш кичкән соңгы татар язучысы.

Хисам Камалов – үлем белән күп тапкырлар очрашкан, фронтның алдынгы сызыкларында көрәшкән, яраланып, контузияләр алып, госпитальләрдә ятып исән калган кеше, фронтовик язучы. Унсигез яше дә тулмаган килеш сугышка алынып, Суслонгер хәрби лагере михнәтләрен үтеп, фронтка озатылган. «Икенче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында бик күп канлы бәрелешләрдә катнаша, 1944 елның җәендә, яраланып, өч ай чамасы госпитальдә ятып чыга, аннары яңадан фронтның алгы сызыгына җибәрелә, артиллерия полкының кыр элемтәчесе сыйфатында Латвия җирләре аша Польша чикләренә кадәр сугышчан юл уза. 1945 елның 26 февралендә Хисам Камалов кабат яралана һәм янәдән госпитальгә озатыла. Бу юлы җәрәхәт бик җитди булып, егеткә ел ярым төрле госпитальләрдә дәваланырга туры килә, ахырда бер аягын төптән кистереп, 1946 елны ул инвалид булып өенә кайта», – дип язылган аның биографиясендә.

Хисам аганың 57 ел бергә гомер иткән хатыны Роза Камалова – башта китапханәче, соңрак библиограф булып 27 ел Лобачевский исемендәге китапханәдә эшләгән. Алар ике ул – Зөфәр белән Айдарны үстергәннәр. Дүрт оныклары, ике оныкчыклары бар. «Онықчыкларым – Марсель белән Сорен Америкада яши, оныгым Лилия Америкага укырга китеп, шунда мөселман кешесенә кияүгә чыгып калды», – дип сөйли Роза апа.

**– Роза апа, Хисам ага белән ничек таныштыгыз?**

– Ул Казан педагогия институтының әдәбият бүлегендә минем Резеда сеңелем белән бергә укыды. Илдар Юзеевлар укыган бик талантлы төркем иде ул. Ә мин ике курс алдарак тарих бүлеген тәмамладым. Хисам миңа шул чакта ук игътибар иткән булган икән. Институтны тәмамлагач, мине юллама белән Ютазы районының Кәрәкәшле авылына укытырга җибәрделәр. Ул якта суда йод җитми, ди. Кыскасы, ярты ел эчендә калкансыман биз шешенеп, авырып, кире Казанга кайттым. Мине табибларга күрсәттеләр, ә алар, биз нык азынып китәргә мөмкин, дип, тиз генә операция ясадылар. Операция вакытында тавыш ярыларына зыян килеп, бөтенләй тавышсыз калдым. Шулай итеп, укытучылыктан китәргә туры килде, Казанга кайтып, Лобачевский исемендәге китапханәгә эшкә кердем. Ул чакта Яңа бистәдә яши идек әле. Беркөнне өйгә кайтып керсәм, әти, әни, Илдар, Хисам чәй эчеп утыралар...

Шушы урында бер аңлатма. Роза ханымның әтисе Сәет Гарипов – әдәбиятчы, тәрҗемәче, Әмирхан Еники, Гомәр Бәшировлар белән бергә китаплар тәрҗемә иткән шәхес. Бөек Ватан сугышыннан исән кайткан ветеран, табиблар ялгышлыгы белән, операциядән соң үлеп киткән.

– Безне Яңа Бистәдән Борисково бистәсенә күчергәннәр генә иде. Әти андагы йортыбызда бер генә кич кунып калды, – ди Роза апа. – Хисамны мин әтигә охшаттым. 1959 елның башында язылыштык. Миннән: «Ничек аяксыз кешегә кияүгә чыктың?» – дип сорыйлар иде. Нигә чыкмаска?! Эчми, тартмый, укымышлы... Фатиры да бар. Әйтәм ич, әтигә охшаттым. Мин бит 1928 елгы. Безнең чордашлар сугышта ятып калды. Исән-сау кайтканнарның да күбесе эчә, тарта иде.

**– Ничек яшәдегез, Роза апа?**

– Матур яшәдек. Ике ул үстердек. Хисам эчмәде, тартмады, сугышмады, азып-тузып йөрмәде. Без Илдар Юзеевлар белән ун ел бер коммуналкада күршеләр булып тордык. Дөрес, күп вакытны Борисководагы йортыбызда үткәрә идек. Тавыклар асрап, бакча утыртып яшәдек. Хисам андый эшләрне бик яратты. Аның авылына да кайтып йөрдек. (Татарстанның Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылы – авт.). Ул беренче китабы чыккан акчага авылында таш йорт салдырган. Аяксыз булса да, печән чорында аның кайтуын көтеп алалар иде. Минем ачуым да килә иде хәтта. Шул хәлендә дә печәнгә йөрде. Әллә ни печән чаба алмаса да, печәнчеләргә булыша иде. Үз бакчабыз булгач, авылга кайтуыбыз сирәгәйде. Әтисе үлгәч, Хисам анда башка кайтып йөрмәде инде. Бакчабыз Гариф Ахунов, Лирон Хәмидуллин, Туфан Миңнуллиннар белән бер тирәдә иде. Хисам ярата иде бакчаны. Култык таягында булса да, шулкадәр оста итеп печән чаба иде.

**– Малайлар ата тәрбиясе күрдеме соң? Әллә язучы кеше кәгазьләреннән баш күтәрмәдеме?**

– Балаларны бик карашты. Дәресләрен дә тикшерә иде, шахмат уйнарга да өйрәтте. Математикадан бик башлы иде ул. Балалар да аңа охшаганнардыр инде. Икесе дә КАИ тәмамладылар. Хәзер балалар үзебезне дә бик карыйлар.

**– Кайчаннан урын өстендә инде Хисам ага?**

– Биш ел элек инфаркт кичерде. Шуннан бирле урын өстендә. Соңгы арада бик ябыкты да. Теге Губкин урамындагы фатирыбызда торсак, күптән үлә идек инде. Анда тәрәзә ачарлык та түгел – йортыбыз юл буенда иде. Бу фатирыбызда дүрт ел яшибез. Иркен, һәрчак һавасы саф. «Теге фатирыбызны сагынасыңмы?» – дип сорыйм Хисамнан. «Юк» – ди. Җиденче катта булса да ризалаштык. Өстәрәк тузан да азрак. Йорт янында каенлык... тик чыгып йөреп кенә булмый.

**– Сезгә сугыш турында сөйли идеме?**

– «Безне өйдә көтәләр» әсәрендә Әнвәр дип үзен яза ул. Госпитальдә ел ярым яткач, чыгаралар. Ул кистереп: «Авылга кайтмыйм» – ди. Аяксыз килеш анда өйдәгеләргә җәфа буласы килмәгән инде. Бөгелмә педучилищесына укырга керә. Фронтовик буларак, көнгә бер әбәт ашаталар, айлык паек итеп ике чиләк бәрәңге белән үпкә-бавыр колбасасы бирәләр. Шуннан аш пешереп тамагын туйдыра. Шулай итеп, укуын «5»кә генә тәмамлап, Казанга килә һәм пединститутка укырга керә...

Язучының туган көнендә ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Эльвира Камалова Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медален һәм акчалата бүләк тапшырды.

**– Роза апа, язганда сезнең белән киңәшә идеме?**

– Әйе, гел киңәшә иде. Шулай итсәң ничек булыр икән, дип киңәшләремне бирә идем. Әмма ул барыбер үзенчә эшли иде.

**– Быел да Хисам аганың бер китабы чыгып килә икән. Сезнең тырышлыктыр инде?..**

– Быел чыгып килгән китабы «Ачы җиләк» дип атала. 2013 елда «Мәхәббәт хакы» дип аталган китабы басылып чыкты. 2015 елда «Рухият» нәшрияты фронтовик язучыларның әсәрләреннән «Соңгы һөҗүм» исемле китап чыгарды. Анда да Хисамның әсәрләре кертелде. Аның әле басылмаган әсәрләре дә байтак. «Хыянәт» дигән романы ята, сәхнә әсәрләре бер дә каралмаган. Мин, әкренләп редакцияләп, басмага биреп тора идем. Хәзер үзем дә авырыйм шул... Хисамның почеркы бик начар. Җайлы гына укып чыгып булмый. Операциядән соң күзләрем дә начар күрә башлады. Сеңелем, Хисам абыеңны ашатырга вакыт җитте...

**P.S.** Нинди бай Интернет киңлекләрендә Хисам ага белән бер генә интервью да булмавы минем өчен бүгенге көннең иң күңелсез яңалыгы булды. Безнең – журналистларның игътибарсызлыгы инде бу. Соңгарак калганбыз. Ул әле сөйләшкәндә...

PRESSA.RU

# ТАТАРСТАН

**«Татарстан»** журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә

Индекс **П 2381** – татар телендә: алты айга язылу бәясе **892 сум 32 тиен**
Индекс **П 2378** – рус телендә: алты айга язылу бәясе **892 сум 32 тиен**



Ф.СП-1

Почта России

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал — П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания) — количество комплектов:

на 2016 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | ✓ | ✓ | ✓ | ✓ | ✓ | ✓ |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на ~~газету~~ журнал — П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания)

Стоимость: подписки 892 руб. 32 коп.; переадресовки ___руб.___коп. — количество комплектов:

на 2016 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | ✓ | ✓ | ✓ | ✓ | ✓ | ✓ |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

Шулай ук электрон почта аша да язылырга мөмкин:
**milyaushanb@tatmedia.com**
Дистрибуция бүлеге хезмәткәрләре, шалтыратып, кызыксындырган сорауларыгызга җавап бирерләр.

Яки түбәндәге телефон буенча тарату бүлеге җитәкчесе Миләүшә Байрашевага үзегез шалтырата аласыз: **тел. +7 (843) 222 09 79**

# МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

**БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:**

Иң тәмле кыстыбыйны **КАЙДА** пешерәләр

Биләр мәчете турында без **НИЛӘР** беләбез

Иң яхшы балалар язучысы Татарстанның **КАЙСЫ** авылында укытучы булып эшләгән

Кече ватан патриотлары **КАЯ** юл тота

PRESSA.RU

Cappuccino
«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
Caffé latte
Yellow bourbon
Caffé latte

# *Татарча* ФАСТ-ФУД

Моннан ун ел элек Казанда күпләп тиз туклану челтәрләре ачыла башлады: шаурма, кызган тавык, пицца саталар иде. Бүгенге көндә исә лаваш эченә тавык итен төрүчеләрне сирәк очратабыз. Әмма, җылы урын хуҗасыз булмый, дигәндәй, соңгы арада Казанда ипи, кабартма сату үзәкләре артты. Алай гына да түгел, әлеге сату нокталарында безгә шулкадәрле якын булган өчпочмакларны, вак бәлешләрне, пәрәмәчләрне һәм кыстыбыйларны очратырга да була. Шунысы шатландыра: мәркәзебездә көньяктан килгән кунак ризыкларын түгел, ә үзебезнең татар ашларын яратып ашыйлар. Хәер, Казанда гына кыстыбыйлар һәм өчпочмаклар фаст-фуд рәтендә йөри дип әйтү дөресме икән соң?

Автор:
Айсылу Хаҗиева

### ИСЕМЕҢНЕ КЕМ КУШТЫ?

Кыстыбыйны тиз арада пешерелә торган ризыклар рәтенә кертәләр. Ләкин бу чынлыкта шулаймы соң? Пешереп караган кеше, шунда ук башын селкеп, «билгеле инде, юк» дип җавап бирер. Иң элек камырын басарга, аннары бәрәңге боламыгы әзерләргә һәм инде соңыннан майлап чәй янына чыгарырга. Камыры бер генә төрле була икән: төче камыр. Ә эчлекләргә килгәндә, вариантлар шактый: төйгән бәрәңге, тары боткасы, төйгән киндер орлыгы һәм хәтта ки мәк!

Өчпочмак өч почмаклы булганга шулай атала, бөккән – бөгеп ясалганга, ә кыстыбыйга исемне кем һәм ни өчен кушкан? Билгеле, халык. Кабартма эченә нинди дә булса эчлек «кыстырып» пешерелгәнгә күрә, әлеге ризыкны КЫСТЫбый диеп атаганнар. Ләкин шунысын да әйтергә кирәк, кайбер районнарда кыстыбый өчен пешерелә торган кабартманы күзикмәк дип атыйлар, ә икенче бер өлкәләрдә кыстыбый сүзе гомумән таралмаган һәм анда тулаем шушы ризыкны күзикмәк дип атау гадәткә кереп калган. Бу очракта тарихи китапларга мөрәҗәгать тә итәргә кирәк түгел, нибары Саба һәм Азнакай якларыннан булган танышларыгыз белән аралашу да җитәчәк. Ә инде татар халык ашларының килеп чыгышын тикшерергә алынсак, монда да барысы аңлаешлы.

Кыстыбый эчлекләре вакыт узу белән үзгәрсә дә, камыр рецепты үзгәрешсез калган, дип әйтеп була. Элек-электән әбиләребез кыстыбый камырына чүпрә салып кабартмаганнар, төче камыр ясый торган булганнар. Шуңа да бу ризык татар халкында тиз пешерелә торганнар рәтенә кергән дә инде. Ә инде эчлекләргә килгәндә, мине шаккатырганы шул булды: борынгы вариантта кыстыбый эченә тары боткасы, киндер орлыгы сала торган булганнар. Нибары XIX гасырда гына, бәрәңге үстерү киң җәелеп киткәч, кыстыбый эчлекләренең исемлеге артып, үз рәтләренә бәрәңгене дә алганнар. Кыстыбыйны аерым бәйрәмнәргә, кунаклар өчен пешергәннәр дип әйтеп булмый, мондый мәгълүмат юк. Бу татар ашы көндәлек ризыклар рәтендә йөргән, хәер бүгенге көндә дә шулайрак бугай. Иртәнге аш янына коймак пешерелә торган булса, төшке аш җиткәндә, өйләрдә кыстыбый исе тарала торган булган.

### ЕВРОПА ТӘРӘЗӘСЕННӘН ӨЧПОЧМАК САТАЛАР?!

Кыстыбый пешерер өчен ерак авыл-районнарга барырга туры килмәде, Казанда гына очраштык. Нәкъ менә очраштык сүзе урынлы булыр, чөнки бүгенге хуҗабикәбез бер урында гына утырырга яратмый. Гыймадиева Виктория Виктор кызы тумышы белән Санкт-Петербургтан, анда 5 ел торганнан соң, Азнакайга кайтып төпләнәләр, ләкин Викториягә 18 тулу белән, күңеле романтика, маҗаралар таләп итә башлый һәм ул кабаттан төньяк башкалага юл тота. Шулай өстән-өстән генә биографиясен сөйләп узар идек тә, ләкин мөһим бер фактны күз уңыннан төшереп калдыруыбыз бар.

Виктория Азнакайда яшәгән вакытта повар-кондитер һөнәрен үзләштерә, бүгенге хуҗабикәбез дипломлы пешекче, димәк ки. 2005 елда ул Петр I карары белән салынган шәһәргә чыгып китә. Күңел маҗаралар таләп итсә, кесә акча сорый, шуңа да ул алман ашлары ресторанына урнаша. Шунысын да әйтик, Виктория фикеренчә, Германиядә тәмле итеп ашый белмиләр. Әче кәбестә, колбаса-сосиски – аларның халык ашлары. Шуңа да ул анда озакка калмыйча, икенче бер ресторанга күчеп, белемен арттыра һәм 5нче разрядлы аш-су остасына әйләнә. Үземнең дә Питерда булганым булса да, шушы зур шәһәрдә озак вакыт яшәгән танышымнан төпченеп сорарга керештем: «Татар

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

ашларын сагынып, еш пешергәнсеңдер инде», – дим. Ул исә: «Пешергәли идем, ләкин Питерда да өчпочмаклар адым саен сатыла. Ул анда, нәкъ бездәге кебек, фаст-фудлар рәтендә йөри», – дип, мине шаккатырды. Шулай итеп, Европага тәрәзә булган шәһәрдә татар халык ашлары популяр булып чыкты. Өчпочмак белән горурланудан сулышлар иркенәеп, борыннар күтәрелеп китте. Ләкин Виктория сөйләп бетермәгән булган икән әле: «Өчпочмак – айсбергның очы гына, Питерда татар халык ашлары рестораннары да шактый», – дип, минем болай да җәелгән елмаюымны колакка кадәр җиткерде.

Өйгә кайтып, Интернетта эзләнә башладым. «Санкт-Петербургта татар ашлары» дип сорау бирүгә, дистәләгән җаваплар чыгарды виртуаль дустым. 2011 елда Питерда татар рестораннары бер-ике генә булса, бүгенге көндә аларның саны шактый арткан. Алай гына да түгел, татар ризыкларын китереп бирү һәм кыстыбый, кабартмалар пешереп сатучы тиз туклану челтәрләре дә, чынлап та, күп!

## БӘРӘҢГЕ КЫСТЫБЫЕНЫҢ ИКЕ ВАРИАНТЫ

Сөйләшә-сөйләшә, кыстыбый пешерергә керештек. Виктория аңлата, мин язып барам. Әйткәнемчә, кыстыбый камыры элек-электән төче камыр булган. Бу гадәтне пешекчебез дә бозмады. Ләкин әбиләребезнең камыр басуыннан Викториянеке аерылып торды. Иң элек 1 данә йомырка алып, аңа эреткән сыер мае кушты да бераз гына тоз да өстәде. Шунда ук шушы катнашманы венчик белән болгата башлады. Соңрак камырга он өстәргә кереште, ләкин тимер ярдәмчесен бер читкә алып куймады, ә һаман да венчик белән болгатып, камыр изде. «Ә ник венчик кулланасың? Камырың катыланып китмиме яисә артык йомшак булмыймы соң?» – дигән соравымны хуҗабикәбез көткән икән. «Венчик белән эшләргә гадәтләнгәнмен, кул белән камыр басканым юк, миңа болай җайлы», – дип җавап кайтарды. Башкалардан аерылып тору, күрәсең, дипломлы пешекче булудан килә торгандыр.

Камыр чынлап та уңды. Шунысын да искәртик, камыр, пилмән камыры кебек, йомшак булырга тиеш. Пешекчебез камырны «ял иттерергә» кирәк дип, өстенә полиэтилен пакет каплап, бер читкә алып куйды. Вакытны заяга уздырмас өчен, эчлек ясарга керештек. Шунысы кызык, тарихи китапларда татарлар кыстыбыйны тары ярмасы белән пешергәннәр диюгә карамастан, мин дә, бүгенге пешекчебез дә андый ризыктан авыз иткәнебез булмаган. Ләкин пешекчебез аның рецептын белә: тары боткасы пешеп җитүгә, аңа сыер мае кушасың да эчлек әзер! Әмма бүген без бар төбәкләрдә дә яратып ашала торган бәрәңгедән пешерергә булдык.

Бәрәңге боламыгын ясап бетерүгә, Виктория, плитәгә таба куеп, сыер мае эретә башлады. Мин «кыстыбыйны майларга иртәрәк шикелле» дип уйлап утырганда, Виктория әлеге майга вак итеп турап суган чумдырды. Ә үзе сөйли: «Элек зәйтүн майлары кулланып пешермәгәннәр бит, шуңа да сыер маенда кыздырам. Аннары, болай эшләгәндә, ул матур сары төскә кереп кыза», – ди. Ә мин барыбер аптырап утырам, безнең гаиләдә пешерелә торган кыстыбый-

Безгә кирәк булачак:

Фото: Ната Смирнова

1. Туглыйбыз!

2. Җәябез!

3. Кисәбез!

4. Изәбез!

5. Ягабыз!

6. Майлыйбыз!

лар сугансыз була, шуңа да Викториянең суган кушуы минем өчен беренче ачыш булды.

Икенче ачыш – ул икенче вариант. Әгәр дә ашказаныгызга кызган ризыклар ярамый икән, бу очракта суганны атланмай белән кыздырмаска, ә сөт белән кайнатырга була икән. Бер кәстрүлгә саласың пешкән бәрәңгене, туралган суганны, өстисең сөт белән май. Сөт кайнап чыкканчы, шушы ингредиентларны плитәдә биетәсең. Сөт күтәрелә башлагач, уттан алып, бәрәңге боламыгы ясыйсың. Эчлек әзер дә бугай инде... Кабаттан кулга камырны алып, аны басарга керештек. Камырны кечкенә кисәкләргә бүлеп җәяргә кирәк булыр, ләкин Виктория моның белән генә чикләнеп калмады, ул, уртача бер тәлинкә куеп, шуның буенча түгәрәкләп камыр кисеп алды. «Матур булганда рәхәт», – диде дә елмайды үзе. Шулай җәеп кисә торды, табада кайберләре кыза да башлады.

Әзерләрен тастымал белән капларга да онытмады: «Артык озак кыздырсаң, камыры ката һәм сына башлый. Шулай тастымал белән каплап торгач, камыры да йомшаграк була», – дип сөйли-аңлата үзе. Аш бүлмәсенә шушы мизгелләрдә Викториянең ире дә кереп-чыккалый башлады. «Әһә, тамагы ачкан икән», – дим. Виктория исә: «Тикшерә», – дип, мине кабат шаккатырды. Баксаң, Викториянең тормыш иптәше дә ашчы икән. Алар икесе дә дипломлы пешекчеләр. «Гаиләдә дә тормыш иптәшем шеф-повар булса, мин – су-шеф», – дип шаярта Виктория. Аш бүлмәсендә сугышып ятмас өчен, үзләренә яңа төр эш ачканнар. Кейтеринг белән шөгыльләнәләр икән. Ягъни мәсәлән, заказга ашарга пешерәләр. Туйның икенче көнен табигать кочагында үткәрәсең киләме? Әмма ашарга пешереп йөрисең килми? Шул вакытта Виктория һәм аның тормыш иптәше, мультфильмдагы Чип һәм Дейл шикелле, ярдәмгә ашыга. Яшьләрнең яшьләрчә инде.

## АМЕРИКАНЫҢ – ҮЗЕНЕКЕ, БЕЗНЕҢ – ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

Шулай сөйләшә торгач, күзикмәкләребез пеште, бәрәңге боламагы әзер, май эретелгән, барысын бергә җыясы гына калды. Шул вакытта аш бүлмәсендә янәдән Викториянең тормыш иптәше пәйда булды. Ә мин исә бераз гына сораштырырга ният иттем: «Кыстыбыйны, сезнеңчә, нинди очракларда пешергәннәр?» Ул җавапны Америкадан башларга булды: «Сэндвич дигән ризыкны һәркем дә белә, аны безнеңчә бутерброд дип тә атыйлар. Кайдан килеп чыкканын гына белмиләр. Ә ул Америкада уеннар уздыручы бер бинада барлыкка килгән. Бер бик бай ир-атның покер уйнап утырган вакытта тамагы ача. Шунда аңа салат һәм ипи китерәләр. Ләкин, уеннан аерылып, салат ашап утырып булмаганга күрә, ул шушы салатны ике ипи кисәге арасына тутырып ашый. Шуннан сэндвичлар киң тарала башлый да инде. Кыстыбый да нәкъ шул принцип буенча барлыкка килгәндер дип уйлыйм...»

Ире сөйләгән арада Виктория кыстыбыйларны әзерләп тә куйган иде, нибары чәй хәстәрлисе генә калды.

Ә хәзер инде без, ике рецептны чагыштырып, дистәләрчә еллар эчендә татар халык ашлары күпне кичереп, нык үзгәргәнме, юкмы икәнен белербез.

Төче камырны басалар. Чиста савытка су яки сөт салалар да, шикәр комы, тоз, йомырка, май өстәп, әйбәтләп болгаталар. Аннары иләгән он салып, камырны кулга йә савытка ябышмый башлаганчы басалар. Азрак кабаргач, 75 граммлы кисәкләргә бүләләр һәм, җәеп, кызган коры табада башта – бер ягын, аннары икенче ягын пешереп алалар. Әзер җәймәләрне, йомшак булсын өчен, тастымалга төреп куялар.

Эченә салу өчен бәрәңге боламыгы әзерлиләр, кайнар сөт, эреткән май, майсыз гына кыздырган башлы суган салып, барысын бергә болгаталар.

Җәймәнең яртысына бәрәңге ягалар да икенче яртысы белән каплыйлар. Бөкләнгән җирдән сынмасын өчен, кыстыбыйны кайнар килеш ясарга кирәк.

Кыстыбыйның өстен эреткән май белән майлап, табага тезәләр, каплап 10–15 минутка духовкага куялар. Кыстыбыйны кайнар килеш ашыйлар, аерым савытка салып, эреткән атланмай куялар.

PRESSA.RU

# БИЛӘРНЕҢ ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ

**Шәһри Болгарның XIV йөздә төзелгән Җәмигъ мәчетен белмәгән кеше юктыр бүген. Күпләрегез аны барып та күргәндер, ерак бабаларыбызның кул җылысын саклаган борынгы таш диварларын сыйпап, күңелен сафландыргандыр, җанына сихәт алгандыр.**

Автор:
Фаяз Хуҗин

Ә менә Биләрнең изге туфрагында сакланып калган Җәмигъ мәчете хәрабәләре турында белүчеләр бар микән? Биләр урманындагы Хуҗалар тавына «Изге чишмә» суын эчәргә килүчеләр арасында әлеге сорауга уңай җавап бирүчеләр сирәк очрый. Кызганыч, әлбәттә. Югыйсә, Биләр мәчете тагын да борынгырак һәм, архитектура тарихын өйрәнүчеләр фикеренчә, Болгар мәчетен салганда үзенә күрә бер өлге булып хезмәт иткән.

Эчке шәһәрнең үзәгендә урнашкан булган ул мәчет. Без, профессор Альфред Халиков җитәкчелегендәге бер төркем археологлар, бирегә 1972 елның җәендә беренче тапкыр аяк басканда, җир өстендә аның эзләре дә күренми иде. Ә менә мәчет хәрабәләре турында XVIII–XIX йөз сәяхәтчеләре язып калдырган мәгълүматлар сакланган.

### ТАРИХ НИ СӨЙЛИ?

Моннан 200–250нче еллар элек мәчетнең биек манарасы ерактан ук күренеп торган икән әле. Мәсәлән, «урыс тарихының атасы» Василий Татищев (1686–1750) үзенең «История Российская с древнейших времен» дигән китабында борынгы Биләр каласы урынында сакланып калган таш бина хәрабәләре турында яза. Алар арасында, ди ул, үзенең элеккеге данын һәм бөеклеген әле һаман да югалтып бетермәгән бер бина, галимнең үз сүзләре белән әйтсәк, *«портал, или врата великого храма и столп»* һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Ягъни манарасы («столп») һәм фасад стенасыннан бераз алга чыгарып эшләнгән Шәрык архитектурасына хас «П» рәвешле төп ишеге («портал, или врата») булган ниндидер зур мәчетнең («великий храм») хәрабәләре була инде ул.

Биләр җирлегендә 1769 елда тикшеренүләр алып барган тарихчы һәм сәяхәтче Николай Рычков та әлеге мәчетнең манарасына сокланып карап торган. «Сакланып калган биеклеге 5–7 аршинга җитә торган әлеге манара таштан һәм кызыл кирпечтән салынган, стенасы исә яшел һәм зәңгәрсу төстәге чынаяк плитәләр белән капланган булырга охшый», – дип яза Рычков.

Әлеге сүзләрне 1832 елда Биләрдә булып киткән язучы һәм публицист, Казанда чыга торган «Заволжский Муравей» журналы нәшире Николай Рыбушкин да кабатлый. «Хәрабәләренә карап фикер йөртсәң, – дип яза ул, – бу мәчет Болгарныкына караганда күпкә зур булгандыр».

XIX йөз урталарында мәчетнең эзе дә калмый диярлек. Ташларын, манара нигезендәгеләренә кадәр, тирә-юнь халкы хуҗалык кирәк-яракларына ташып бетерә. Кайчандыр изге урын саналган җирләрне әкренләп сөрә башлыйлар.

### «МӘЧЕТ БУ, ЕГЕТЛӘР, АЧЫШЫГЫЗ БЕЛӘН КОТЛЫЙМ!»

Күз алдына китерегез: Биләрнең эчке шәһәрен иңләп алган киң басу, игеннәр өлгереп килә. Без басып торган җир бераз калкурак. Игътибар беләнрәк карасаң, бу калкулыкта берән-сәрән аунап яткан таш кисәкләрен абайларга мөмкин. Туфрагы да тирә-юньдәге кебек кара түгел, көлсу, известьмы-көлме кушылган. Төзелеш калдыклары, дип аңлатты җитәкчебез Альфред Хәсәнович. Без менә шунда, бик киң мәйданда, казу эшләре үткәрергә тиеш.

Шуны да искәртәсем килә: безнең аста нинди бина ятканын алдан ук фаразлау мөмкин түгел иде. Безгә бит берәү дә аның төгәл урынын билгеләп калдырмаган. Мәчет икәнен соңыннанрак ачыкладык.

20–30 сантиметр калынлыктагы беренче катламны алып ташлауга ук, биредә зур бина хәрабәләре ятка-

Фотолар автордан алынды

ны аңлашылды. Тирәнрәк казып төшкәч, аның планы да ачыклана башлады. Турыпочмаклы бина булган, эчендә колонна эзләре. Гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан да артыграк булыр кебек. Менә шул хәлдә беренче сезонны тәмамлап, төп эшләрне киләсе елга калдырып, экспедициябез Казанга кайтты. Беренче елның эш нәтиҗәләре турында археологларның Мәскәүдә ел саен чыгып килә торган экспресс-җыентыгына кечкенә мәкалә язарга кирәк иде. Альфред Халиков, әле Биләрдә чакта ук, без казый торган объект хан сарае булырга тиеш, дип йөрде. Шул ук вакытта профессорыбыз моның коры фараз икәнен дә яшермәде.

Киләсе елның җәй башын без тагын шул ук казылмаларда каршыладык. Казу мәйданын төньяк-көнбатышка таба ярыйсы гына киңәйттек. Бу урында рәт-рәт багана чокырлары китте. Башта безнең җитәкчебез, болары – хан сараен уратып алган агач стена эзләре түгелме икән, дип уйлаган иде. Бераздан бу фикердән баш тартырга туры килде. Багана эзләре зур гына турыпочмак мәйдан хасил итәләр иде.

Альфред Хәсәнович архитекторларга мөрәҗәгать итәргә булды. Ике-өч көннән Биләргә борынгы архитектура корылмаларын реставрацияләү буенча атаклы



Биләр мәчетенең таштан салынган өлеше. Х гасыр ахыры. Нияз Халит реконструкциясе.

PRESSA.RU

«Бай феодал йорты» нигезе.

белгеч, архитектор Сәйяр Ситдыйк улы Айдаров килеп төште. Без ачкан объектларга бер генә күз төшерде дә, озак уйлап тормастан, соңгы сүзен дә әйтте:

– Мәчет бу, егетләр, ачышыгыз белән котлыйм! Ике өлештән тора: бусы – таш мәчет, ә тегесе, багана эзләре генә сакланганы – агач мәчет.

Һәм бик тә гади, ышандырырлык итеп, исбатлап та бирде. Без шаклар катып, ике олы галимнең сөйләшкәнен тыңлап, бер читтә басып тордык, Альфред Хәсәнович, шатлыгыннан нәрсә эшләргә белмичә, очып-канатланып дигәндәй, архитектор дусты белән (алар, чыннан да, күптәнге дуслар иде) казып чыгарылган объектларга яңа күзлектән карап бәя бирә башлады:

– Кайсы якка карап тора бина? Дөрес, кыйблага. Бердәнбер колонналы зал ни өчен? Әйе, гыйбәдәт кылу өчен. Болгар ханының кабул итү залы түгел ул. Менә монда михраб урыны булырга тиеш. Ә манарасы кайда? Манарасыз мәчет булмый ич.

– Җир астында әле ул. Менә бу тирәдәрәк булыр кебек.

Шул ук көнне, җитәкчебез кушуы буенча, казылмаларны тагын бераз киңәйттек. Бер атнадан безнең алда мәчет стенасыннан 1,5 метрга читкәрәк китеп салынган турыпочмаклы (7,2 х 6,6 м) таш манара нигезе пәйда булды. Нык торган – котлованының тирәнлеге генә дә 3 метрга җитә.

Менә шулай. Хәзер инде мәчетебезгә тагын бер тапкыр күз төшерик.

Без казып чыгарган бинаның нигез эзләре генә сакланып калган. Шулай да бик ачык күренеп тора: заманында ул ике өлештән торган. Баштарак, X гасырның беренче яртысында, зур гына агач мәчет салып куйганнар. Ул 1420 квадрат метр мәйданда урнашкан. Аннан соң, шул ук гасырның ахырларында, агач мәчеткә терәтеп, яңасын җиткергәннәр. Ак таштан. Ул 1076 квадрат метр мәйданны били. Таш мәчетнең эчендә 6 рәт колонналар төзелгән (һәр рәттә дүртәр колонна, аларның нигезе – стилобатлар гына сакланган). Көньяк-көнчыгыш стенасы тыштан ярымколонналар – пилястралар белән бизәлгән.

Бу – Идел Болгарстанында археологлар тарафыннан ачылган бердәнбер мәчет. Шәһри Болгардагы XIV гасыр мәчетеннән зуррак. Биләрнең үзәгендә, хан сарае тирәсендә урнашкан. Болгар иленең үзәк мәчете булып торган дисәк тә дөреслеккә хилафлык китермәбез кебек.

Биләр мәчетенең иң борынгы өлеше. Нияз Халит реконструкциясе.

## «БАЙ ФЕОДАЛ ЙОРТЫ»

Агач мәчет янында ике катлы кирпеч йорт торган. Без аны, шартлы рәвештә, «бай феодал йорты» дип атадык. 1971–1972 елларда казып тикшергән идек. Ул бина X йөз ахырларында төзелгән булып чыкты. Беренче катта дүрт бүлмәсе бар. Һәрберсенең мәйданы 16 квадрат метр. Йорт идән астыннан үткәрелгән махсус каналлар буйлап йөрүче эссе һава белән җылытылган. Биредә, күрәсең, үзенең гаиләсе белән югары дәрәҗәле берәр дин әһеле яшәгәндер. Әлеге бина җәмәгать мунчасы булмадымы икән, дип фаразлаучы галимнәр дә бар. Шәрык илләрендә мәчет янына, намаз алдыннан тәһарәт алып чыгу өчен, мунчасын да салып куя торган булганнар, имеш. Ай-һай, агач бинага терәтеп диярлек урнаштырырлар иде микән ул мунчаны?

Җәмигъ мәчетенең көнчыгыш ягында мәйданы ягыннан артык зур булмаган зират урнашкан. Биредә 50ләп кабер тикшерелде. Үлгән кешеләрнең кайберләре кирпеч төрбәләр эчендә ята иде. Барысы да саф мөселман йоласы буенча җирләнгәннәр. Антропологларның әйтүенә караганда, монда күмелгән кешеләр баш сөякләренең төзелеше ягыннан гади кешеләрдән бераз аерылып торганнар (монголоид сыйфатлары күбрәк). Бу – болгар ханнарының, аларның якыннарының, гомумән, югары катлау кешеләренең каберләре булырга тиеш. Шәһәр уртасында, Җәмигъ мәчете янында, махсус төрбәләрдә гади кешеләрне күммәсләр, шәт.

## МӘЧЕТ КАЙЧАН ТӨЗЕЛГӘН?

Һаман мәчет турында уйланам. Аның агач өлеше соңрак, таш бина төзелгәннән соң, мәдрәсә булып хезмәт итмәдеме икән? Ә мәчет үзе, бәлки, 922 елда, Болгар иленә Багдад илчелеге килгәч төзелә башлагандыр?

Шул елда бит болгар ханы ислам динен рәсми рәвештә кабул итә. Хәтерегезгә төшереп үтәм: 920 елда Алмыш хан (мөселманча исеме – Җәгъфәр ибн Абдаллах) Багдад хәлифәсе Мөкътәдиргә язган хатында аннан Болгарга, беренче чиратта, халыкка ислам динен һәм шәригатен өйрәтерлек галимнәр, аннан соң, дошманнар һөҗүменнән саклану өчен кальга – ныгытылган шәһәр салып бирергә сәләтле оста төзүчеләр җибәрүне үтенә. Белгәнегезчә, аның бу теләкләре кабул ителә, хәлифә хәзрәтләре тарафыннан Багдадтан Болгар иленә зур илчелек җибәрелә. Ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгәннән соң (бу тантаналы вакыйга 922 елның 16 маена туры килә), күп булса, атна-ун көн вакыт та үтмәгәндер, Җәгъфәр ибн Абдаллах үзенә буйсынган кабилә башлыкларын һәм аларга буйсынган халыкны (кулларына балта-пычкы тотарга сәләтле ир-атны, дип уйларга кирәк) яңадан җыя һәм алар көнчыгыш тарафка, Җаушыр елгасы тирәсенә юнәләләр. Барып җиткәч, биредә ике ай чамасы булалар. Нишлиләр? Төгәл генә әйтеп булмый, ә фаразлар бар.

Җаушырны күп кенә галимнәр Кече Чирмешән елгасы белән тәңгәлләштерә. Бу чыннан да шулай булса, Болгар ханы һәм гарәп илчелеге әгъзалары белән килгән халыкны – төзүчеләрне кальга корырга һәм мәчеткә нигез салырга дип алып килмәгәннәр микән? Мин бу

сорауга, археология материалларына таянып, уңай җавап бирер идем.

Югарыда әйтелгәнчә, агач мәчетнең төзелә башлау вакыты X гасырның беренче яртысына карый. Профессор Альфред Халиков үзенең хезмәтләрендә әлеге мәчетнең тагын да борынгырак чорга, IX гасыр ахырына караган булу ихтималын да искәртеп үткән иде. Һәрхәлдә, 922 ел – болай гына уйлап чыгарылган дата түгел.

Тагын бер кызыклы фактка игътибар итик. Мәчет тирәсендә гади кешеләр яши торган агач (бура) йортлар, хуҗалык корылмалары, ашлык саклау амбарлары урнашкан. Арада берничә оригиналь, безнең якларга бөтенләй дә хас булмаган торак йортлар бар иде. Аларның стенасы чыбыктан (читәннән) үрелеп, ике яктан калын итеп кызыл балчык белән сыланган. Өй эчендә, хәтта ишегалдында да, тандыр тибындагы мичләр. Баш ватып та торасы юк – биредә, һичшиксез, Урта Азия якларыннан, Шәрык илләреннән килгән кешеләр яшәгән. Ирексездән, Багдад илчелеге белән килгән төзүчеләр түгел микән, дип уйлап куясың.

### САКЛЫЙ АЛЫРБЫЗМЫ?

1976 елда, казу эшләре төгәлләнгәннән соң, мәчет урынын һәм «бай феодал йортын» бераз рәткә китереп, архитекторлар Сәйяр Айдаров һәм Фәридә Зәбирова эшләгән проектка таянып, консервацияләп куйдылар. Ул вакытта әле «Изге чишмә» турында уйлаучы да юк иде. Халык Биләр хәрабәләрен, Җамигъ мәчет урынын карарга килә иде. Вакытлар үткән саен консервацияләп куйган борынгы биналарыбыз җимерелә башлады, элеккеге матурлыкларын югалтты.

Ике дистә еллап вакыт үткәннән соң, 1997 елда, «Татнефть» берләшмәсе, зур чыгымнар белән санашмыйча, Хуҗалар тавын, «Изге чишмәне» төзекләндерү буенча киң күләмле эшләр башлап җибәрде. Биләр археологиясе музее да төзеп куйдылар хәтта. Чишмә тирәләре танымаслык булып үзгәрде.

Җимерек хәлгә килгән Җамигъ мәчетне яңадан бер мәртәбә консервацияләделәр. Әмма ул, йомшак кына әйткәндә, уңышсыз чыкты. Бүген анысы да ташландык хәлдә. Бирегә хәзер экскурсияләр дә оештырылмый. Биләр дәүләт тарихи-археология музей-тыюлыгы да, Алексеевск муниципаль районы җитәкчеләре дә, республикабызның Мәдәният министрлыгы да бу хәлгә борчылмыйлар. Борынгы болгар бабаларыбызның монгол яуларына кадәр үк төзелгән уникаль архитектура ядкәрләренә мондый караш безне гаҗәпләндерә. Музей-тыюлыкның иң беренче бурычы шул һәйкәлләрне саклау һәм халыкка күрсәтү түгелмени?

**Биләр мәчете хәрабәләре казу эшләре тәмамланганнан соң.**

Биләр мәчете хәрабәләре. Консервациядән соң.

PRESSA.RU


# Язып һәм телевизор от!

**1 Языл**

30.06.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

**2 Җибәр**

язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

**3 От**

телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!

Акцияне үткәрү вакыты:18.04.2016 - 20.09.2016

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84, өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

# Соңгы кыңгырау

**Соңгы кыңгырауны укый-укый чиләнгән мәктәп укучысы кебек берәү дә көтми, дип уйлыйлар гадәттә. Хәер, элек шулай иде. Соңгы елларда аны көтүчеләрнең саны артты һәм яшь буенча өлкәнәйде. Мәктәп чорының тәмамлануын әби-бабайлар белән берлектә әти-әниләр дә, уку йортының директоры җитәкчелегендә укытучылар да көтә. Бары тик репетиторлар гына чемоданнарын Кипрга (Төркиягә юлны яптылар бит) юл тотар өчен җыя-җыя көрсенеп куя: «Эх, тагын берәр ай эшләп булса, Майоркага да җыелыр иде». Шундый мәзәк бар…**

## Мәктәп. Катнашучылар:

Иң яхшы УКЫТУЧЫ –
укытучылардан уңуы турында.

Иң битараф түгел ӘНИ –
ни өчен укытучыларга укучыларга белем бирү отышлы түгеллеге турында.

Иң объектив РЕПЕТИТОР –
ни өчен репетитордан башка белемнең булмавы турында.

Хәзерге мәктәптәге уку-укыту системасына карата памперс бәяләре кебек вак-төяккә көяләнүчеләр генә канәгатьсезлек белдермидер. Калганнарга гел нәрсә дә булса ошамый: кемгәдер БДИ тапшыру системасы, кемгәдер акча җыюлар, кемгәдер репетиторлык, кемгәдер хисаплар, кемгәдер хезмәт хаклары, кемгәдер безнең булдыксыз балалар… Әмма канәгатьсезлек һәм зарлану белән генә проблеманы хәл итеп булмый. Аек акыл кирәк. Без монда нәкъ шундыйларны тупладык та. Бу экспертларның берсе генә булмаса да, 9–11 елга сузыла торган мәктәп тормышы тулы булмас иде. Алар аның төп катнашучылары. Һәм һәркайсы үз мөнбәреннән, артык тирәнгә кермичә генә, ни өчен бүген ул шулай, ә башкача түгел икәнне аңлатып карый. Ә иң мөһиме, ниһаять, камиллеккә ирешү өчен кайсы юнәлештә хәрәкәт итәргә икәнен дә әйтә.

Фото: Александр Эшкинин

PRESSA.RU



# Укытучы укытучы турында

Дөньядагы иң яхшы УКЫТУЧЫ әле күптән түгел, нибары узган гасырда гына, Лаеш районының Емельяново авылында эшләде, дип ышандыра безне шул авыл кешеләре. Аның исеме – Юрий Коваль. Әйе, әйе, балаларның иң яраткан язучыларының берсе, «Недопесок», «Картофельная собака», «Приключения Васи Куролесова» һәм башка мавыктыргыч әсәрләрнең авторы үзе.

– Юрий Иосифович – чын укытучы иде, – дип искә ала Анна Федоровна Семенова – Емельяново мәктәбенең хәзер лаеклы ялдагы укытучысы. **– Ул үзе Мәскәүдән булса да, бик гади кеше иде. Кем әйтмешли, масаеп-нитеп йөрмәде.** Аны 1961 елда, пединститутны тәмамлагач, безгә билгеләгәннәр. Башкалар, үзебезнең Казанныкылар, киләләр дә, әле бер нәрсә ошамый аларга, әле икенчесе. Китеп тә баралар. Ә ул китмәде. Эшләде, рус телен, әдәбиятын гына түгел, географияне дә укытты, тарихны да, җыр дәресләрен дә… **Авыл мәктәбенә укытучылар беркайчан да җитмәде.**

Емельяновода Коваль турында әнә шулай кичә генә авылдан киткән авылдашлары турында сөйләгәндәй сөйлиләр – гәрчә ул биредә нибары өч кенә ел яшәгән булса да. Хәтта яше буенча ул яшәп киткән чорга туры килмәүчеләр дә белгән сыман искә ала. Әмма җентекләп сөйләтер өчен, барыбер Анна Фёдоровнага җибәрәләр:

– Барысын да укытты, минем энем Николайны да. Мин аның барлык укучыларын да хәтерлим: Юра Киришин, Николай Струков, Маша Клеткина, Надя Прохорова… Алар Ковальне бик яраттылар. Юрий Иосифович гитарада да уйный иде, җырлар да чыгара. Балалар белән шундый тамашалар куя иде – чын театрдагыдан да остарак итеп. **Төрле кагыйдәләрне истә калдыру өчен, диктантларны үзе уйлап чыгара – чәчмә формада да, шигъри телдә дә:**

*На полу сидела мышь.*
*Вдруг вбегает грозный муж*
*И, схватив огромный нож,*
*К мыши он ползёт, как уж.*

Монысы сызгыра торган авазларны дөрес язу өчен. Чын укытучы иде. Ә язучы булып киткәч, ул безнең Емельяноводагы күп кенә кешеләргә хас сыйфатларны үзенең геройларында чагылдырды. Кайберләренә исемнәрне дә дә безнекеләрдән алып куйды. Менә Маша Клеткинасы кайсыдыр бер әсәрендә бар… **Икеле капчыкларына аерым игътибар бирә иде. Аларны яхшылар рәтенә күчерде. Болай гына, бер тиенсезгә.** Алар белән дәрестән соң калып шөгыльләнә иде.

Юрий Ковальнең әсәрләрендә әле монда, әле тегендә укытучыларга юлыгасың. «Икеле капчыклары булган рецидивистларны дүртлегә укучылар» рәтенә кертергә сәләтле мәктәп укытучыларына. Тулаем, алганда, Юра укытучылардан уңды.

*Юрий Коваль*

## КЫЗЫЛ КАПКАЛАРДАН

…Безнең ишегалдында барысына да мәгълүм иде бу: мин гомеремдә дә институтка керә алмаячакмын. Моны мин үзем дә аңлыйм, абыем Боря да аңлый, укытучылар да… Ләкин дөньяда Владимир Николаевич Протопопов дигән кеше яши, менә ул минем керә алмавымны аңламый иде. Ул мине институтка укырга керә ала, дип ышана, ә мине, керә алмам да Владимир Николаевич Протопоповның ышанычын акламам, дигән уй бимазалый иде. Владимир Николаевич бөек укытучы иде. Икеле капчыгын өчлегә укучыга әйләндерү аңа берни тормый. Владимир Николаевичның кыяфәте генә дә ни тора – аның дәһшәтле сакалы һәм үткен карашы икеле капчыгын «ә» дигәнче өчле йөртүчегә әверелдерә.

Протопопов авызын ачып, аннан котылгысыз күкрәү авазы ишетелсә, яңа гына табадан төшкән өчлегә укучының дүртле капчыгына әйләнми чарасы калмый иде.

– Калганы инде Ходайдан, – дип хәл итә иде гадәттә Владимир Николаевич.

Боря абыемның, ул вакыттагы иң өметсез рецидивист икеле капчыгының, кырык алтының кара күзендә Владимир Николаевичның ничек итеп алар сыйныфына беренче тапкыр килеп керүе турында сөйләгәне бар.

Башта аларның сыйныф ишеге үзеннән-үзе калтырап куя.

Ул дулкынланудан һәм неврозданкалтырана башлый. Үзенә таба кемнеңдер якынлашуын сизә, тик кем икәнлеген генә аңлап җиткерми. Тешләре шак-шок килә, үзе тиргә бата, һәм, ниһаять, ишек дөбердәп ачылып китә.

Кашына кадәр төшереп кигән йөнтәс колаклы бүрек, бүрек астыннан корыч күзләре ялтырап тора – ишек катында Протопопов әнә шулай пәйда була.

Ул уң җилкәсенә биштәрен аскан.

Владимир Николаевич әллә нинди бер вәкарьлек белән ярым сикереп, ярым атлап укытучы өстәле янына килеп баса да дәһшәтле тавыш белән болай ди:

– Как с древа сорвался предатель ученик…

Укытучыны сәламләргә дип торып басарга өлгергән укучылар парталары янында катып кала.

Ул арада Владимир Николаевич үзе дә авыр тынлыкка чума. Аның күзләрендә соң чиккә җитеп киерелгән игътибар сизелә. Ул әйтерсең лә хыянәтче шәкертнең, күзгә күренмәс агачтан өзелеп, упкынга тәгәрәвен күзәтә.

Әлеге упкын төпсез, шуңа да тынлык күпме кирәк, шуның кадәр сузыла ала иде. Һәм әлеге очып баручы хыянәтче нәрсәгә дә булса килеп бәрелеп, чәлпәрәмә килгәнче, Протопоповның аны күзәтәчәге барысы өчен дә көн кебек ачык иде.

Һәм шунда куркыныч дөбердәү тавышы ишетелә. Протопопов иңеннән үзенең биштәрен алып куйган икән.

Шунда барысы да хыянәтченең нәрсәгәдер бәрелеп, чәлпәрәмә килүен аңлый. Бу бер мизгел эчендәге куркыныч үлем иде.

Үлемнән соң бушлык барлыкка килә.

Шушы бушлыкта нәрсәдер кыштырдый, кыймылдый башлый, тик нәрсә икәне билгеле түгел.

– Диавол прилетел, – дип пышылдый Протопопов. – К лицу его приник.

Владимир Николаевич әлеге картинага арты белән борылып баса, аның боларны күрәсе килми иде. Ләкин бу хәлләрне ничек булса да аңлатырга кирәк, һәм ул моның өчен көчле һәм яңгыравык сүзләр таба:

– …Дхнул жизнь в него, взвился с своей добычей смрадной
И бросил труп живой в гортань гиенны гладной…

Владимир Николаевич биштәрендә казына һәм аннан австриячә ике яклап үткерләнгән штыгын тартып чыгара, аннан ипи ала, ниһаять, бүреген сала. Штык белән ипи кисеп ала да ашый башлый.

Укучылар тораташ булып катып калалар.

Алар үзләренә таныш «укучы» сүзенең «хыянәтче» сүзе белән берничек тә аваздаш булмавыннан тыш, берни дә аңламый. Ә кайбер гадирәкләре бөтенләй да гади бер нәрсәгә төшенә: әгәр начар укыйлар икән, «диавол» аларга «жизнь дхать» итәчәк икән. Владимир Николаевичның кисеп алынган ипи кисәге кереп югалган сакалы исә барысы өчен дә «гортань гиенны гладной» булып тоелды.

Владимир Николаевич, ипи ашый-ашый, укучыларга хәйләкәр генә караш ташлап ала, сыйныфтагы кайберәүләргә ымлап:

– Им, гагарам, недоступно наслажденье битвой жизни… – дип мыгырдый.

Бу сүзләрдән өшеп киткән укучылар үзләрен гагара итеп хис итә, һәм аларның күбесе яшәү өчен көрәштән ләззәт алу мөмкинлегенә ия булырга теле башлый.

Владимир Николаевич үзе сыйныфны күзәтә, үзе кемгәдер көтмәгәндә генә күз кысып ала. Минем Боря абыема да күз кыскан ул. Боря бу мизгелдә шуны тоеп алган: бәлки, әле соң түгелдер, бәлки, аңа гагаралар семьялыгыннан чыгып котылу насыйп булыр.

Владимир Николаевич могҗиза ясый.

Ул Боря абыемны гагара-рецидивистлар семьялыгыннан тартып алып, аны канатлыларның югарырак отрядына – тәлләтәвечләр һәм аккошларга таба борып җибәрә.

Әти-әнием Боряның гагаралар арасыннан чыгуына бер шатланса, аларның бу шатлыгы минем һаман да гагара булып калуым аркасында тоныклана иде. Бары тик Владимир Николаевич кына миңа канат куя ала, дип саныйлар иде алар, һәм ул бу үтә дә катлаулы эшкә алынды.

Кич белән соң гына, унберләр тирәсендә, мин өйдән чыгам. Мәктәпкә. Нәкъ шунда Владимир Николаевич минем гагаралыгымның нигезен төя дә иде инде… Ул моны төнлә эшли. Көндез аның вакыты бөтенләй юк, һәм, өстәвенә, ул минем гагаралыгым төнлә аеруча канат җәя, дип саный иде.

Мин килгәндә, Владимир Николаевич гадәт буенча укытучыларның бушап калган бүлмәсендә утыра һәм дәфтәр тикшерә.

Мине күрүгә, күңелле итеп көлеп җибәрә һәм йодрыклары белән күкрәгемә суккалый.

Күкрәгемне туйганчы төеп, җанымны белем алыр өчен ачкач, Протопопов каты итеп чәй пешерә һәм төрепкәсен «Алтын йон» һәм «Флот» тәмәкесе белән тутыра.

Без чәй эчә башлыйбыз…

Аннан соң Владимир Николаевич янә дәфтәр тикшерә башлый, ә мин аңа булдыра алганча ярдәм итәм.

Протопоповның төнге дәресләренең асылы да шунда: миңа, чын икеле капчыгына, бөек укытучы иншалар тикшертә иде, ул моны миңа ышанып тапшыра, ә ул иншаларның авторлары, ихтимал, миннән өлкәнрәк тә, белемлерәк тә булгандыр.

Болай итеп Протопопов бер атуда ике куянны тота иде.

Ул, минем булган белемнәремне сыгып, игътибарлылыгымны соң чиккәчә җиткереп, үткен җаваплылык хисе тәрбияләп һәм тәвәккәллекне уятып кына калмый, ә мин тикшергән дәфтәрләрдәге кайбер мәгълүматларның аңыма сеңеп баруына да ирешә иде. Ә мин остаргач, Владимир Николаевич тагын бер куянны атып алды: мин аңа дәфтәрләрдән өелгән тауны азмы-күпме җиңеләйтергә булышам.

Ул миңа хәтта билге куярга да ышаныч белдерә башлады – икеләләр һәм дүртлеләрне. Өчле белән бишлене куярга рөхсәт итми. Моңа да ул кызыклы бер мәгънә бирә иде. Ул, әлбәттә, минем, гагаралар дусты буларак, икеләләрне яратмавымны белә. Мин чыннан да аларны яратмыйм һәм һәрвакытта да «өчлегә тартырга» тырышам. Миңа мескен гагараларга икеле кую җинаять кылу кебек тоела иде.

Өчлеләрне Протопопов миннән соң тагын бер тикшереп чыга, ә бишлеләр Аллаһтан дип санала иде, һәм монда Владимир Николаевичның бары үзе кирәк.

Дүртлене – рәхим итеп. Дүртлеләрне ул миңа ышана, бу җәһәттән безнең фикерләр гел туры килә, һәм мин моның белән горурлана идем.

Дәфтәрләрне тикшереп чыккач, мин аларны дүрт күчкә өеп куям – икеләләр, өчлеләр, дүртлеләр һәм бишлеләр.

– Укытучы! – дип шаярта шулчак Владимир Николаевич. – Синең исемең алдында баш иеп тезләнергә рөхсәт ит…

– Һәм шуннан соң ул минем арттан өчлеләрне һәм бишлеләрне тикшереп чыга. Минем тарафтан киткән берәр хилафлыкка яки ялгышка килеп төртелсә, канәгатьсезлек белдереп мыгырдый:

– Гагаралык… – Һәм тырнагы белән минем хата киткән урынны тырнап, астына сызып куя.

Минем хилафлык яки ялгышымны Протопопов беркайчан да йодрыгы белән «төзәтми». Йодрык шатлыктан, бәхеттән була, ә монда тырнак эшкә җигелә. Тырнак дәфтәрдә минем гагаралык урынында төртелеп кала, әгәр дә мин аңламыйчарак торсам, тырнакка охшашлы каты сүзләр ява. Аннан соң мин, ниһаять, укытучының күн диванында йоклап китәм, кайчак уянып китәм дә укытучымның өстәл артында чәй эчә-эчә, төрепкә тарта-тарта исәпсез-хисапсыз дәфтәрләрне тикшерүен һәм аның үткен карашлы мәрхәмәтле күзләренең ялтыравын күрәм. Владимир Николаевич Протопопов беркайчан да йокламый иде.

***

Шулай итеп, безнең ишегалдында барысы да минем институтка мәңгегә дә керә алмасымны аңлый иде. Моны мин дә аңлыйм, абыем Боря да аңлый, мәктәптәге укытучылар да аңлый. Бары тик Владимир Николаевич Протопопов кына аңламый. Ул минем институтка керәчәгемне белә иде, һәм мин кердем дә.

PRESSA.RU



# РЕПЕТИТОР ЮК ИКӘН – БЕЛЕМ ДӘ ЮК

Иң объектив РЕПЕТИТОР – Татарстанның атказанган укытучысы Зоя Дмитриевна Степанова репетиторлыктан башка белемсез калу куркынычы һәм безнең дөрес юлга чыгу мөмкинлекләребез турында.

– Соңгы елларда репетиторларга ихтыяҗ артты, алай гына да түгел, **укучыларны үзенә, профессионал укытучы гына түгел, акча юнәтергә теләүче студент та таба ала.** Әле 90нчы елларда репетиторлык, кагыйдә буларак, илнең иң җитди югары уку йортларына керергә планлаштыручы бишлегә генә укучыларның өстәмә дәресләр алуын күздә тотса, бүген исә **«репетитор яллау» – гап-гади мәктәп программасын үзләштерү өчен системалы рәвештә дәресләр алу дигән сүз.** Мәктәп программасыннан тыш белем алу өчен дә мөрәҗәгать итүче укучылар бар, әлбәттә, ләкин андыйлар мәктәптә дәрес вакытында аңламаган, аңлатылмаган, өйрәнелмәгән материалны аңлатуга мохтаҗларга караганда күпкә азрак. Һәм бу безнең мәгариф системасы турында күпне сөйли.

Ни өчен болай килеп чыга соң? Үземнең предмет – математика турында сөйләячәкмен. Бүген мәктәптә математика, алгебра һәм геометрия дәресләренең төп максаты нинди? Дөрес, укучыдан төп дәүләт имтиханын һәм бердәм дәүләт имтиханын тапшырттыру. Соңгы елларда бердәм имтиханнар канаты астында бик күп санда дәреслекләр һәм методик кулланмалар язылды, ләкин бала алар ярдәмендә предметны авыр үзләштерә. **Бүген балалар формулаларны – нәтиҗә чыгармыйча, теоремаларны исбатлауларсыз гына өйрәнә.** Кайбер дәреслекләрдә башта практик күнекмәләрне эшләргә, аннан соң гына алар нигезләнгән теорияне өйрәнергә тәкъдим итәләр. Монда белем алганда системалылык һәм эзлеклелек турында нинди сүз була ала соң? Соңгы үзгәрешләр дә күңелне сөендерми: алгебра дәресләренең сәгате – өчкә, геометриянеке икегә калды. Бу үзгәрешләрнең иң югары ноктасы – әлеге төп (!) предметларны өйрәнүнең блоклы-зачет – алмашлап уку системасын кертү булды. Укучы бер ай бер предметны өйрәнә, икенче айда – икенчене. Бер айдан соң шул предметка әйләнеп кайткач, бала алган белемнәренең күпмесен истә калдырган була икән соң? **Аның каравы, мисал-мәсьәләләрнең әзер чишелеше күрсәтелгән әсбапларны сату киң таралыш алды.** Хәтта бишенче сыйныф укучылары ук, җиңел генә мәсьәләләрне чишкәндә дә, әзер җавапларны шуннан күчереп ала. Менә шулай, чишелеш бирелгән китаплардагы җаваплар аша Россиянең булачак белгечләренең фикерләү дәрәҗәсе «киңәя». **Шул ук вакытта дәрестә аңлап өлгермәгән нәрсә баланың һәм ата-ананың проблемасына әйләнеп кала.** Әйе, 30 ел элек өендә дәресен хәзерләп килмәгән укучыны укытучы дәрестән соң алып кала иде. Ләкин 90нчы елларда өстәмә дәресләргә

Иллюстрация: Жан Батист Симеон Шарден. «Молодая учительница»

түләүне бетерделәр. Бүген күпләр укытучыларны эшләренә битараф булуда, аңа бармак аша карауда гаепли. Ләкин аларга да бит ел саен яңадан-яңа методик таләпләр куела, еш кына – уку-укыту процессына булышлык итми торганнары. Педагоглар да гаиләле, аларның да шәхси тормышка хаклары бар.

**Әлеге фонда укучының киләчәк язмышын төгәл күзаллый алмавы демотивацияләүче роль уйный.** Әйе, әти-әнисе максатчан рәвештә абруйлы уку йортына әзерли торган балалар да бар. Алар өстәмә рәвештә күп шөгыльләнә, белем дәрәҗәсе дә югары. Ләкин алар өчен дә елдан-ел азая барган бюджет урыннарына эләгү юлы катлаулылана бара: конкурстан башлап әшнәлеккә кадәр. Дүртлегә һәм өчлегә укучыларга килгәндә, аларның бюджеттагы урынга эләгү мөмкинлекләре тагын да азрак. Түләүлегә – рәхим итегез. Моны белгән хәлдә, балаларның укырга омтылышы кими, күңелләре төшә. **Гадәти мәктәпләрдә югары сыйныф укучылары дәрескә йөрүне кирәк дип санамый да – ни мәгънә?** «Ничек тә булса кермен әле укырга», – дип фикер йөртә яшүсмер.

Эш шуңа бара кебек: бездә уку-укыту тавыш-тынсыз гына түләүлегә, димәк ки, элитарга әйләнә. Чөнки атнага икешәр-өчәр репетитор яллау һәркемнең хәленнән килми, өстәвенә, бүген күп гаиләләрдә – икешәр-өчәр бала. **Ләкин дөрес юлга чыгарга шансларыбыз бар әле.** Безнең педагоглар арасында укымышлы, акыллы, талантлы кешеләр күп. Бу турыда ишетеп кенә түгел, төгәл беләм – Казанның иң яхшы математика укытучылары арасында минем укучыларым да шактый. Ләкин яхшы якка үзгәрешләр уку-укыту барышы белән практик педагоглар шөгыльләнсә генә мөмкин – аларның тиешле квалификациясе һәм тәҗрибәсе бар. Ожегов сүзлегендә «профессионал» сүзенә «эшен әлеге һөнәргә ия булган белгеч буларак башкаручы кеше» дигән аңлатма бирелә. Россия мәктәпләренең язмышы турындагы җитди карарларны нәкъ менә шундый кешеләр кабул итсен иде.

PRESSA.RU



# Укыту начаррак булган саен, БДИ яхшырак тапшырыла

Иң тынгысыз ӘНИ – Надежда Фёдорова ни өчен укытучыларга укучыларны укытмау отышлырак булуы турында.

**– Безнең гаиләдә бүген ике чыгарылыш сыйныф укучысы бар.** Улларымның берсе БДИ бирә, икенчесе – ГДИ. Һәм ата-аналар мине кызгана, чөнки бу уку елының миңа нинди суммага төшүен аңлыйлар. Алай гына да түгел.

Олы улыма фән нигезләрен кимерергә 5 репетитор ярдәм итә – имтихан тапшырасы предметлар санынча алар. Бу балада өмет бар, һәм уку барышында репетиторларның катнашуы безгә имтиханнарда югары баллар җыярга ышаныч бирә.

Кече улыма 4 репетитор кирәк. Монда максат башка – «өчле» алырлык булса да ярый. Әмма репетиторлар отрядының һәр икесе өчен дә бәяләр бер үк – «бишле»гә укучы улым да, «өчле»гә укучысы да миңа атнасына 6 мең сумга төшә.

Әгәр бу хәл бездә генә, дип уйласагыз – ялгышасыз. Улларымның сыйныфташларының һәркайсында шуның кадәр репетитор – «икеле»гә укучыларында да, «өчле» белән «бишле»гә баручыларында да. **Безнең ике сыйныфка тулы бер армия хезмәт куя. Ә бөтен мәктәп буенча күпме?**

Урынлы сорау туа: ә укытучылар нишли? Аларга ярыйсы гына хезмәт хакын (минекеннән артыграк) бюджеттан ни өчен түлиләр, һәм без нәрсә өчен салым түлибез? Бу очракта миндә бер генә теләк туа: хезмәт күрсәтелмәгән икән – акчасын кайтарсыннар. **Минем балаларымны мәктәп укытмый, бу хезмәтне репетиторлар күрсәтә.**

Әлеге темага мәктәп директоры белән сөйләшеп карадым. Җавап мондый булды: «Ә нәрсәгә репетиторлар яллыйсыз? Үзләре укысыннар». Чыннан да, каршы әйтеп булмый. Үзләре укысыннар. Менә шунда балаларыбызның булдыксызлыгына килеп төртеләбез: менә дигән укытучылары бар, ә алар һич кенә дә аңламый. Ләкин барысы да аңламый кала алмый бит инде?

«Балаларны имтиханнарга әзерли торган бушлай элективлар бар», – диде миңа директор.

Монда да хөрмәтле директор белән килешми булмый. Анысы әйе, шөгыльләнәләр. Әмма ничек? Мәсәлән, рус теле укытучысы үзенең элективларын шимбә көнне иртәнге 7гә куя. Һәм бу турыда игълан иткәндә, һәрвакытта да өстәп куя: «Тагын берәү дә килмимени? Шулай дип уйлаган идем инде аны, бушлай белем беркемгә дә кирәк түгел!»

Математика укытучысы исә болай ди: «Мин сезгә төп белемне бирәм, калганын үзегезнең реперлардан сорагыз». Хәзерге укытучыларның слэнгы шундый.

Һәм зарланалар, зарланалар, зарланалар. Җыелышка «Сезнеке надан... Сезнеке укымый... Сезнеке берни дә белми... Сезнеке мине бөтенләй өч хәрефкә җибәрде...» дигәннәрен ишетмәс өчен генә дә бармассың.

Менә шулай, безнең ике сыйныф һәм алар белән бергә тулы бер буын ничектер берьюлы ахмакка әйләнде дә куйды.

Әллә шушы рәвешле ахмаклык кем өчендер отышлымы?

Отышлы, әлбәттә. Башкача була да алмый. Мәктәп кәттәрәк булган саен, кабул итүче як укырга килүчене куркытып куя: «Бездә уку авыр! Белеп торыгыз. Тарта алмасагыз – репетиторлар ялларга туры киләчәк!»

Каян килә мондый тәртип? Ни өчен нәкъ менә бу мәктәптә уку авыр? Бала өчен уку процессы яңа белем алырга ымсындырып тора торган кызыклы, мавыктыргыч булырга тиеш түгелмени?

Мәктәп өчен балаларны укытмау отышлы. Начаррак укыткан саен, әти-әниләр репетиторларны күбрәк яллаячак бит. Кая барсыннар. Репетиторлар күбрәк булган саен, баланың белеме дә күбрәк, димәк, ул имтиханны әйбәт бирәчәк, һәм мәктәп тә БДИ тапшыру буенча рейтингта алдынгы урыннарга чыгачак. Димәк, бу мәктәпкә тагын да күбрәк кешеләр килергә теләячәк. Димәк, алга таба кул кушырып кына утырырга мөмкин булачак яки эштән бушаган арада репетиторлык белән шөгыльләнергә мөмкин – хезмәт хакы да тама, репетиторлыктан да өлеш керә, мәктәп тә – яхшыдан-яхшы. Менә дигән схема!

Һәм моны болай гына калдырырга ярамый, минемчә. Әлегә мин кулдан килгәнне эшлим. **Бу хакта танышларыма сөйлим һәм балаларын абруйлы мәктәпләргә бирмәскә үгетлим, чөнки аларның даны – аларныкы түгел.** Быел бишесен туктатып калдым, былтыр – өчесен. Әлбәттә, безнең алдынгы мәктәбебез диңгездәге сизелер-сизелмәс тамчыны тоймады да. Әмма тавык бөртекләп чүпли. **Мәктәп укытырга тиеш, ә репетиторлык институты өчен планктон әзерләргә тиеш түгел.** Югыйсә, нәрсәгә безгә арадашчы?

PRESSA.RU

# МОНДА АЛАРНЫҢ ӘЗЛӘРЕ БАР...

**Тукайның туган көнендә «Татарстан» журналы редакциясе, республика эшкуарлары белән дин вәкилләрен җыеп, «Бизнес. Рухият. Мәхәббәт» темасына сөйләшү үткәрде. Бу исә турыдан-туры «Татарстан» журналы игълан иткән «Кече ватан патриотлары» хәйрия агарту хәрәкәтенә аваздаш.**

Автор:
Линар Закиров

Проектның максаты – татарстанлыларны республиканың талантлы шәхесләре арасындагы онытыла барган исемнәрне кире кайтару. «Татарстан» журналы үткәргән махсус сораштыру нәтиҗәләре буенча, Абдулла Алиш, Гаяз Исхакый, Шәйхи Маннур, Шәүкәт Биктимеров, Бакый Урманче, Фәнис Яруллин, Илһам Шакиров h.б шундый исемнәрне телгә алуга, мондый җаваплар алынды: «ниндидер танылган шәхес», «шундый урам бар», «җавап бирергә кыенсынам»...

Проект кысаларында күренекле ватандашларыбызның исемен мәңгеләштерүне һәм аларны искә алуны бурычы дип санаган районнарга сәфәр чыгу планлаштырыла. Төп туристик маршрутларга кертелмәсә дә, әлеге музейлар, истәлекле урыннар – Татарстанның йөзек кашлары.

«Кече ватан патриотлары» үз хәрәкәтен эшлекле очрашудан башлады. Республиканың дин вәкилләре, Кече һәм урта бизнес эшкуарлары ассоциациясе әгъзалары белән бергә, түгәрәк өстәл уздырдылар. Сөйләшүдә катнашучыларның фикерләре туры килде: рухият һәм мәхәббәттән башка бизнес алга бармый. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк.

Әлеге агарту хәрәкәте кысаларында айга бер тапкыр «Татарстан» журналы хәбәрчеләре һәм ТР эшкуарларыннан торган десант республиканың берәр почмагына – бөек якташларның кече ватанына юл тотачак. Теләге булган һәркем «Татарстан» игълан иткән хәйрия хәрәкәтенең меценаты була ала.

Чараны алып барган ТР кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе президенты Хәйдәр Хәлиуллин әйтүенчә, 15 ел дәверендә шушы урында эшләп, ул бер әйбергә игътибар иткән: предприятие җитәкчесенең әхлак, рухият дәрәҗәсе никадәр югары булса, бизнесы да шулкадәр нәтиҗәле эшли.

### «БЕРКЕМ ДӘ ӨЛЕШЕГЕЗГӘ ТИМӘЯЧӘК»

**Ицхак Горелик, ТР баш раввины:**
– Тәүратта гади генә, әмма бик хикмәтле гыйбарә бар: «Аллаһ Тәгалә барлык эшләреңә үз фатихасын бирәчәк». Әйтик, миңа ашарга кирәк, ди. Ризыкны Аллаһ Тәгалә җибәрәме, әллә үземә эшләп табасымы? Аллаһ Тәгаләнең биргәнен генә күтәргә була, дип уйлаучылар да бар. Дөресе шул: ашыйсың килә икән, эшлә, бизнес ач. Белеп тор: моңа Аллаһ үз фатихасын бирмәсә, берниндиы тырышлык та уңышка китерә алмаячак, чөнки бу – Аның карары. Аллаһка ышанганда, кеше үз бизнесы өчен тыныч яши. Иманлы бәндә, берәү күрше урамда кибет ачкан, бөтен акча шунда китәчәк, дип хафаланмас. Беркем дә сезнең өлешегезгә тимәячәк.

Фото: Александр Эшкинин, Ната Смирнова

Бизнеста тормыштагы сыман законнар хөкем сөрә: тирә-ягыңны яхшырту өчен көч куярга кирәк. Барысы да шулай эшләсә, бөтен кешегә яхшы булачак.

### «БАБАЛАРЫБЫЗ ҮЗ БАЙЛЫГЫН ИМАННЫ НЫГЫТУГА ТОТКАН»

**Геннадий атакай Четвергов, Казанның искейолачылар общинасы рухание:**

– Тарихка карасак, искейолачылар йөз ел элек халыкның 2–3%ын гына тәшкил иткән, шуңа да карамастан, революциягә кадәр Россиядәге капиталның 1/3 өлеше алар кулында булган. Нәселемдәге танылган сәүдәгәр Четвергов Козьма да бизнеста уңыш казанган. Безгә ана сөте белән Давыт пәйгамбәр сүзләрен төшендерделәр: «Байлык йөрәгең Аллаһ Тәгаләгә тапшырылган очракта гына сиңа агыла». Байлыкны балаларыбыз йә башка кешеләр өчен җыябыз, һәрхәлдә, үзебез өчен түгел, чөнки берсен дә ахирәткә алып китә алмыйбыз. Ә кайвакыт кеше байлыкны бертуктаусыз җыя да җыя. Христиан күзлегеннән караганда, бу – акылсызлык. Бабаларыбыз үз байлыгын гыйбадәтханәләр төзүгә, иманны ныгытуга тоткан. Кешеләрне алдамыйча, гадел рәвештә эшләү – болар Аллаһның төп принциплары.

### «ИМАНЛЫ КЕШЕ КАЙГЫРМЫЙ»

**Нияз хәзрәт Сабиров, ТР Диния нәзарәтенең дәгъват бүлеге җитәкчесе:**

– Коръәндә һәм хәдисләрдә тормышның барлык очраклары өчен дә кагыйдәләр төгәл язылган. Кеше аларга таянып эш итсә, һәр изге гамәле табыну буларак кабул ителә. Табыну биш вакыт намаз укып, ураза тотуны гына күздә тотмый, ул киңрәк мәгънәгә ия. Бизнес та табынуга керә, тик моның өчен ике шартны үтәү мәҗбүри: 1) ихластан, ягъни Аллаһ разый булсын

## «КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ» ХӘЙРИЯ АГАРТУ ХӘРӘКӘТЕ КАРТАСЫ

PRESSA.RU



өчен эшләргә; 2) Аллаһ кануннарыннан читкә тайпылмаска.

Һәр Аллаһ илчесе нинди дә булса сәләткә ия булган: Нух пәйгамбәр – балта остасы, Давыт пәйгамбәр – тимерче, Мөхәммәд пәйгамбәр – сәүдәгәр. Алар үз мисалларында иманлы кешенең ничек яшәвен күрсәткән. Исламда гаиләне тәэмин итүгә, шулай ук рухи якны гына түгел, матди якны кайгыртуга да зур игътибар бирелә. Иманлы кеше, хезмәтем табыш китерерме, юкмы, дип кайгырмый, хәленнән килгәнчә, бөтен нәрсәне эшләп, Аллаһның шәфкатьлелеген көтә.

Дин белгече Хәсән Басрыйдан: «Тәкъвалыкка ничек ирешә алдың?» – дип сораганнар. Ул болай дигән: «Дүрт сыйфат ярдәмендә: 1) миңа насыйп ризык башка кешегә эләкмәячәген белеп, күңелем тыныч булды; 2) минем эшемне миннән башка беркем башкармаячак, шуңа да үз кәсебем белән шөгыльләнә башладым; 3) Аллаһ Тәгаләнең һәрчак күзәткәнен белдем, гөнаһ кылган чагымны күрә алуыннан оялдым; 4) үлем ул – хакыйкать, Аллаһ белән күрешү өчен, үлемгә әзерләнә башладым».

**«Тормышыбыз уңышлы һәм бәхетле булсын дисәк, ярдәмгә мохтаҗ кешеләр турында онытырга ярамый. Бу байларга гына түгел, һәркемгә кагыла».**

Иманлы кеше үз гамәлләре өчен җавап тотасын белә. Бөтен байлыклар – гаилә, сәламәтлек, мал-мөлкәт – Аллаһ рәхмәте. Мөхәммәд пәйгамбәр: «Кеше иртән исән-имин уянса, бер көнгә тамагын туйдырырлык ризыгы булса, ул – иң бәхетле кеше», – дигән.

Бизнес алып барганда, ике тәгълиматны истән чыгарырга ярамый: үзеңне һәм хезмәткәрләреңне харамнан сакларга һәм Аллаһ кушканны эшләргә, ягъни хәләлгә тартылырга. Хәләл булган бизнеста уңыш елмая. Бер хәдистә әйтелгәнчә, кыямәт көнендә намуслы һәм гадел сәүдәгәр пәйгамбәрләр белән бергә булачак. Намуслылык исә вәгъдәләрне һәм килешү шартларын үтәүдә чагыла. Өстәвенә, җитәкче хезмәт хакын вакытында һәм тулы күләмдә түләргә тиеш. Хәдистә язылганча, «эшчегә хезмәт хакын аның тире кипкәнче түләргә кирәк».

Тормышыбыз уңышлы һәм бәхетле булсын дисәк, ярдәмгә мохтаҗ кешеләр турында онытырга ярамый. Бу байларга гына түгел, һәркемгә кагыла. Күп кенә Коръән аятьләрендә болай диелә: «Мохтаҗ кешегә ярдәм итсәң, Аллаһ мал-мөлкәтеңне икеләтә арттырачак».

### «КҮПМЕ КҮЗ ЯШЕ ТҮККӘНЕМНЕ ҮЗЕМ ГЕНӘ БЕЛӘМ...»

**Зәкия Шәфыйкова, «Элемтә» ҖЧҖ генераль директоры:**

– Бизнес белән 20 ел шөгыльләнәм, аңарчы 20 ел адвокат булып эшләдем. Рухият һәм мәхәббәттән башка бизнес алга бармый. Гомумән, нәрсә соң ул бизнес? Банкка барып, биш миллион сум акча сорау түгел, ә кешеләр арасында дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыра алу.

Минем урта яшькә кадәр Коръәнне дә, башка дини китапларны да укыганым булмады. Әмма тора-бара әти-әнием өйрәткән кагыйдәләрнең Коръәндә язылган икәнлеген аңладым. Бизнесым елына 1,5 миллиард сум доллар китерә иде.

Үз эшең белән шөгыльләнгәндә, янында намуссыз кешеләр йөри башлый, көннәрдән бер көнне алар авырлык китерергә, юлдан тайпылдырырга мөмкин. 2008–2009 елларда минем оешмага карата җинаять эшләре ачылды, бөлгенлеккә чыктым. Ул вакытта Аллаһка ышанмый идем, хәзер дә, бармы соң Ул, дип еш кына уйлап куям. Һәрхәлдә, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен көйли торган Кемдер бар инде. Кешеләр хыянәт иткәч, ташлап киткәч, ни өчен мине мондый авырлыкларга дучар иттең, дип Аллаһка ялварасың. Мин бу сорауга өч елдан соң гына җавап таптым. Аллаһ мине уратып алган яман кешеләрдән коткарган икән. Күпме күз яше түккәнемне үзем генә беләм.

### «ИСКӘ ТӨШЕРМӘСӘҢ, ЗУР ШӘХЕСЛӘР ДӘ ОНЫТЫЛА»

«Кече ватан патриотлары» акциясе кысаларында беренче булып Габдулла Кариев ватанына юл тоттык. Биредә аның туган көнен дүртенче мәртәбә зурлап билгеләп үтәләр. Бу көнне республиканың татар театрлары җыелып, спектакльләрдән өзекләр тәкъдим итә.

Яшь тамашачы театры, Кариевның түгәрәк датасына атап, аның үзе язган «Артист» әсәрен сәхнәләштерде. Инсценировкасын язган драматург, шагыйрь **Ркаил Зәйдулла** сөйләвенчә, Габдулла Кариевны онытылып барган шәхес, дип әйтеп булмый. Татар тарихында һәм сәнгатендә аның эзе яхшы сакланган, туган авылындагы музеенда да истәлеген кадерләп саклыйлар. Без моңа үзебез инандык.

– Онытылып барган шәхес дип шушы авылдан чыккан җәмәгать эшлеклесе, публицист Фоат Туктаровны атарга була. Ул революциягә кадәр Казан университетының юридик факультетын тәмамлый. Гаяз Исхакыйның якын көрәштәше була, алар бергәләп «Таң йолдызы», «Таң» газеталарын чыгаралар. Революциядән соң Фоат Туктаров мөһаҗирлеккә китә.

Совет чорында большевизмга каршы көрәшеп, чит илдә булган шәхесләр турында язарга да, искә алырга да ярамый иде. Бу исемлеккә Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Габделбари Баттал һ.б кертелде. Үзгәртеп корудан соң, Фоат Туктаров турында материаллар чыкты, ләкин аның шәхесен киң масштабта ачып бетерә алганыбыз юк әле. Искә төшереп тормасаң, иҗтимагый тормышта тирән эз калдырган әллә нинди зур шәхес тә онытыла. Шул ук Исхакыйның да күп кенә мөһаҗирлек чоры әсәрләре, публицистикасы рус теленә тәрҗемә ителмәгән. Моны башкарып чыгу безнең алдагы бик зур бурыч булып тора, – диде Ркаил Зәйдулла.

### «КАРИЕВ – НУРЛАТНЫҢ ТУКАЕ»

Төбәк тарихын өйрәнүчеләр арасында Габдулла Кариевның моңарчы билгеле булмаган тормыш сәхифәләрен барлауга юнәлтелгән конкурс игълан ителгән. Шул рәвешле болай да бай булган музей фондын тагын да тулыландырмакчылар.

– Без хәзер Кариев исемен танытуга зур көч куябыз, – диде Нурлат шәһәрендәге Кама аръягы тарихы төбәк музее директоры **Флюра Морзаханова. –** Былтыр аның музеена 27 туристик төркемне китерүгә ирештек. 2015 елда Күлбай Морасада барлыгы ун меңгә якын кунак булып китте. Хәзер музей турындагы мәгълүматны бөтен туристик агентлыкларның сайтларына урнаштырдык, инде шалтыратулар да килә башлады. Тырышлыгыбыз бушка китмәс, дип ышанабыз. Габдулла Кариев исемен киңрәк яңгырату максаты белән Казахстанга, Магнитогорскига, Чиләбегә, һәртөрле Сабан туйларына күргәзмәбезне алып барабыз.

Музей директоры, ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев нигез салган «Яңарыш» республика фондын күздән тотып, Татарстан Хөкүмәтенең тарихка зур игътибар күрсәтүен билгеләп үтте. Шул ук вакытта кечкенә һәм ерак авыллардагы мемориаль музейларны онытырга ярамый. Флюра Морзаханова «Татарстан» журналының «Кече ватан патриотлары» акциясенә, бу бик әһәмиятле һәм кирәкле чара, дип югары бәя бирде, әлеге эштә ярдәм итәргә әзерлекләрен дә белдерде.

– Габдулла Кариевны Нурлат районының Габдулла Тукае дип кабул итәм, – диде безгә Нурлат районы башлыгы Равил Кузюров. – Аның турында күпмедер белә идем, ләкин үз тарихыбызны ныклабрак өйрәнергә кирәк. Кариевка иң югары бәяне халык биргән инде!

Фото: Александр Эшкинин, Ната Смирнова

Г.Кариев исемендәге Яшь тамашачы театры сәхнәләштергән «Артист» спектакленнән күренеш.

### «ҺӘРКЕМНӘН ГЕРОЙ ЯСАРГА БУЛА»

– Габдулла Кариев – районыбызның, авылыбызның горурлыгы. Татар театрларына, Кариев исемен күтәреп барып, яшьләргә үрнәк күрсәтүләре, безнең авылны хөрмәт итүләре өчен рәхмәт. Һәр кеше – үзе бер тарих, һәркемнән герой ясарга була. Без дөрес юлдан барабыз, – диде Нурлат районы якташлыгы, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе **Фәрит Мифтахов**.

Фәрит Мифтахов сүзләренчә, соңгы өч айда республикада үткәрелгән шактый чараларда татар театры атасының исеме телгә алынган. Якташларны елга бер тапкыр җыеп, концерт үткәрү генә җитми, аларның исемнәрен халыкка даими рәвештә таныту мөһим, ди ул.

Күлбай Морасадан тагын бер күренекле шәхес – танылган дин әһеле Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин чыккан. Руханига быел 120 яшь тула, авыл халкы аны да игътибарсыз калдырмады.

Тамашачылар арасында Казан театр училищесы студенты **Сөембикә Матурова** да бар иде, ул Камал театры артисты Илдар Хәйруллин курсында укый.

– Без татар һәм рус театрларына йөрибез. Укытучыбыз да Камалдан булгач, дәресләрдән соң да гел анда чапкач, шул театрга эләгәсем килә. Училищеда Габдулла Кариевның нинди авырлыклар кичеп татар театрын аякка бастыруы турында күп сөйләшкәнебез булды. Аның тормыш юлына карап, теләсә нинди авырлыкны җиңеп чыгарга була, дигән фикергә киләсең. Күлбай Морасага туганнарым янына кайтып йөрим, әтием шушыннан, – диде студент кыз.

Аны да безнең акция кызыксындырды. Сөембикә соңгы вакытта драматург, язучы Туфан Миңнуллин иҗаты белән аеруча кызыксынып киткән. Үзе, иҗаты һәм туган авылы онытылмаса да, аның мирасын яшьләргә күбрәк тәкъдим итәргә кирәк, диде ул.

### «БӘЛКИ, КАРИЕВ ЭЗЕНӘ БАСКАНМЫНДЫР...»

Татарстанның халык шагыйре **Ренат Харисның** Габдулла Кариевның тавышын ишеткәне булган.

– Берничә ел элек, Дәүләт музеенда бер пластинка табылды, анда Кариев тавышы язылган, диделәр. Пластинка хәзер исәнме икән, юкмы – белмим, әмма ул вакытларда аны тыңлап карадык. Кариевның тавышы безгә баритон булып тоелмады, тасманың язылу тизлеге дә башкача иде. Без аны бер чарада яңгыратырга тиеш булсак та, яңгырата алмый калдык. Еллар үтте – фән алга китте. Ватылган, җимерелгән самолетларда язылган кара тартмадагы тасмаларны алып, анда нәрсә язылганын белә ала хәзер кеше. Бәлки, Габдулла Кариевның пластинкасын фән казанышлары нигезендә элеккеге хәленә китереп, яңгыратып булыр. Ә иң мөһиме – шул тавышны хәзерге Күлбай Мораса кешеләренә дә ишеттерсәң, ул гаҗәеп бер тарихи вакыйга булыр иде, – диде Ренат Харис.

Татарстанның халык шагыйре әйтүенчә, татар сәнгате дөньясында берничә изге урын бар: татар халкының символы булган Габдулла Тукай, татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салган Салих Сәйдәшев, татар рәсем сәнгатенең башында торган Бакый Урманче һәм татар театрын бар кылган Габдулла Кариевның кендек каны тамган туган яклары.

– Бу залга кергәндә йә булмаса музейда йөргәндә, бәлки, Габдулла Кариевның эзенә басканмындыр, – дип тә өстәде Ренат ага.


**ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –**

**«ТАТАРСТАН» БЕЛӘН АЛГА!**

PRESSA.RU

# «ИСЕМЕ АЛТЫН ХӘРЕФЛӘР БЕЛӘН ЯЗЫЛЫР...»

Луиза Янсуар
әзерләде

**«Без шундый театр төзербез, аның исеме алтын хәрефләр белән язылыр», – дип кабатларга ярата торган була Габдулла Кариев. Ачлы-туклы килеш салкын вагоннарда гастрольләргә йөргәндә дә, кунар урын тапмыйча, сукбай хәлендә урамнарда төн үткәргәндә дә, әр-каһәр ишеткәндә дә өметен өзмәгән ул – татар театрының киләчәге барлыгына ышанган. 130 еллык юбилее уңаеннан Габдулла Кариевның биографиясендәге кайбер сәхифәләргә тукталып үтәргә булдык.**

### КОРЪӘН ХАФИЗ МИҢЛЕБАЙ

Миңлебай Хәйруллин элеккеге Чистай өязе Күлбай Мораса авылында 1886 елның 8 (иске стиль белән 20) маенда туа. 1894 елны Морасага яңа мулла Зариф Камалов килә һәм, җәдитчелек күрсәтү уе белән, шәкертләр җыя башлый. Болар рәтенә Миңлебай да керә. Миңлебайның коръән хафиз булуына иптәшләре каршы төшә:

– Ул әле иҗек тә танымый, – диләр.

Миңлебайның иҗек танымыйча коръән укый белүе үзе бер шөһрәт таратуга сәбәп була; кайберәүләр кечкенә генә могҗиза дип тә карыйлар бу хәлгә.

### МИҢЛЕБАЙ НИЧЕК ГАБДУЛЛА БУЛА?

Зариф мулла мәдрәсәсендә Бикбулат, Биктимер, Миңлебай, Тимербай исемнәре күп була. Муллача, мондый исемнәр «мәҗүсияттән» калган, аларны бетереп, мөселман исемнәре табарга кирәк. Миңлебай хафиз була калса, «Миңлебай хафиз» дип әйтү кытыршы булыр төсле. Шунлыктан Миңлебайның исеме Габдулла дип игълан ителә. Миңлебай дигән кешеләргә җавап бирмәскә кушыла. Шуннан соң халык та Габдулла ди башлый. Шуның белән Миңлебай Габдулла була да китә.

### КЫМЫЗЧЫ МАЛАЙ

Зариф мулла, солдаттан калу өчен риязәт чигә-чигә (ашау-эчүдән тыелып тору – авт.), исәнлеген югалта. Аңарга кымыз эчәргә кушалар. Ул, авылның бер очыннан ике дисәтинә җирне кистереп ала да, кымызханә ясатып җибәрә. Бия саварга, бияләрне йөртергә, тайларны карарга бер малай кирәк була.

Әтисенең фәкыйрьлеге сәбәбе белән, Габдулладан да мәслихәт кеше юк. Габдулла караңгы төшкәнче бия сава да төне буе сөт атлый. Таң белән торып, тагын эшкә тотынырга кирәк була. Бу эшләү Габдулланы ялыктыра, ул кайда туры килсә шунда йөгәннәрен баш астына салып йоклый торган кызганыч ятим бала хәленә төшә. Өйгә кайтса, аталары, мулланың явыз догасыннан куркып, кире җибәрергә тырышалар.

Хезмәте буш ителми. Кымыз сезоны үткәч, мулланың иске җиләне, җөббәсе, биш кат баш сапкан итеге Габдулланың җәйлек хезмәт хакы булалар. Габдулла аларны тегүчедән төзәттереп:

– Ул бит яңа чагында аршыны фәлән тәңкәлек булган, – дип мактый-мактый кия.

Зариф мулла Такталы авылына күченеп, Габдулланы да шул авылдагы мәдрәсәгә алдыра. Монда Габдулла күп вакыт чатнама салкын көннәрдә яланаяк йомышка йөреп тамагын туйдыра. Ахыр чиктә, чыдый алмыйча, «бәхет эзләргә» китә дә Җаек шәһәренә барып чыга.

Фотолар: «Шәхесләребез» сериясендә басылган җыентыктан алынды

## БЕЗНЕҢ ДУСЛЫК

*Габдулла Кариев, икенче мәдрәсәдә укучы булса да, бик еш безнең мәдрәсәгә дә килеп, Габдулла Тукай һәм минем белән аралашып йөри иде. Ул карый, ягъни коръәнне күңелдә бикләп укучы булганга күрә, бигрәк тә миннән, коръәнне мисыр көйләре белән укырга өйрәнде. Мин аңарга төрекчә, гарәпчә бик күп җырлар җырлап күрсәттем. Төркия белән Гарәбстанда ниләр күргәннәремнең барын да сөйләдем. Ул аларны бик кызыксынып, бик рәхәтләнеп, Тукай шикелле үк, бөтен күңелен салып тыңлады...*

*Тукай, Кариев һәм тагын да миңа килеп йөрүче берничә яшьләр белән җыелышып, үзебездә нинди дә булса татарча бер пьесаны шәһәр театрында яисә башка урында куярга киңәшеп йөрдек. Ләкин ул вакытта татар телендә басылган берниндидә пьеса таба алмау һәм патша хөкүмәтенең аны куярга рөхсәт итмәве дә билгеле булуы сәбәпле, без ул эшне, никадәр теләсәк тә, булдыра алмадык. 1905 ел революциясеннән соң, «Гыйшык бәласе» дигән пьесаны табып репетицияләр ясап йөрсәк тә, фанатикларның безне мыскыллап, театр уйнау өчен кыйнаулар белән куркытып йөрүләре һәм минем газет-журналлар чыгару белән кайнашып бушый алмавым сәбәпле, аны да уйный алмадык.* (К. Мотыйгый-Төхфәтуллин истәлекләреннән).

## ИКЕ ГАБДУЛЛА

1901 елда Габдулла Җаекка килә һәм Гайнетдин карый мәдрәсәсендә укый башлый. Бу иске карашлы мәдрәсә була, ләкин революция җилләре аның диварларыннан да үтеп керә. Шәкертләр арасында мәдрәсәгә тыелган китаплар алып кайтучылар була. Берсе – Сираҗетдин Бикулов. Габдулла аның белән дуслашып китә.

1910 елда, Галиәсгар Камалда кунак булганда, Габдулла Кариев үзенең Җаек чоры турында болай сөйли: *«Сираҗетдин атлы шәкерт миңа мәдрәсәдә тыелган китаплар укый иде... Берсендә ул мине Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсенә алып барды. Анда мин кыскарак кына буйлы бер яшь шәкерт белән таныштым. Бу шәкерт мине үзенең гакылы вә тормышка булган ачык карашы белән җәлеп итте. Без, вакытны онытып, озак гәпләштек. Бу Габдулла Тукай иде».*

Шул көннән башлап, алар еш очраша башлыйлар, бу дуслык Тукайның соңгы көннәренәчә дәвам итә. 1906 елның кышында алар мәдрәсәне ташлап чыгалар һәм «Казан» миһманханәсендә номер алып яши башлыйлар. Тукай «Фикер» газетасында эшли, Габдулла Хәйруллин газета, журналлар сата торган киоск ачып җибәрә. Сату эше очны-очка ялгарлык кына табыш китерә. Шулай да бу дәверне һәр ике Габдулла сагынып искә ала торган була. Алар бергәләп татар сәнгатен яңа баскычка күтәрү һәм моның өчен, әлбәттә инде, Казанга китү турында хыялланалар.

Җаекта еш кына әдәби кичәләр уздырыла. Шуларның берсендә Габдулла Хәйруллин сәхнәгә чыга һәм Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» шигырен башкара. Соңрак, шигырь популярлашып китеп, аны шәкертләр урамнарда декламацияләп йөри башлый.

1906 елның җәендә Габдулла Хәйруллин Түбән Новгородка юл тота, шул ук елның көзендә Тукай Казанга кузгала. Һәр икесенең үз язмышын, үз бәхетен эзләп, үз сукмагыннан атлап китүе була бу. Казанда аларның юллары әле кат-кат кисешә. 1908 елда алар Мәкәрҗәдә күрешәләр, бергәләп тамаша кылып йөриләр. Бу хакта Кариев «Тукай Мәкәрҗәдә» дигән истәлегендә яза: *«Көндезләрен Тукай белән самокатка йөрергә чыга идек; ул анда, ике тиен биреп, балалар шикелле, карусель атларына атланып әйләнә торган иде...»*

Тукай Кариев җитәкләгән «Сәйяр» труппасының һәр адымын күзәтеп тора, спектакльләрендә еш була, премьералар турында яза. Шагыйрь каты хаста хәлгә төшкәч, башка дуслары белән бергә, ахыргача аның янәшәсендә була. *«31 март көнендә көндез сәгать 1-2ләр тирәсендә доктор Лурия килде. Тукай янынннан чыккач, без – мин, Габдулла Кари, Әмин Мостафин, Әхмәт Урманчиев докторны чолгап алып, авыруның хәле ничегрәк, дип сораша башладык. Ул: «Сездән яшерүне кирәк тапмыйм, авыруның хәле яхшыдан түгел, бик күп торса, өч-дүрт көн торыр, үзенә белдермәгез, ялгызын гына калдырмагыз», – диде дә, башын иеп чыгып китте. Без дүртебез дүрт җиргә баскан килеш, бер-беребезгә бер сүз дә дәшә алмаенча, катып калдык. Арадагы тынычлыкны башлап Кариев бозды. Ул, стенага сөялгән килеш, кулларын күзенә куйды да үксеп-үксеп елый башлады: «Шулай ук Тукайны югалтабызмыни», – диде.* (Ш. Әхмәров истәлекләреннән).

Г.Кариевның грим тартмасы.

Габдулла Кариев
Кәрим Тинчурин белән.

## ХӘЙРУЛЛИН НИЧЕК КАРИЕВКА ӘВЕРЕЛӘ?

Габдулла Түбән Новгородка ярминкәгә килеп төшкән көннәрдә биредә Ильяс Кудашев-Ашказарский оештырган татар труппасының гастрольләре башлана. Габдулла татар театрының оешып килүенә әйтеп бетергесез шатлана, спектакльләргә йөри. Тамашаларның берсендә залга түбәтәен чөя. Аннары, шул түбәтәен алырга дип кереп, артистлар белән таныша, аларга соклануын белдерә. Шуннан соң артистлар янына көн дә килә башлый. Шулай бер әңгәмә корып торганда, Хәйруллин труппага керергә теләге барлыгын белдерә. Коръәнне яттан белгәч, рольләрне дә җиңел ятлар идем, дип ышандыра.

*«Бер көнне репетиция ясаган чагында, бер шәкерт килеп керә һәм мөлаем гына, башын игән хәлдә, күзләрен чытырдатып йомып, сүз башлый, үзенең сәхнәгә керергә теләгәнен аңлата. Кудашев аңар:*

*– Кыяфәтегезгә караганда, сездә артистлык куәте күренми, мин сезне ала алмыйм, – дип җавап бирә дә репетициягә тотына.*

*Кудашевның кырт кисеп җавап бирүе – аның кәефен җибәргән булырга кирәк, ул бер читкә бара да нәүмизләнеп утыра. Шул чакта мин Кудашевка:*

*– Әллә соң моны аласызмы? Кемне алсагыз да, белмәгән кешене алырга туры килә бит, – дим...*

*Ул көнне мескен «шәкерт» һичбер рәтле җавап ала алмыйча чыгып китә. Ләкин иртәгесен яңадан килеп, мине капка төбенә чакырып чыгара һәм үзенең театр уйнарга чын күңеленнән теләгәнен белдерә.*

*– Сез Кудашевтан сорап карагыз, бәлки мине труппага алырга риза булыр, – ди. Мин Кудашевка әйтеп карарга сүз бирәм...»* (С. Гыйззәтуллина-Волжская истәлекләреннән).

Гыйзәтуллина-Волжская кат-кат әйтә торгач, Кудашев Габдулланы труппага ала, әмма аның баштарак уйнавыннан һич канәгать булмый. Чынлап та, Кариев, истәлекләргә караганда, башта бик пафослы итеп уйный. Тора-бара хәлләр җайлаша. Труппадагы К.Шамил исемле артист аның ничек Кариев булып китүен болай искә ала: *«Баштарак мин бу яңа иптәшнең фамилиясен белми идем, шуңа да аңа Габдулла Карый дип эндәшәдер идем. Кудашев моны ишетеп алды да: «А! Карый, Кариев. Монда бик танылган профессор яши – Караев. Ә без афишага Кариев дип язарбыз...»* (Ш. Сарымсаков мәкаләсеннән).

### НИК ЕЛЫЙСЫҢ, ҖҮЛӘР, ЯКИ ТАТАРНЫҢ КАЧАЛОВЫ

*«Кариев белән 1908 елда Мәкәрҗәдә таныштым. Ул елны Мәкәрҗәгә үзенең дүрт кешелек кечкенә труппасы белән И. Кудашев-Ашказарский килде... Кудашев Казанга кайтмады. Г. Кариев белән С. Гыйззәтуллина, аннан аерылып, Казанга кайтып, «Сәйяр» исемендә кечкенә труппа төзеп уйный башладылар. Ул вакытта труппада Г. Кариев, В. Мортазин-Иманский, Б. Болгарский, С. Гыйззәтуллина, Ф. Сәмитовалар бар иде. Репертуар ярлы иде. Иң күп уйналган әсәр «Кызганыч бала», «Мәсхәраләнмеш ханым», «Гыйшык баласе», «Яшь хатын» кебек әдәби яктан эшләнеп җитмәгән нәрсәләр булды. Труппа акрынлап үсә башлады. К. Тинчурин, Г. Болгарская, С. Байкина, Камал I һ.б. килеп кушылдылар. Репертуар киңәйде.*

*Кариев нинди артист иде? Хәзерге кебек театр мәктәпләрендә укыган яки зур артистларның уйнауларын күргән кеше түгел, бәлки үзлегеннән үскән бер самородок... Ул татар типларын гаҗәеп оста, матур итеп бирә белә. Шуның белән бергә, рус һәм чит телләрдән тәрҗемә ителгән әсәрләрдә типларны һич татар артисты дип әйтмәслек дәрәҗәдә дөрес, табигый итеп бирә ала... «Трильби» куелганның икенче көнендә Кариев, минем янга килеп, Свенгали роле хакында фикеремне сорады. Мин аны кочаклап үптем. Ул, бик тәэсирләнеп, буылып елады. Аңа карап мин дә еладым. Соңыннан көлеп: «Ник елыйсың, юләр? Шатланырга кирәк, син киләчәктә татарның Каратыгины яки Качаловы булырсың», – дидем...»* (Г. Кәрам истәлекләреннән).

### ТЕАТРНЫҢ ПӘРДӘ АРТЫНДА...

Әмма театрның һәм артистларның хәле яхшыдан булган икән, дип ышанырга ашыкмыйк...

*«Бер көнне Габдулла Карины театрда очратырмын уе берлә көндез театр бинасына киттем. Ишекне ачып эчкә керсәм, көтелмәгән бер манзара алдында калдым. «Сәйяр» труппаның зур артистларыннан Гөлсем Болгар, Мәрфуга Мортаза, Сара Байкина кулларын сызганганнар да театрның идәннәрен юалар. Кәрим Тинчурин, Вәлиулла Мортаза, тагын берничә артист чиләк-чиләк су ташыйлар. Габдулла Кари да урындыкларны күчерә. Бүген булачак театрга бинаны паклау, арулау өчен кирәк булганда кеше яллап эшләтүләргә акчалары юк күрамсең дә, үзләре шуны эшләп яталар. Минем шундый хәлдә үзләрен очратуыма труппа әгъзалары, хосусән, хатын артистлар оялдылар. Ләкин мин үзем, аларның ничек группа булып яши белүләренең төп мәгънәсен аңлап, боларның һичбер эштән бу «кара» дип тартынмауларын күреп, киләчәктә дә үсәчәкләренә сөендем. Вә аларның күңелләрен күтәрә торган сүзләр сөйләдем».* (Г. Исхакый истәлекләреннән).

«Сәйяр» труппасы кышкы сезонда «Шәрекъ» клубында эшли. Тартып-сузып кына тамак туйдыра алырлык хезмәт хакы ала. Атнага ике-өч спектакль куя торган була. Кышкы сезон ябылгач (апрель азагында), тагын Россиянең төрле шәһәрләре буйлап йөрергә мәҗбүр булалар. Габдулла Кариев труппага җитәкчелекне үз өстенә алгач, театр куярга рөхсәт сорап, азмы-күпме булса да акча юнәтергә тырышып, көн-төн административ хезмәт белән шөгыльләнә.

*«Кыш буе эшләгән артистларга ял бирү, ял вакыты өчен акча түләү тәртибе юк. Гастрольгә чыгу мәсьәләсе Казаннан кузгалып китәрлек, маршрутта билгеләнгән беренче пунктка барып җитәрлек «юллык акча» эшләп алуга бәйле. Шуңа күрә «Сәйяр» гастрольгә чыгу алдыннан үзлегеннән бер-ике «саубуллашу» спектакле бирергә тиеш була. Гастрольгә чыккан шәһәрләрдә спектакльләрне куярга рөхсәт бирмичә җәфалыйлар. Шундый каплаулы тоткарлыклар нәтиҗәсендә, «Сәйяр»нең материаль хәле гелән авыр шартларда кичте. Иртәсен-кичен коры-сары белән туклану, төшкесен дә чәй белән генә үткәрү шактый еш кабатлана торган «меню» булып килде.*

*Әнә шундый авыр чакларда да Кариевнең үз язмышына карата зарлы-моңлы сүз, үз профессиясеннән ризасызлык белдерүен ишетмәдем. Аның оптимистлыгы калганнарга да тәэсир итми калмый».* (И. Рәмиев истәлекләреннән).

Г.Кариевның буыннан-буынга күчкән ядкәр йөзеге.

Гыйффәт туташ (Заһидә Бурнашева) искә алганча, 1907 елны Әстерханга барганда, тимер юл билеты алырга акча булмагач, Кариевның пальтосын сатып юлга билет алалар.

### АРТИСТ, РЕЖИССЕР, ҖИТӘКЧЕ, ОСТАЗ

*«Табигате белән Кариев шактый кызу канлы кеше иде. Ул бик тиз кабынып китә, аннары, бераз тынычлана төшкәч, гаепле бер кыяфәт белән гафу үтенергә керешә иде. Аңарда бернинди мин-минлек, кәпрәю юк иде... Бәхәсләшүе аның беркайчан да кирелектән, үз сүзен өстен чыгарырга тырышудан булмады. Үзенең ялгышканлыгын сизсә, ул шундук бирелә, үзен җиңелгән итеп саный иде...»* (З.Тинчурина истәлекләреннән).

Кариевка бер үк вакытта режиссер-спектакль куючы, режиссер-оештыручы, режиссер-җитәкче, режиссер-тәрбияче һәм театрның иҗади юнәлешен билгеләүче дә булырга туры килә. Аның беренче теоретик нигезләрен салучы да була ул. Бернинди профессиональ белеме булмаган, труппага дәрте, теләге буенча гына килеп эләккән «артистлар» бу остаздан беренче һөнәри дәресләрен, заманча итеп әйтсәк, мастер-класслар да алалар. Әлбәттә, бушка! Шуның өстенә, Кариев әле барысы белән бергә сәхнәдә дә уйный бит...

*«Мин, Болгарская, Кариев трамвайда бара идек, безгә шунда ике карчык очрады. Кариев шулар белән сөйләшә-сөйләшә китеп барды. Соңыннан Кариев безгә: «Мин теге әбиләр белән Пороховойга кадәр бардым бит, алар шундый интересный әбиләр икән», – диде».* (Н. Таждарова истәлекләреннән).

*«Кариев бөтен образларны сөйләп чыга. Рольне күп укырга кушмый иде. Просто, сүзләр белән күз алдына китерегез», – ди иде».* (Г. Болгарская истәлекләреннән).

*«Кариев актер-реалист иде. Менә шуңар күрә дә ул татар сәхнәсенең олы артистлары тезмәсендә күренекле урын алып тора. Кариев бик оста пародияче һәм импровизаторлык талантына ия иде. Кайчакны яшьләр җыелып ала. Кариевтан «Казан мөселман җәмгыяте хәйриясе» (байлар, муллалар оешмасы) утырышын имитацияләп күрсәтүен үтенәләр. Тукай сорый, Г. Камал да кул чаба. Иҗат итәргә настроениесе булганда, Кариев ялындырмый».* (И. Рәмиев истәлекләреннән).

Аны гаять гадел, намуслы кеше иде, дип искә алалар. Мактанчыклыкны, эшкә салкын карауларны, әхлак

Г. Кариев К. Тинчуринга бүләк иткән көмеш кашык.

бозучыларны яратмады, диләр. Труппада баш кеше булуына карамастан, җитди мәсьәләләрне ялгызы чишмичә, дуслары К. Тинчурин, Г. Мангушев, И. Кулиев белән бергәләшеп, киңәшеп хәл итә торган булган.

*«Рус театры казанышларын яңа аякка басып килүче безнең татар театрына күчерергә теләге зур булды. Ул кешеләр белән оста сөйләшә, зур әдәп белән мөрәҗәгать итә белә иде. Юкса 1917 елда әле киң җәмәгатьчелеккә (рус җәмәгатьчелегенә) таныш булмаган татар труппасы Мәскәүдә гастроль спектакльләре куя алыр идеме икән? Ә ул спектакльләр Мәскәүнең танылган театрларының берсендә – Корш театры бинасында барды.»* (Ф. Ильская истәлекләреннән). Шул гастрольләр вакытында Кариев «Сәйяр» артистларын Станиславский белән таныштыра.

*«Сәйяр» труппаны Мәскәүдә беренче майда башланачак Бөтен Русия мөселманнары корылтае вакытына чакырдым. Габдулла Кари бөтен труппасы берлә бергә килеп, корылтай вакытында Мәскәүнең иң зур театры «Корш»та «Зөләйха»ны 4 мең халык алдында куйды. Мәскәүдәге уңышы, һәм дә урысның үзагендә «Зөләйха»ны куя алу аның рухын бик күтәргән иде...»* (Г. Исхакый истәлекләреннән).

**«ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ АТАСЫ»**

1912 елда ук Габдулла Кариевның бенефисына замандашлары менә нинди бүләк әзерли:

## МӨХТӘРӘМ ГАБДУЛЛА КАРИЕВ ҖӘНАБЛӘРЕ!

*...Бу көннәрдә татар халкы сезнең биш сәнә буенча «Сәйяр» труппасын ялыкмый идарә кыйлуыгызны, татар театрын тәрәккъкый юлында күрсәткән корбанлыгызны, тагы татар театры гамәлендә моңа кадәр нәзыйрсыз (тиңдәшсез – **авт.**) артистлык талантыгызны тәкъдир кылып, сезне «татар театрының атасы» дип исемли.*

*Яшәсен татар театры! Яшәсен Габдулла Кариев!*

*Яшәсен «Сәйяр» труппасы!*

*Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукаев, Хөсәен Ямашев, Вәлиулла Мортазин, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Әхмәт Кулалаев... бары җитмешкә якын кеше кул куйган.*

*Казан, 1912 сәнә, 5 март.*
*«Йолдыз». – 1912. – 13 март.*

«Сәйяр» тәмам җитлеккән коллектив булып әверелә. Чордашлары труппаның иң уңышлы – «парлак» еллары дип 1915-1917 елларны атый. Кариев үзе дә, актерлык талантының апогеена гына җитеп калмый, театр репертуарын баетуы, режиссер буларак маһирлыгы белән дә танылa. Татар әдипләренең әсәрләре (Г. Камал, К. Тинчурин, Г. Исхакый, С. Рәмиев һ.б.) белән беррәттән, җитди тәрҗемә әсәрләрне сәхнәләштерергә дә курыкмыйча алына: Шиллерның «Мәхәббәт һәм нәфрәт»е, Островскийның «Яшенле яңгыр»ы, Чеховның «Чия бакчасы» һ.б.

1917 елда татар пьесасына конкурс игълан ителә. Бу труппаның репертуарын баетыр өчен эшләнә. Гәрчә Кариев коллективы бер ел эчендә инде театр тарихында рекорд исәпләнерлек 25 премьера чыгарган була. Кариев меценатлар һәм үз акчасына театр бинасы төзетеп чыгарга хыяллана. Әмма 1917 елдан соң хыяллар чәлпәрәмә килә...

**«КАЗАНГА КАЙТЫП ҮЛСӘМ ЯРАР ИДЕ...»**

Хакимияткә большевиклар килеп, башбаштаклыклар башлангач, театр эшен туктата. 1918 елда Габдулла Кариев, бер төркем артистлар белән бергә, Г.Исхакый, Ф.Туктаровлар эзеннән Самарага юл тота. Соңыннан Себергә барып чыга.

*«Габдулла Омски, Томски, Иркутскиларда театрлар куеп йөрергә булып, Кызылъярда калды. Бу минем Г. Кари берлә соңгы вә актыккы күрешүем булды. Ул бик озак төрле җирләрдә әллә кемнән куркып, әллә кемнән качып йөргәннең, большевиклар җирләшеп беткәннең соңында Казанга кайткан. Анда тиф берлә авырган. Большевиклар аны терелер-терелмәс: «Себердә акларга уйнап йөрдең бит, монда пролетариатка уйнарга теләмисең», – дип куркытып, ачыклы-тишекле салкын театрда сәхнәгә чыгаралар. Шунда ул бик каты суык тидереп, өзлегеп китә, вә савыга алмаенча, 1920 елның 28 гыйнварында вафат итә».* (Г. Исхакый истәлекләреннән).

Кариев Себердән Казанга кайтып егыла. «Салкын Себердә, рухсыз, вәхшәт оясы булган Себердә торган вакытта Казанга кайтып үлә алсам гына ярар иде», – дип тели идем дип, аркадашы И.Кулиев белән уртаклаша. Казан аны салкын каршылый – татар театры өчен 13 ел буе бушлай диярлек хезмәт куйган бу шәхеснең «ике арада адашып йөргүен» кичерми. Иске режимлы демократик театр инде пыран-заран китерелгән була.

«Сәйяр» труппасы.

Кариевның үзенә мөнәсәбәт тә әнә шулай, нәкъ ил икегә бүленгәндәй, аерыла – совет яклылар Кариев яңа властьне кабул итеп өлгерде, аны кичерергә кирәк, дип инандырса, совет властен кабул итмәүчеләр, аның яңа системаның чираттагы корбаны булуын ассызыклый, исемен «кызыл»ларга каршы хурлык әләме итеп күтәрә.

*«Иптәш Кариевның җәсәде артистлар тарафыннан күтәрелеп торганда бөтен Казан артистлары исеменнән иптәш Тинчурин һәм Казан журналистлары исеменнән Галимҗан Ибраһимов нотыклар сөйлиләр. Иптәш Тинчурин: «Кариев, мин үлгәндә Казанда татар театры уйнала торган үз бинасын күрә алсам – иң бәхетле кеше булыр идем», дигән иде, ләкин ул иң зур теләген күрә алмый үлде», – ди... Казан укытучылары исеменнән Фатих Сәйфи сүз ала. Иптәш Ашказарский Кариевка үз рәхмәтләрен укый...*

*Кариевның кабере, аның иң якын дусларыннан булган, Кариев белән яшьлекне үткәргән, шулай ук Казанда сәргәрдан булып (аптырап – **авт.**) вафат иткән Г.Тукай белән янәшә урында сайланган. Татар мәдәнияте тарихында мәңге онытылмаслык эз һәм эш калдырсалар да, ярлы-гидайлар булып күмелделәр».*

*«Кызыл армия». –*
*1920. – 1 февраль.*

*«Даһи артист Кариев Казанга кайтып үлде. Татарның иң зур артисты Габдулла Кариевны аның кәгъбәсе булган Казан ничек каршы алды? Салкын Себердә Казан өчен янган Кариевның кайнар йөрәгенә, авыру тәненә Казан бер җылы бүлмә дә бирә алмады. Без татарларның үзебезнең зур кадерле кешеләребезне үлгәч кенә аңлый ала торган йөрәкләребезне әҗәл генә йомшарта ала икән...»* («Сәйяр» труппасы һәм Казан артистлары исеменнән Кариевның җеназасы өстендә К. Тинчурин тарафыннан әйтелгән ахыргы сүз).

PRESSA.RU

# «ТӨШЕМДӘ СУГЫШ КҮРӘМ...»

Язып алды:
Луиза Янсуар

Сугыш төшенчәсе көннән-көн виртуальләшә. Заманның үзе кебек, компьютер уеннарындагы чынбарлык белән алышына. Кайчак аңлап та бетереп булмый: TV-яңалыклардан тәкъдим ителгәне дә – әлеге дә баягы сугышлы уенның өр-яңа супер, мега версиясе генә түгелме? Бар иде башкарак заманнар: әби-бабайлар безгә әти-әниләре, ягъни карт әби-бабайларның, башыннан кичкән сугыш турында сөйли иде. Саргаеп беткән фотоларны күрсәтеп. Өчпочмаклы хатларны. Лёня Голиков, Олег Кошевой, Зоя Космодемьянскаяларны каһарман саный идек. Планетаара яуларда катнашкан уйдырма джедайлардан аермалы буларак, алар чын яу кырында чын-чынлап ятып калган кешеләр. Кайбер тарихи фактлар нигезендә бу геройларга мөнәсәбәт хәзер үзгәрде. Әмма аларның безне реаль чынбарлыкны яратырга, ихтирам итәргә өйрәтүләре белән килешми мөмкин түгелдер. Бу санда үз буынымның берничә вәкиленә сүз бирергә булдым.

## «ИДЕАЛЛАШТЫРЫРГА КИРӘКМИ, ӘММА БЕЛЕРГӘ КИРӘК»

**Айсылу Галиева, «Татарстан китап нәшрияты»ның балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясе мөдире:** Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләрнең шактые мәктәп елларында укылды: **Габдрахман Әпсәләмовның «Газинур»**ы белән **«Алтын йолдыз»ы, Шамил Рәкыйповның «Кызлар-йолдызлар»ы, Рафаэль Мостафинның «Өзелгән җыр эзеннән»е. Фатих Кәримнең «Пионерка Гөлчәчәккә хат»ы:** андагы Ләйлә артыннан куып килгән фриц хәзер дә минем күз алдымда тора. **Муса Җәлилнең «Вәхшәт»е.** Аны 1–2нче классларда, әнисе иңенә башын яшергән баланы кызгана-кызгана, елый-елый, берни эшләп булмавына тәмам гаҗиз булып, яттан сөйләгән идем. Күләмле әсәрләрдән иң тәэсир иткәне – **Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» романы**. Соңгы укыганым – **Айдар Хәлимнең «Татар солдаты»**. Рейхстагка беренчеләрдән булып байрак кадаган Гази Заһитов турында ул. Әле өйдә балалар белән бүлеп-бүлеп **Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары»н** укыйбыз. Ошый. Минемчә, бу әсәрләр туган илеңне, туган җиреңне яратырга, ә иң мөһиме, үзең турында гына түгел, ә башкалар турында да уйларга өйрәткән безне.

Әле чынбарлык белән виртуальлекне бер итеп кабул иткәндә, телевизор экранынннан үземә ыргылып килгән танкны күреп, курыкканымны хәтерлим. Совет чоры кинолары патриотизм, халыклар дуслыгы, башкалар хакына үз-үзеңне корбан итү, батырлык хисләре белән сугарылган булса, соңгы елларда экранлаштырылганнарында куркаклык та, хыянәт тә, бер-береңнән көнләшү дә – миңа калса, чыгарып селкергә кирәк булмаган башка хисләр дә бар. Алар тәрбияләми, алар Бөек Ватан сугышында катнашучыларның абруен төшерә һәм, алар шундый булган, димәк, безгә дә ярый, дигән уйларга этәрә. Күпчелек шундый булган булса, Җиңү дә булмас иде бит. Ераклашкан саен, идеаллаштырырга кирәк, димим, әмма кайчандыр зур тәрбияви көчкә ия булган шул ук социалистик реализм методы белән иҗат ителгән әсәрләрне дә тамашачыга, укучыга җиткерергә кирәктер.

## «ҖИҢҮ – НӘРСӘ УЛ?»

**Раил Гатауллин, Белем.ру порталы җитәкчесе:** татарлар өчен, Бөек Ватан сугышы чорын бөтен тирәнлегендә чагылдырган әдәби әсәр ул, һичшиксез, – **Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»**. Төрмә диварларыннан чыгып, илләрне айкый-айкый әйләнеп кайткан әлеге шәлкем минем үземдә тирән мәгънәле шигъриятькә мәхәббәт уятты, кешелек дөньясына, аның тарихына игътибар беләнрәк карый башларга өйрәтте.

Адәм баласында кешелеклелек сыйфаты беркайчан да юкка чыгарга тиеш түгел. Җир шарында кешелек дөньясы нәкъ менә кешелекле, аңлы кешеләрнең булуы хакына гына сакланып килә. Андый кешеләрнең билгеле бер процентны тәшкил итүе хакына. Менә шул процент тиешле шкаладан түбән тәгәрәсә, безнең белән, белмим, ни булып бетәр... Уйлап табылган һәр коралга җавап итеп яхшырагын уйлап табып була, әлбәттә. Ә менә яхшылыкка җавап итеп яхшылык эшли алу – күпләр өчен шактый кыен мәсьәлә.

Ел саен **«В бой идут одни старики»** фильмын карыйбыз. Яки сугыш турындагы башка **совет фильмнарын**. Безне тәрбияләп үстергәннәрдер, күрәсең, кадерле алар, якын. Бәлки, хәзер сугыш турында тагын да яхшырак фильмнар бардыр, әмма мин телевизорны сирәк карыйм, әлегә юлыкканым юк.

Җиңү көне алдыннан үзебезнең хәзерге тормышыбыз турында уйланып йөрдем. Сугыш сөреме азмы-күпме таралган, еллар узган, әмма, ни өчендер, без һаман акылга утырмыйбыз. Тарихта шулай: кем белемлерәк, фән һәм техника ягыннан үсештәрәк, димәк, шуның җиңүгә шансы да күбрәк. Әмма бүген без нәрсә белән мактана алабыз соң? Россиядә, бигрәк тә бездә, татарларда, фән юк дәрәҗәсенә төшеп бара. Шуңа безгә хөрмәт тә юк, безнең белән санлашмыйлар. Безгә кичекмәстән акыллы, кешелекле үз галимнәребезне арттырырга, татар фәнен ныгытырга кирәк. Менә шул булыр Җиңүебез!



PRESSA.RU



# «АЛАРДА – ТОРМЫШЧАН ДӨРЕСЛЕК»

**Рәмис Нәҗмиев, фотограф:** Минем өчен Бөек Ватан сугышының асылын яктыртучы әсәрләр – ул «лейтенантлар прозасы» вәкилләренеке: **Василь Быков, Юрий Бондарев, Константин Симонов.** Алар, сугышны кичкән кешеләр буларак, үз язмышларына нигезләнеп язганнар, шуңамы, әсәрләрендәге детальләр, вакыйгалар үстерелеше, сурәтләү рәвеше – һәммәсеннән дә тормышчан дөреслек бөркелеп тора, чынбарлыкны бар масштабында күз алдына китереп бастыра. Аларны укып, сугышның «эчендә» булып кайткандай хис итәм үземне. Һәм ул сугышның чынлап та куркыныч икәнлеген аңлыйм.

Фильмның, визуаль рәт буларак, тәэсире җитез. Көчле картиналарның кадрлары, символикасы кешенең аң катламы астына кереп урнаша да анда озакка кала... Сугыш фильмнарыннан миңа түбәндәгеләр зур тәэсир ясады: **«Спасти рядового Райана», «Отец солдата», «Взвод», «Цельнометаллическая оболочка», «В бой идут одни старики», «Женя, Женечка и «Катюша», «Цветы войны», «Империя солнца»...** Бу сугыш XX гасырның иң зур афәте булган, дисәк, ялгышмабыздыр. Аны СССР белән фашист Германиясе арасындагы конфликт буларак кына кабул итәргә ярамый. Совет фильмографиясендә ул нигездә шулай тәкъдим ителсә дә. Икенче Бөтендөнья сугышына китергән сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре дә бик катлаулы. Ул бары комплекста караганда, анализлаганда гына азмы-күпме аңлашыла башлый. Шуңа мин тәкъдим иткән арсеналда һәм СССРда төшерелгән фильмнар да, һәм бу сугышка карата Америка режиссерлары **Стэнли Кубрик** белән **Стивен Спилберг** карашларын чагылдырган фильмнар да, Кытай режиссеры **Чжан Имоу**ның мөнәсәбәтен белдергән полотно да бар.

---






# «УЕННАН УЙМАК ЧЫГА»

**Резеда Гарипова, режиссер:** Сугыш турында беренче тапкыр әбием сөйләгәннәрдән ишетеп белдем. Күрәсең, ул сөйләгән вакыйгалар бала психикасына шулкадәр нык тәэсир иткән, әлеге ерак тарихлар минем күз алдыма әле һаман да сурәтләр рәвешендә килеп баса. Мин аларны башта ук – сөйләү барышында ук – шулай күргән идем: кадрлар итеп...

Сугыш турындагы әсәрләрдән аеруча якыннары – **Борис Васильевның «А зори здесь тихие»** һәм **Эрих Мария Ремаркның «Время жить и время умирать» әсәрләре**. Бу китапларның төп принцибы: кеше нинди генә шартларда да кеше булып калырга тиеш. Хәтта кеше булып кала алмаслык ситуациядә дә. Аларда замана кешеләре онытып, дөресрәге, онытырга өйрәнеп барган бик мөһим рухи сыйфатлар турында сүз бара, ул сыйфатлар кайчандыр кагыйдә булган бит... «Система» һәм аның «шөрепләре» темасына сүз куертып тору кирәкмидер, әмма без ул темадан котыла алабызмы икән? Нәкъ менә шундый бүленешкә нигезләнгән дөньяда әле һаман да низаглар, сугышлар чыгып тора, юкка түгел бит. Туктый алмас шикелле тоела бу механизм...

Хәзерге вакытта актерлыкка укый торган студентларым белән **Тод Штрассерның «Волна» дип аталган әсәре** буенча спектакль әзерлим. Бу әсәр чынбарлыкта булган вакыйгага нигезләнеп язылган. 1967 елда Америкада, Калифорниядәге кечкенә генә бер мәктәптә, тарих укытучысы Бен Росс яшүсмерләргә нацизмның никәнен күрсәтү өчен уен формасында эксперимент уздыра. Әмма уеннан уймак чыга... Әлеге тарих миндә Икенче Бөтендөнья сугышы һәм тоталитаризм феномены белән ассоциацияләр уята, без яшәгән бүгенге чынбарлык хакында уйландыра.

Фильмнарга килгәндә, иң беренче чиратта – **Андрей Тарковскийның «Иваново детство» картинасы**. Аны карап, яшәүнең һәм иминлекнең тәмен тоярга өйрәнәсең. Адәм баласына үзе булып кала алуның мөһимлеген...

## «КУЛЛАРЫ АЛТЫН КЕШЕ ИДЕ»

**Нурзадә, җырчы: Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй** әсәрләрен яратып укый идем. Гомумән, Бөек Ватан сугышына кагылышлы китапларны да, фильмнарны да бик яратам. Аларда тәрбия көчле, безнең заманга шундый тәрбияле торган әсәрләр бик кирәк. Аеруча кадерле әсәрләрдән **Шамил Рәкыйповның «Кызлар-йолдызлар»ын** атый алам. Хәзерге көндә дә бик сокланам ул туташ-ханымнарга. Менә без куркыныч алдында торып калсак, шулай булдыра алыр идекме икән?

**«Сталинград», «Аты-баты, шли солдаты», «Снайперы», «Апостол», «На безымянной высоте»** һәм сугыш тематикасын яктырткан башка бик күп фильмнарны кат-кат карадым. Хәзер нәрсә генә дисәләр дә, алар туган җирне, Ватанны яратырга өнди, үз илең һәм аның кешеләре белән горурланырга өйрәтә.

Мин төшемдә бик еш сугыш күрәм. Нәкъ менә Бөек Ватан сугышын. Һәм мин анда – партизан. Илемнең азатлыгы өчен көрәшәм.

Бабам сугыш ветераны иде. Ярата идем үзен. Ул яуда ике тапкыр яраланган, без үскәндә таяк белән йөри иде. Ләкин шулкадәр көчле рухлы, эшчән кеше буларак хәтерлим үзен. Куллары алтын мичче иде ул.



## «ТАРИХ КАБАТЛАНМАСЫН ӨЧЕН»

**Сәйран Сөләйман, кырым-татар язучысы:** Сугыш чорын яктырткан әсәрләрдән **Борис Васильевның «А зори здесь тихие»** һәм **Борис Полевойның «Повесть о настоящем человеке» повестларын** яратам. Кызганыч, соңгы вакытта Бөек Ватан сугышының әһәмиятен киметергә, аның каһарманнарын кимсетергә тырышып язучылар очрый. Блогерлар да бу мәгънәсез, һәм, әйтергә кирәк, аларның үзләрен үк бизәми торган эш белән шөгыльнәләр. Әмма онытып җибәрәләр: бу яуда сугышкан гап-гади кешеләр афәт алдында куркып, тез чүгеп калмаганнар, ә нацизм кебек куркыныч режимны, миллионнарча корбаннар хисабына булса да, җиңгәннәр бит. Ә нацизмның, фашизмның теләсә кайсы вакытта яңадан баш калкытуы бар.

Бөек Ватан сугышы чорында дистәгә якын кырым татары Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды. Очучы-ас Әхмәтхан Солтан – хәтта ике тапкыр Советлар Союзы Герое. Сугыш вакытында ул 603 очыш ясый, 150 һава сугышыннан имин чыга, шул яулар вакытында башка очучылар белән бергә – 19, үзе генә 30 фашист самолетын бәреп төшерә. Аның турында китаплар, фильмнар бар, апрель аенда гына «Россия-1» каналыннан чираттагы бер фильмны күрсәттеләр. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры, сугыш чорында разведкада эшләгән каһарман Алимә Әбденанова турындагы китапны укырга киңәш итәм. **«Алиме. Крымская легенда»** дип атала ул, авторы – тарихчы **Владимир Лота.**




Язучы **Әбелгазиз Вәлиевның китаплары** бик гыйбрәтле. Ул озак еллар дәвамында кырым татарларының Бөек Ватан сугышында уйнаган ролен өйрәнде, меңләгән кырым-татар офицерының язмышын барлап чыкты. Менә бу китапларда онытылып барган тарихны тәфсилләп яктыртты: **«Къараманлар ольмейлер»** (**«Герои не умирают»**), **«Дженк офицерлери»** (**«Боевые офицеры»**), **«Фашизм махбюслери»** (**«Узники фашизма»**), **«Муаребе аскерлери»** (**«Солдаты войны»**) һ.б.

**«Судьба человека», «Аты-баты, шли солдаты», «Баллада о солдате», «Летят журавли», «В августе 44-го»** – бу фильмнар сугыш турында гына түгел, ә кешелек кыйммәтләре турында да. Чын мәгънәсендә шедевр буларак исәпләнергә хокуклы һәрберсе. Аларны карап үсмәсәк, без тормышны белмәс идек.



# ТАТАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ АЛТЫНЧӘЧЕ

Татар профессиональ музыка сәнгате формалашуын һәм үсешен ТАССРның халык артисткасы Галия Кайбицкая һәм мәшһүр композитор Салих Сәйдәшевтан башка күзаллап булмый. Бу затлы шәхесләр гасырлар дәвамында буыннан-буынга тапшырылган моңлы, шаян халык җырларын туплап, эшкәртеп, баетып, татар музыкасын профессиональ дәрәҗәгә күтәрүчеләр. Композиторлар белән бергә иңгә-иң торып эшләү, иҗади тандем булдыру – бу өлкәдә дә Галия Кайбицкая аерым бер урынны алып тора.

Автор:
Хәмидә Гарипова

## ҖЫРЛЫ-МОҢЛЫ ЧИШМӘ БАШЫ

Галия Кайбицкая 1906 елның 21 маенда Җаек шәһәрендә алдынгы карашлы татар мәгърифәтчесе, дин әһеле, атаклы «Мотыйгыя» мәдрәсәсен оештырган Кече Кайбыч кешесе Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин гаиләсендә туа. Гаиләнең бай традицияләре Галиянең тормыш һәм иҗат юлын билгеләүдә зур роль уйный. Галиянең әнисе Гыйззинас 30 елдан артык мәдрәсәдә кыз балалар укыта. Биредә аларны тегәргә, чигәргә, җырларга, үз-үзләрен тотарга, тормыш алып барырга өйрәтәләр. Әдәби кичәләр оештырыла. Галия Тукай шигырьләрен чатнатып яттан сөйли, биеп тә җибәрә, «Туган тел»не яратып җырлый, башкалар да аңа кушыла. Өйдә скрипка, пианино аһәңнәре тынып тормый. Әтиәнисенең моңлы тавышын тыңлап, үзе дә җырлап үсә Галия.

Әнисе татар дөньясында беренче булып хатын-кызлар хоры оештыра. Үсмер чагында Галия шуның башлап җырлаучысы була. Җаекта рус театры эшли. Революциядән соң анда татар спектакльләре кую мөмкинлеге ачыла. 15 яшьлек Галия Җаекта бертуган абыйлары Әдһәм һәм Хәмит оештырган татар театр труппасы спектакльләрендә уйнап, тамашачы алдында беренче чирканчык ала. Галиянең бертуган абыйсы гастрольләр вакытында татар, башкорт, рус җырларын, опералардан арияләрне бердәй югары һөнәри дәрәҗәдә башкарып, Россия киңлекләрендә дан алган, хаклы рәвештә «татар Шаляпины» дип атап йөртелгән, татар милли музыка культурасы тарихындагы беренче профессиональ җырчы-артист Камил Мотыйгый сеңлесенең табигый сәләтен вакытында күреп ала, аңа сәнгать юлын сайларга киңәш итә.

Г. Кайбицкая «Галиябану» операсында Галиябану ролендә.

## КАНАТЛАР ОЧКАНДА НЫГЫЙ

1923 елда Галия апасы Әминә белән Казанга килә. Калага аяк басуга, Тукай каберенә барып, үз туганнарыдай якын күргән шагыйрьнең рухына дога кылалар. Туташлар татар театр техникумына укырга керә. Галия студент чагында ук драма театрындагы музыкаль спектакльләрдә катнаша башлый. Шул вакытта мөхтәрәм ата-бабасының туган җире Кече Кайбыч хөрмәтенә Кайбицкая тәхәллүсен ала.

Тирән белемгә омтылган сәләтле кыз Көнчыгыш музыка техникумына кабул ителә. Сәйдәш Галиягә җыр дәресләре бирә. Кәрим Тинчурин өметле яшь туташка Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» спектаклендәге төп рольне ышанып тапшыра. Галиянең ихлас уйнавын ошатып, театрга эшкә чакыра. Тәүге адымнарын атлаучы музыкаль театр сәнгатенең күренекле эшлеклеләре: драматурглар – Кәрим Тинчурин, Мирхәйдәр Фәйзи, композиторлар – Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши, актерлар – Хәлил Әбҗәлилов, Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарскаялар белән бергәләп иҗат итү Галиянең иҗади үсешенә, киләчәктә халык күңелендә тирән эз калдырачак милли җанлы актриса, көчле рухлы шәхес булып формалашуына уңай йогынты ясый. Ул моңлы йомшак тавышы, тәрбиялелеге, чибәрлеге, тирән хисләрне сизгер йөрәге аша үткәреп, тамашачы хозурына тапшыра, аларның күңелен кузгата алуы белән аерылып тора. Музыкаль драмалардагы җырлы-моңлы, кайчакта дәртле-шаян, кайвакытта гамьле-моңсу образларны үзенә генә хас ягымлылык, эчкерсез җылылык белән җиренә җиткереп башкарып, халык арасында тиз арада таныла. Фәйзинең «Асылъяр»ында – Ләлә, Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә – Мөршидә, «Зәңгәр шәл»дә – Мәйсәрә, «Кандыр буе»нда – Гөләндәм, «Сүнгән йолдызлар»да – Сәрвәр... Тырыш хезмәт җимешләре озак көттерми, рольдән рольгә үсеш күзәтелә. Мәдәни җәмгатьчелек актив иҗат итүче актрисаның хезмәтен уңай бәяли. Фәтхи Бурнашның «Таһир белән

Фотолар музей архивыннан алынды

Зөһрә» спектаклендә Галиянең уенын күргән Һади Такташ «Кызыл Татарстан» газетасында: «Татар сәхнәсендә тагын бер йолдыз кабынды», – дип язып чыга. Музыкаль драмаларның бизәген генә түгел, үзәген тәшкил иткән көйләренең шактыен Сәйдәш Галия тавышын күздә тотып иҗат итә.

### СӘХНӘДӘ УЙНАМЫЙ, ЯШИ...

Казанның иң борынгы сәнгать учагы – бүгенге көндә Муса Җәлил исемен йөртүче дәүләт опера һәм балет академия театры 1791 елда ачылса да, анда гастролер итальяннар гына спектакльләр куеп киткәли. Казанның үз рус труппасы тарафыннан әзерләнгән беренче опера – «Иван Сусанин» 1874 елның 26 августында куела. XIX гасырның 40нчы еллары башында милли җанлы татар зыялылары үзебезнең опера театрын оештыру идеясе белән яна. Һөнәри белемле милли кадрлар әзерләү зарурияте көн кадагына баса. 1934 елда Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясе каршында Хәмит Төхвәтуллин җитәкчелегендә ачылган татар опера студиясенә бер төркем талантлы яшьләр: Ситдыйк Айдаров, Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Мәрьям Рахманкулова, Мөнирә Булатова, Усман Әлмиев, Сара Садыйкова, Нияз Даутов, Фәхри Насретдинов, Асия Измайлова, Зөһрә Байрашова, Галия Кайбицкая сайлап алына. Бер дигән вокал мөмкинлекләренә һәм актерлык сәләтенә ия, драма театры сәхнәсендә җырлы рольләр башкарып шомарган Галия студентлар арасында кыйммәтле йөзек кашыдай балкый. Консерваториядә уку аның дөньяга карашын үзгәртә, фикерләү дәрәҗәсен яңа баскычка күтәрә, күңел офыкларын киңәйтә, вокал мөмкинлекләрен камилләштерә. Укуын уңышлы тәмамлап, 1939 елда труппа Казанга кайта.

Опера театры сәхнәсенә тәүге аяк басуына карамастан, Галия югалып калмый. Озак та үтми, ул яңа ачылган милли опера театрының әйдәп баручы солисткасына әверелә. 1939–1941 елларда бирегә әдәби бүлек мөдире булып эшләгән шагыйрь Муса Җәлилнең «Алтынчәч» (композиторы Нәҗип Җиһанов) операсында төп партияне башкару Кайбицкаяга алкышлар һәм дан китерә. 1940–50нче елларда куелган барлык татар операларында, музыкаль комедияләрдә диярлек төп рольләрне башкара ул. «Түләк»тә – Сусылу, «Башмагым»да – Сәрвәр, «Качкын»да – Рәйханә, «Наемщик»та – Гөлйөзем һ.б. Рус һәм чит ил операларында катлаулы партияләрне аңа ышанып тапшырулары очраклы хәл түгел. «Риголетто»да – Джильда, «Травиата»да – Виолетта, «Фауст»та – Маргарита, «Патша кәләше»ндә – Марфа, «Кар кызы»нда Кар кызы рольләренең сәхнәдә югары зәвык белән гәүдәләнеше аның көчле талантын чагылдыра. Сирәк очрый торган яңгыравыклы, бизәкле мелизмнарга бай ягымлы тембрлы табигый тавышы (колоратур сопрано), әзләнүчәнлеге, тырышлыгы Кайбицкаяга башкару осталыгы биеклекләрен яуларга, сәнгать сөючеләр арасында киң танылырга ярдәм итә. Галия гүя сәхнәдә уйнамый, яши: һәр сүзен, хәрәкәтен ихлас, тормышчан, җанлы итеп гәүдәләндерә.

### КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ АША ЕЛМАЮ

Коточкыч репрессияләре белән талантлы шәхесләрнең язмышларын имгәткән шомлы еллар шаукымы Галияне дә читләтеп узмый. Җырчының олы улы, татар милли архитектурасына нигез салучы, архитектура фәннәре докторы Сәйяр Ситдыйков Галия апаның Кайбычтагы музеендагы бер очрашу вакытында: «Әни үзенең халыкны рухландыручы, аның күңелен сугаручы, җәмгыятькә кирәкле һөнәр иясе булуын аңлап иҗат итте. Бу аңа чиксез авырлыкларга бирешмәскә көч бирде. Дин әһеле кызы булуы аркасында, совет заманы түрәләренең әнине мораль яктан изүен, каныгуын, көнчелек белән тәгәрмәчкә таяк тыгуын, нахакка күз яшьләре түктерүен хә-

Г.Кайбицкаяның Олы Кайбычтагы музее.

терлим. Авызы тулы кан булса да, чит-ятлар алдында төкермәде ул. Күз яшьләрен эчкә йотып, сәхнәгә шат елмаеп, көр күңел белән чыгарга үзендә көч тапты. Газаплы сугыш чорында, халкыбыз ачлы-туклы михнәт чиккән елларда әни тамашачыга рухи ныклык бирергә омтылды. Тарих барысын да үз урынына куйды: әнигә тәтемәгән шәхси бәхетне балаларына татырга насыйп булды», – дип сөйләгән иде.

## ТУКАЙ ТУКАЙ БУЛМАС ИДЕ, МОТЫЙГУЛЛА БУЛМАСА...

Миһербанлы Кече Кайбыч халкы Төхфәтулла хәзрәтнең ятим калган улы Мотыйгулланы мәхәллә акчасына әүвәле данлыклы Кышкар мәдрәсәсендә укыта. Ул анда Тукайның әтисе булачак Мөхәммәтгариф шәкерт белән дуслаша. Якташларының иганәчелек ярдәме белән егет Каһирәдә төпле дини белем ала. Гыйлем туплап, дөнья күреп кайткач, кыз туганы янына Җаекка юл тота. Дини җәмәгатьчелек хәлфәнең тирән белемле, киң карашлы булуына сокланып, шәһәр мәчетендә имам булырга күндерә.

Алдынгы карашлы хәзрәт «Мотыйгыя» мәдрәсәсен ача, анда белем бирү яңача алып барыла. Дини һәм дөньяви гыйлемнәр укытудан тыш, шәкертләренең табигый сәләтләрен ачу өчен уңай шартлар тудырылган белем учагыннан күренекле шәхесләр, кайнар йөрәкле замана яшьләре үсеп чыга. Шуларның берсе татар профессиональ театрына нигез салучы Габдулла Кариев булса, иң күренеклесе – татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукай. Мәдрәсәгә очраклы рәвештә килеп эләккән тома ятим Апушның Мөхәммәтгариф мулла улы икәнлеген белеп алган Мотыйгулла хәзрәт аны үз канаты астына сыйдыра. Үз балаларына тиң күреп тәрбияләп, белем биреп кенә калмый, сәләтен ачарга ярдәм итә. Шигырь төзелешен өйрәтүче гаруз фәнен Габдуллага төшендерүче, аның белән шахмат уйнаучы, гаилә бәйрәмнәрендә сәләтле шәкертнең беренче әсәрләрен укуын оештыручы, искиткеч бай китапханәсендәге классик язучылар, аеруча Пушкин, Лермонтов әсәрләре белән танышырга рөхсәт бирүче мәрхәмәт иясе дә ул. Ә олы улы – беренче татар газета-журналлары мөхәррире һәм нашире Камил Мотыйгый, мәдрәсә тәмамлаган Тукайны типографиягә хәреф җыючы, редакциягә корректор итеп алып, эшле-ашлы итә, иҗат җимешләрен бастырып, халыкка таныта. Тукай бу гаиләдә еш кунак була. Бишектә яткан елтыр күзле нәни Галиягә сокланып: «Сөбханалла! Еламый бит бу сабый, җырлый түгелме соң? Тавышы иллә дә матур, моңлы! Җырчы булыр бу, фаразан», – дип әйтүе фәрештәнең «Амин» дигән чагына туры килгән, күрәсең.

Миңа якташым Галия Кайбицкая белән якыннан аралашу насыйп булды. Аның: «Тукай Тукай булмас иде, Мотыйгулла булмаса», – дип кабатлавы әле дә исемдә.

РСФСРның халык артисты Айрат Арсланов белән Актерлар йорты янында.

## ЯКТАШЛАРЫ ОНЫТМЫЙ

Галия Кайбицкая ТАССРның халык артисткасы исеменә, «Почет билгесе», Хезмәт Кызыл байрагы орденнарына лаек була. Арабыздан китүенә 23 ел узса да, талантлы җырчының нурлы образы халык хәтереннән җуелмады. Кайбычта, Казанда аның исемендәге урамнар, Уральскида Төхвәтуллиннар музее бар. 1998 елда Олы Кайбычта ачылган музеенда Галия Кайбицкаяның үзе язган шигырьләре, хатлары, фотолары, афишалары, буклетлары, ноталар дәфтәре, пианиносы, сәхнә күлмәге, китап һәм кием шкафы, радиосы, перчаткалары, бизәнү әйберләре, өстәл япмасы; әтисенең чалмасы, тәсбихы, китаплары; Каһирәнең «әл-Әзһәр» дини академиясендә белем алган Мотыйгулла хәзрәт һәм аның улы Камилнең Мәккәгә хаҗ кылуы истәлеге – изге шамаил һ.б. ядкәрләр кадерләп саклана. Галия Кайбицкаяның үз мемуарлары гаять кызыклы, аңа багышлап язылган мәкаләләр бихисап. М. Җәлил, С.Хәким, М. Хөсәен һ.б. шагыйрьләр, аның талантын зурлап, шигырьләр иҗат иткән. С. Вәлиди «Кайбыч кызы Галия» дигән җырын язды. Фоат Галимуллин аның гыйбрәтле тормыш юлын «Талантлар йолдызлыгында» дип аталган документаль повестенда яктыртты.

2013 елдан Галия Кайбицкая исемендәге Халыкара вокал бәйгесе гамәлгә куелды.

Фото: Андрей Титов



PRESSA.RU


Алексеевск штб
Изге чишмә
Зур Тигәнәле
Байчыклы Барангул
(Красный Баран)
Арбузов-Баран
Биләр




# Алексеевск районы

## ТУКУЧЫЛАР, ИГЕНЧЕЛӘР... ҺӘМ БАДМИНТОНЧЫЛАР ЯГЫ

Алексеевск районы матур бер пазлны хәтерләтте миңа: бер якка күз салсам, анда – бөек вакыйгаларның шаһите булган археологик һәйкәл, икенче тарафка карасам – ут чыгарып бииләр, бадминтонда уйнап кинәнәләр, арырак атласам – топонимик табышмак, чыгу юлында – башкисәрләр турында хикәят. Һәм боларның барысы да җитеннән тукылган чыбылдык артында. Киттек, карыйбызмы?




Авторлар: Олеся Бондаревская, Владимир Матылицкий



Фото: Ната Смирнова

Җуелып барган туку ысуллары, колакка ят тоела башлаган терминнар белән танышырга теләсәгез, бирегә рәхим итегез!



## УЗГАН ЧОРЛАР ТУКЫМАСЫ

Алексеевскиның визит карточкасы чыннан да төрле төсләрдән тукылган. Мондагы туку фабрикасы 2017 елда үзенең 90 еллыгын билгеләп үтәчәк.

– Тукыманы кулдан агач станнарда тукый торган фабрикалар Россиядә икәү генә: берсе – бездә, икенчесе – Түбән Новгород өлкәсендә, – ди фабриканың директоры Фирая Сергеева. – Предприятиебез кечкенә генә булса да, товарларыбыз Россиядә дә, чит илләрдә дә танылган. Күптән түгел генә Брюссельдә Сабан туенда булып кайттык. Казанга килгән зур кунакларны каршылаганда чәкчәк астына куеп чыгара торган тастымалны да безнең осталарыбыз тукыды.

Станда эшләү көч һәм җитезлек сорый – Алексеевк тукучылары гел яхшы физик формада. Сүз уңаеннан, бизәкле бер сөлге туку өчен берничә көннән алып, берәр айга кадәр вакыт таләп итәлә икән.

– Бу һөнәрне, аның җылысын, әби-бабаларыбыз истәлеген саклыйсы иде. Европада, мәсәлән, мондый нәрсәгә бик сак карыйлар. Әнә итальяннарның муран пыяласы – дөньяга танылган бренд. Безнең фабрика да халык җәүһәрләре рәтендә үзенең лаеклы урынын алыр, дип ышанабыз.

Төрле төсле җепләр белән чуарланган туку цехы буйлап атлыйбыз. Кайчандыр укыганым искә төшә: грек эпосларының күп кенә хатын-кыз каһарманнары – Цирцея, Пенелопа, Елена – оста тукучылар булган. Ми-

Фото: Ната Смирнова

Район башлыгына тиз генә үтеп керә алмадык – халыкны кабул иткән чагына туры килдек. Башлык яныннан һәркемнең диярлек уңай җавап алып чыгуы безне бик сөендерде.

фик алиһәләр язмыш җепләренең озынлыгын үлчәгән. Нәкъ менә шулай бүгенге алиһәләр дә Алексеевск язмышының үз тукымасын тукыйлар.

## ҖИТӘКЧЕ – ЧУЛМАН ХАКЫНДА

Алексеевск районы башлыгы Владимир Козонков белән күрешергә баргач, без аның халыкны кабул иткән чагына туры килдек. Һәркемнең үз йомышы: кемдер чиркәү салырга ярдәм сорый, кемнеңдер туганына медицина ярдәме кирәк, кемдер түбә башын ябарга булышуларын үтенә...

– Күпчелек мөрәҗәгатькә уңай җавап бирдегез. Кемгә булышасын ничек билгелисез? – дим.

– Монда, администрациягә, иң соңгы чиктә генә киләләр. Без инде – иң соңгы инстанция. Мөмкин булганча, кешеләргә ярдәм, таяныч булсын, дип тырышам. Бездә «усак авыл»лар күп – андагы йортлар йөз ел чамасы элек усак агачыннан төзелгән. Анда 70-80 яшьлек пенсионерлар – бөтен гомерләрен дип әйтерлек хезмәткә багышлаган сыер савучылар, механизаторлар, трактористлар яши. Хәзер инде үз чиратында дәүләт тә, пенсиядән тыш, аларны бераз кайгыртыр, дип көтәләр. Бер яктан алар хаклы да. Ләкин мондый ярдәм өчен безгә бюджеттан акча каралмаган шул, һәм мин элеге финанс йөген үз җилкәләренә алган эшкуарларга бик рәхмәтле.

Владимир Константинович район тормышы хакында сөйли. Козонков өчен Алексеевск – эш урыны гына түгел, ул аның туган җире.

– Яраткан урыныгыз бармы монда?

– Мондый иркенлекләр булганда, ниндидер бер урын турында сөйләп була микән? Бер нәрсәне генә әйтә алам: алтын иген кыры уртасында яки биредән иксез-чиксез булып күренгән Чулман ярында торганда аңлыйсың – сүз белән әйтеп аңлата алмаслык хисләрне туып-үскән җир генә бирә ала икән.

## ИНГЛИЗЛӘР ШӨГЫЛЕ

Бадминтон уйнау өчен беренче корт Англиядә – Бадминтон-хаус утарында барлыкка килгән. Алексеевскиныкылар инглизләрнең беренчелегенә дәгъва кылмый анысы, аларның үз горурлыгы: республикадагы иң яхшы бадминтон секциясе алар яшәгән бистәдә ачылган.

– 2003 елда ул чактагы район башлыгы Алексей Демидов Германиядән тренер Давид Камиладзены чакырып алды, – ди 3нче спорт мәктәбе директоры Рөстәм Кәбиров. – Ул безгә үз тренерларыбызны үстерергә булышты. Бүген без Татарстанның үзәк лигасында иң яхшылардан. Март аенда Самарада узган бөтенроссия турнирында безнең кече төркемебез чемпион булды, өлкән төркем – дүртенче урында.

15 яшьлек Тимур Вәлиуллин – танылып килүче җирле бадминтон йолдызы. Беренче карашка җиңел генә күренгән уен аны нәрсәсе белән җәлеп иткәнлеген сорашам.

– Миңа тактика һәм стратегия ошый: яраткан алымнарым – кистерү һәм кыскарту. Волан каршы уенчы көтеп торган җиргә – кырның уртасына килеп җитмәсен, ә сетка янында ук җиргә төшәрлек булсын, – ди Тимур. – Шулай ук физик ягы да җәлеп итә: бер уен барышында спортчы 15 чакрым араны йөгереп уза, ә воланның тизлеге сәгатенә 493 чакрым була ала.

## «БАКЧА» ҮСТЕРҮЧЕЛӘР

Кечерәк кенә бүлмәдә кызлар бии. Аяк асларыннан очкын чәчри, бөтерчек кебек бөтереләләр. Биюләрен зифа буйлы брюнетка – «Сад» эстрада-хореография студиясе җитәкчесе Марина Калинина күзәтә. Аны һәм аның ире Юрий Калининны монннан 25 ел элек Алексеевскига Казаннан чакыртып кайтарткан булганнар. «Сад»ның инде җимешләре дә бар: йөздән артык номер, йөздән артык бала, республика һәм ил күләмендә узган конкурсларда алынган бихисап бүләкләр.

– Марина фәлсәфи нигезгә корылган катлаулы номерлар куярга ярата. Ятимнәр турындагы бер номеры бар аның – спектакль дип әйтерлек. Номер ахырында барлык ятимнәрне дә алып бетерәләр, ләкин бер бала кала. Бу номер җитәкчеләребездә фикер каршылыгы тудыра, – ди номерларга музыкаль бизәлеш ясаучы Юрий.



Ярминкәләре белән шаулап-гөрләп торачак, Воскресения Христово храмының чаңнары Чулман өстенә челтерәп коелачак көнгә дә күп калмады инде. 2016 елның июнендә биредә бөтен Россиягә билгеле «Алексеевские перезвоны» фестиваленең инде менә 14нчесе узачак.

PRESSA.RU

КФУның визуальләштерү һәм уеннар ясау белән шөгыльләнүче лабораториясе белгечләре «Тарих» виртуаль стенды» проекты кысаларында Биләрдәге Җәмигъ мәчетенә виртуаль реконструкция ясады. Урта гасырларның архитектура үрнәге булган бу һәйкәлнең элек ни рәвешле булганлыгын лабораториянең сайтына кереп карап була.

Әле кайчан гына Красный Баранга Ник. Баран – Никольский Баран терәлеп торган. Хәзер инде авыллар кушылган, Ник. Баранның күрсәткеч тактасы да калмаган.

– Берсендә Мәскәү Кремлендә узачак концертка сайлап алу өчен канатлы кыз-кош хакындагы номер алып бардык. Жюри әгъзалары арасында Прагадагы бию академиясе профессоры да бар иде. Татар кешесе булып чыкты ул! Жюридагыларның башкаларына безнең хакта әйтергә вәгъдә бирде. Ләкин безнең номер болай да һәммәсен тетрәндерде, аны Кремльдә биер өчен сайладылар.

Студия, барыннан да бигрәк, иҗат карьерасын дәвам иткән шәкертләре белән горурлана. Алар арасында Сергей Жигунов фильмында Д'Артаньянны уйнаган Риналь Мөхәммәтов та бар.

## ТАРИХЛЫ АВЫЛЛАР

Биләргә таба кузгалабыз. Юл буенда элмә такталар кала – Арбузов-Баран, Красный Баран. Соңгысы татарча Байчыклы Барангул дип йөртелә. Кайдан мондый кызык атамалар? Җавабы һич тә терлекчелеккә бәйле түгел.

– VIII гасыр ахырында бу җирләргә төрки кабиләләр – болгарлар, кыпчыклар, барсиллар, сәкәлләр, бәрәнҗәрләр килеп урнаша. Менә бәрәнҗәрләр авылга нигез салганнардыр да инде, мөгаен. Авылга үз кабиләләренең атамасын да биреп калдырганнар, күрәсең, – ди Биләр дәүләт тарих, археология һәм табигать музей-тыюлыгының директоры Энас Кутуев. – Тарихи документларда бүгенге Красный Баран еш кына Кр. Баран исеме белән очрый. Монда нигездә керәшеннәр яши, һәм авылның баштагы атамасы Крещеный Баран булса кирәк. Ә «Красный» атамасы коммунистлар чорында барлыкка килгәндер.

Арбузов-Баранга килгәндә, аның атамасы XVII гасырда авылга хуҗа булып торган генерал Арбузовка бәйле. Арбузов-Баранда танылган рус химигы Александр Арбузов туган. Моннан берничә генә чакрымда русның икенче бөек химигы – Александр Бутлеровның нәсел утары урнашкан. Кызыксынучан һәм тирән фикерле кеше буларак, Бутлеров химияне өйрәнү белән генә чикләнмәгән, башка фәннәр, аерым алганда, умартачылык белән дә кызыксынган. Умарта ояларын рамлы итеп ясауны нәкъ менә ул уйлап тапкан. Алексеевск кортлары җыйган бал әле дә гаҗәеп тәмле. Ә бу ике олуг галимгә багышланган исткиткеч музей Биләрдә урнашкан.

## УРТА ГАСЫРЛАРДАН БАШКАЛА ХӘРАБӘЛӘРЕ

Биләрдән ерак түгел генә Җәмигъ мәчете янында тукталабыз. Хәзер аның нигезе генә торып калган. Элеккеге бинаны күзаллау өчен берникадәр биеклектә стенасын һәм колонналарын (җәмгысе 24) торгызганнар. Янәшәдә баганалар рәте тезелеп киткән, алары мәчетнең башка өлешен күрсәтү өчен.

– Якынча X гасыр башында Биләр шәһәрендә агач мәчет төзелә. Ә инде Багдад хәлифәтеннән илчеләр килеп, 922 елда рәсми төстә ислам дине кабул ителгәннән соң, алты рәт булып тезелгән ак колонналы, аерым торган манаралы таш мәчет салына. Бинаның мәйданы 2,5 мең квадрат метрны тәшкил итә, – дип сөйли Энас Кутуев. – Монда шундый зур корылманың булуы, ул бит әле дини генә түгел, административ функцияне дә үтәгән, шул чорда Биләр шәһәренең статусы урта гасыр дәүләтенең башкаласы статусына туры килүен күрсәтә.

Вакыт аяусыз: җир йөзендәге күп нәрсә юлбасарлар яки яулап алучылар тарафыннан җимерелмәгән, ә гап-гади тормыш шартларында юк ителгән. Мәсәлән, Император фәннәр академиясе хезмәткәре Николай Рычков үзенең язмаларында Җәмигъ мәчетенең манарасын XVIII гасырда шушында яшәүчеләр сүтеп алып бетергән, дип фаразлый. Исән калган кадәресе әнә шуның өчен дә кыйммәтлерәк һәм кызыклырак.

## КҮККӘ БАСКЫЧ

Саф һәм салкын сулы изге чишмә Биләрдән биш чакрымда гына, матур һәм пөхтә парк уртасында челтери. Шушында ук уникаль экспонатлар коллекциясе булган Археология музее да урнашкан. Алар X–XII гасырларда

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ – «ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!




Суы шифалы дип саналган «Изге чишмә» мөселманнарны, христианнарны һәм мәҗүсиләрне бер-берсенә якынайтучы урынга әверелде. Парк эчендә мөселманнарның дини йолаларын башкару өчен урын каралган. Шулай ук бирегә мәҗүсилек яхшы сакланып калган чуваш, мари халыклары да күп килә.

Фото: Ната Смирнова

Идел буе Болгар дәүләтенең сәүдә, тарихи, мәдәни үзәген тәшкил иткән, урта гасыр Евразиясенең иң зур шәһәре булып, 1236 елда монгол гаскәрләре тарафыннан нигезенә кадәр җимерелгән гүзәл Биләрнең тормышы хакында сөйли.

Тимер баскычлардан (басмалары 444) итәгендә «Изге чишмә» типкән Хуҗалар тавына күтәреләбез. VIII–IX гасырларда җирле төрки телле кабиләләр әле мәҗүси булганнар. Алар шушы тауга, агачларга, чишмәгә табынган. Аллалары дип Тәңрене таныганнар. Аның хөрмәтенә төрле йолалар, корбан чалулар башкарылган.

Хуҗалар тавындагы агачлар төрле төстәге тасмалар белән чуарланган – бәхеткә юрап бәйлиләр икән аларны. Тауның түбәсенә күтәреләбез. Дүрт кырлы гөмбәз астында өч таш тора.

– Бу урынга бәйле бик күп риваятьләр яши, алар барысы да теге яки бу дәрәҗәдә әлеге якның борынгы тарихын чагылдыра. Минем үземә монголлар яулап алган шәһәрдән качып киткән унике кыз хакындагысы ошый. Кызлар монда, тау түбәсендә, кирмән төзеп, баскынчыларга каршы батырларча көрәшә. Ләкин дошман аларны кулга төшерә һәм тереләй җиргә күммәкче була. Кирмән сакчылары күккә инәлә. Аларның инәлүен күкләр кабул итә – кызлар, якты йолдызларга әверелеп, күккә аша. Тау түбәсендәге бу һәйкәл, өч таш, миңа менә-менә очып китәргә торган кошны – ышанычы, кыюлык һәм өмет билгесен хәтерләтә, – дип тәгәлли сүзен озатып йөрүчебез.


Олы Тигәнәле туган якны өйрәнү музеенда танылган археолог Альфред Халиков һәм аның командасы тарафыннан Олы Тигәнәле каберлеген казыганда табылган артефактларның күчермәләре саклана. Алар VIII–IX гасырларда әлеге территориядә бераз вакыт хәзерге венгрларның борынгы бабалары – Magna Hungaria (Бөек Венгрия) вәкилләре яшәгәнлеген дәлилли.

Чулман аша салынган күпердә без тагын ике елга исеме язылган күрсәткечкә юлыгабыз – Көрнәле һәм Архаровка. Район башлыгы Владимир Козонков әйтүенчә, су күтәрелгәннән соң, бу ике елганы Чулман «йоткан». XVIII гасыр башында Архаровка аша салынган күпер астында сәүдәгәрләрне талап көн күрүче юлбасарлар оялаган булган, имеш. Сәүдәгәрләрне төнлә моннан йөрмәскә дип кисәткән кара багана да торган, ди. Чая кешеләргә карата кулланылган «архаровцы» дип әйтү, мөгаен, шуннан киләдер.

PRESSA.RU



А

# РАЙОННЫҢ АЛТЫН ФОНДЫ – КЕШЕЛӘР

Авылның икътисадый тотрыклылыгын тәшкил итә торган нигез – ул милләтара татулык һәм эш урыннары, дип саный Алексеевск муниципаль районы башлыгы Владимир Козонков. Үз җирендә нефть һәм газ булмаса да, район предприятиеләрне, тотрыклы хезмәт хакларын, димәк, кешеләрнең иртәгәсе көнгә ышанычын да саклап тора. Биредә ел саен 14 мең квадрат метр торак кулланугa тапшырыла, менә ун ел дәвамында инде халык саны кимүдән туктады, диләр.

**– Владимир Константинович, ни өчен сез милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне өстенлекле дип саныйсыз?**

– Районда руслар, татарлар, ә алар белән тыгыз күршелектә чувашлар, мордвалар яши. Мөселман һәм православие динендәгеләр белән янәшә мәҗүси чувашлар да бар. Күршеләрнең йолаларын һәм традицияләрен белү, уртак бәйрәмнәрне уздырып бару кешеләргә бу җирдә дус яшәргә һәм эшләргә ярдәм итә. Милли традицияләрне саклауда һәм арттыруда районның биш җирлегендә булдырылган милли-мәдәни үзәкләр һәм районның Иҗтимагый советы зур роль уйный. Бөтенроссия фестиваленә әйләнгән «Алексеевские перезвоны»дан тыш, без «Петров день», Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрәбез, керәшеннәрнең Питрауы белән чувашларның Уявларын да бәйрәм итәбез. Алексеевск җирендә тагын бер яңа бәйрәм – Билярдагы «Изге чишмә» янында уздырыла һәм төрле дин вәкилләрен берләштерә торган «Чишмәле җәннәт» традициягә әйләнеп китте. Бу район бәйрәме, әмма без, Зөя һәм Болгардан соң, «Яңарыш» фонды өченче объект итеп Билярне сайлар һәм әлеге бәйрәм республика дәрәҗәсенә күтәрелер, дип ышанабыз.

**– Бәйрәмнәр үткәрү – бик күркәм гадәт, әмма район бюджетына ышанычлы донорлар да кирәк бит әле...**

– Районда 26 мең кешегә 104 мең гектар сөрүлек җире, 28 мең баш мөгезле эре терлек һәм ике мең баш дуңгыз туры килә, шулай булгач, кешеләр эшсез утырмый. Авыл хуҗалыгына эре инвесторлар кирәк. Шуларның берсе район чәчүлек җирләренең өчтән берен – 39 мең гектар җирне эшкәртүче «Кызыл Шәрык-Агро». 18 марттан элеккеге «Вамин» агрофирмасы территориясенә яңа инвестор – Мари Эл Республикасыннан «Звениговское» халык предприятиесе килде. Анда 20 мең гектар чәчүлек җире һәм 6,5 мең баш МЭТ исәпләнә. Быел өч мең башка исәпләнгән сөт комплексы һәм ике мең башка дип каралган симертү мәйданчыгы төзергә программа бар. Районның иң эре һәм уңышлы хуҗалыклары исәбенә тагын ике колхоз – «Ватан» һәм «Алга» да керә.

**– Авыл хуҗалыгы җитештерүеннән тыш, бюджетны тагын нәрсә тулыландыра?**

–Төзелеш секторы үсеш алды. Әйтик, меңгә якын кеше эшли, республиканың алты районына хезмәт күрсәтә һәм бюджет керемнәренең 25%ка якынын тәэмин итә торган «Алексеевскдорстрой». Подряд буенча эшләрне Алексеевскиның хуҗалыкара төзелеш оешмасы (МСО) башкара. Без Татмелиорациянең «РАФ» бүлекчәсен саклап калдык. «Алексеевская керамика» кирпеч заводы эшли. Коммуналь хуҗалык, «Водоканал» хезмәтләре тулысынча сакланып калды. Төзелеш буенча республика программаларын бары тик үз көчебез белән генә тормышка ашырабыз. 2015 елда республикада иң яхшы дип табылган кулланучылар кооперациясе дә бездә эшли. Ул, җитештерүдән тыш, халыкка хезмәт тә күрсәтә: 43 авыл кибете сакланып калды. Менә 20 ел инде барлык җитештерү участоклары гамәлдә, аларның авыр 90нчы елларда да тотрыклы эшләвендә район белән 24 ел җитәкчелек иткән Алексей Демидовның роле бик зур.

**– Шулай да бер предприятие – сөт-консерв комбинатының эше туктап калган бит.**

– 1934 елда эшләтеп җибәрелгән әлеге тәүлегенә 360 тонна сөт эшкәрткән завод СССРда егәрлеге буенча өченче була, һәм ул бөтен Союзга эшли: коры сөт, коры сөт өсте һәм башка продуктларны армия, Төньяк өчен җитештерәләр, продукция хәтта Кубага да җибәрелә. Бүгенге көндә районның аны сөт белән тәэмин итәрлек егәре юк. Республикада сөт тиешле күләмдә бар, әмма аны Татарстаннан читкә чыгарып эшкәртүне тыю безнең көчтән килә торган эш түгел. Гәрчә өстәмә кыйммәтне, күрше регионнардагы чит ил компанияләре вәкилләкләренә биргәнче, республиканың үзендә калдыру купкә яхшырак булса да.

**– Район икътисадында кече һәм уртача эшкуарлыкның инде 30 процентны тәшкил итүе дөресме?**

– Әйе, һәм бу өлеш үсештә. Районда 545 кече эшкуарлык субъекты исәпләнә, аларга эш урыннарының өчтән бере туры килә. Терлекчелек һәм үсемлекчелекнең төрле юнәлешләрендә 120 фермер эшли. Сәүдә һәм көнкүреш хезмәте зур үсеш алды. «Карусель» базары, «Пятёрочка+» сәүдә комплексы, кафе һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү буенча 33 шәхси предприятие эшли. 187 сәүдә предприятиесе арасында «Эдем» ҖЧҖ иң эреләрнең берсе булып кала бирә. 2015 ел өчен район буенча кече һәм урта предприятиеләрнең сәүдә әйләнеше 3,9 миллиард сум тәшкил итте.

# 300 ЯШЬТӘ ТОРМЫШ БАШЛАНА ГЫНА

2008 елда үзенең 300 еллык юбилеен билгеләп үткәч, Алексеевск бистәсенең икенче сулышы ачылган кебек булды. Ул, яңа социаль объектлар белән үсә-үсә, күз алдында үзгәрә һәм матурая бара.

– ТР Президенты ярдәме белән Балалар сәнгать мәктәбен төзү бистә өчен әһәмиятле вакыйга булды, аның бинасында ЗАГС та урнашты, – дип сөйли Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Александр Харитонов. – ЗАГС турында күптәннән хыялллана идек инде, чөнки соңгы 15–20 ел дәвамында яшь парлар язылышыр өчен Чистай шәһәренә бардылар.

31 яшьлек яшь мэрның тормыш тәҗрибәсен Кама инженер-икътисад академиясеннән соң, инде дүрт елга якын район башкарма комитетында инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы вазыйфасын башкару тулыландырып тора. Демографик үсеш факторлары турында ул үзенә җиткерелгән саннарга нигезләнеп фикер йөртә. Бистә халкының саны 11,7 мең кешене тәшкил итә һәм 16 ел инде тотрыклы дәрәҗәдә тора, соңгы ике елда әле табигый үсеш тә күзәтелә. Бу, билгеле, социаль тирәлекнең сыйфаты яхшыруга да бәйле.

Өч ел дәвамында сәламәтлек саклау объектларына капиталь ремонт ясау республика программасы кысаларында Үзәк район хастаханәсенә этаплап реконструкция ясау бара. Эчке биналарга ремонт һәм җиһазлар сатып алуны ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы башкара. Мәшгульлек мәсьәләсе дә уңышлы хәл ителгән. Предприятиеләр эшли, продукция чыгаралар. Тотрыклы хезмәт хакы һәм кредит алу мөмкинлекләре торак базарында шактый җанлануга китерде. Ел саен бистәдә 60лап шәхси йорт төзелә, төзелеш өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре калмады диярлек. Яңа кишәрлекләр хәзер бары тик күп фатирлы йортлар өчен генә бүлеп бирелә.

Бюджетка даими рәвештә төзекләндерү һәм яшелләндерүгә, юллар һәм тротуарлар, урамнарны яктырту, күперләр, зиратлар, полигоннар һәм гиротехник корылмаларны карап тотуга акча салына. Парклар һәм скверлар республика программасы буенча искиткеч матур Юлчылар паркы салынды. Ул дәүләт һәм шәхси партнерлыкның ачык үрнәге булып тора: «Алексеевскдорстрой» проектка – 18 миллион, ә республика бюджеты дүрт миллион акча кертте.

Салым кертемнәренең 60 процентын тәэмин итүче «Алексеевскдорстрой» ААҖ бистә өчен шәһәр тотучы булып тора. Шактый өлешне «Алексеевск керамикасы» ААҖ (әлеге предприятие кирпече, мәсәлән, Казан шәһәрендәге Универсиада авылы төзелешендә кулланылды) һәм ТР Президенты каршындагы Торак фонды дәүләт программалары буенча күпфатирлы йортлар төзелешен алып бара торган «Керамика-Маркет» ҖЧҖ кертәләр. 2014 елга кадәр мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урын җитмәү проблема булып торса, 220 урынлык яңа балалар бакчасы ачылу белән ул күп елларга чишелде – бүген 34 буш урын да бар әле.

Алексеевскида алты балалар бакчасы, өч гомуми белем бирү мәктәбе һәм бер башлангыч мәктәп, Аграр көллияттә 400ләп укучы һөнәри урта махсус белем ала. Кызганычка каршы, «Забота» приюты да буш тормый, бирегә балигъ булмаган балалар эшләре буенча комиссия карары белән социаль яктан имин булмаган гаиләләрдән балигъ булмаган яшүсмерләр җибәрелә. Анда Алексеевск һәм күрше өч районнан даими рәвештә 30лап бала яши.

Алексеевскилыларның сәламәт ялы өчен бик яхшы чаңгы базасы, спорт комплексы һәм күптән түгел генә ремонттан соң ачылган бассейн бар. Узган ел Габдеҗәлил Сөләймановның җиңүләренә бәйле рәвештә һәм ТР Президенты булышлыгы белән Көрәш залы ачылды. Габдеҗәлил 2013 елгы Универсиадада – көмеш, ә узган елны билбау көрәше буенча дөнья чемпионатының алтын медален яулады.

Җирле хакимиятләр бәләкәчләр турында да онытмый. Республика программасы буенча балалар мәйданчыклары төзелә. 2014 елда бистә халык-социаль проектлары бәйгесендә җиңүе өчен ТР Хөкүмәтеннән миллион сум күләмендә грант алды. Әлеге чараларга күп фатирлы йортлар ишегалларында биш яшькәчә балалар өчен җиде зур булмаган уен комплекслары төзелде.

Алексеевск олы тарихка ия. 2008 елда ачылган Туган як музееның бик бай экспозициясе бар һәм ул туристлык маршрутына кертелгән. Өч ел элек «әфганлылар» инициативасы белән ачылган Сугышчан дан музее икенче бөтендөнья сугышы вакыйгалары һәм анда катнашучылар һәм 80–90нчы еллардагы сугыш хәрәкәтләре турында сөйли. Быел бистә Алексеевск җирендә Мәрьям Ананың Ахтыр иконасын табуның 200 еллыгын билгеләп үтә һәм «Алексеевские перезвоны» дип аталган XIV Бөтенроссия чиркәү чаңы фестивален үткәрә.

Реклама

РАЙОННАР БУЙЛАП! / МАХСУС ПРОЕКТ

PRESSA.RU



# ЮЛ ЭШЕНЕҢ ОСТАЛАРЫ

**Икътисад ягыннан бер-берсеннән ерак урнашкан торак пунктлардагы авыл хуҗалыгы предприятиеләре зур роль уйный торган төбәкләр үсеше, шул исәптән әлеге торак пунктларын бәйли торган юл инфраструктурасына да бәйле.**

Авылга «зур» дөнья белән хәбәрләшергә мөмкинлек бирү – Татарстандагы иң эре юл төзү предприятиеләренең берсе булган «Алексеевскдорстрой» ААҖнең үз алдына куйган бурычлары арасында иң мөһимнәреннән санала торганы.

Предприятиенең төзелү тарихы Алексеевск тарихы, аның район үзәге статусын алуы, федераль трасса булган Оренбург трактындагы эре торак пункты буларак үсешкә ирешүе белән тыгыз бәйләнгән.

Оешманың динамик рәвештә үсеше XX гасырның 90нчы елларында, Алексеевскиның Юл ремонтлау-төзү идарәсен «Алексеевскдорстрой» ААҖнең хәзерге генераль директоры Фоат Вәли улы Вәлиев җитәкләгәч башланды. Бернечә ел эчендә предприятие хезмәткәрләренең саны шактый артты, юл төзү эшләрен алып баруның алдынгы ысуллары үзләштерелде.

Бүген «Алексеевскдорстрой» ААҖ Татарстан юл тармагында алдынгы урыннарның берсен алып тора. Үзен төрле дәрәҗә авырлыктагы зур күләмле эшләрне вакытында һәм һөнәри яктан уңышлы башкара торган җаваплы подрядчы сыйфатында тәкъдим итеп, «Алексеевскдорстрой» региональ һәм федераль билгеләнештәге юл өлешләрен төзү, реконструкцияләү һәм хезмәт күрсәтү проектларын тормышка ашыра торган иң сораугa ия компанияләрнең берсе булып җитеште.

Бүген оешма республиканың алты районы буйлап җәелгән 1675 км региональ һәм федераль юлларга ел әйләнәсендә хезмәт күрсәтүне тәэмин итә.

«Алексеевскдорстрой» ААҖ тарафыннан башкарыла торган эш нәтиҗәлелеге күп очракта компания хезмәткәрләре даими рәвештә үзләштерә һәм үз эшендә куллана торган юл төзелеше һәм хезмәт күрсәтүнең заманча ысулларына нигезләнгән. Салкын регенерацияләү ысулы, үзләре җитештергән полимер-битум бәйләү материалын куллану, җирле грунтларны органик һәм органик булмаган бәйләү матдәләр белән ныгыту – бу оешма тарафыннан башкарыла торган эшне җитештерүдә киң кулланыш алган алдынгы ысуллар һәм технологияләренең кайберләре генә әле.

– Әмма технологияләр – уңышлы эшне тәшкил итә торган бер өлеш кенә, ә иң мөһим рольне предприятиенең квалификацияле (махсус белемле) кадрлары уйный. Бүген биредә 1500 хезмәткәр эшли. Оешмада буыннан-буынга күчү үсеш алган, һөнәри династияләр традициясе бар. Кадрларның мондый тотрыклылыгы һәм бердәмлеге күп очракта компания җитәкчелеге тарафыннан үз хезмәткәрләренең эш һәм тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуга, һөнәри яктан даими үсешкә юнәлдерелгән көче хисабына бәйле.

Еллык кереме 3 млрд сумнан артык булган «Алексеевскдорстрой» ААҖ Алексеевск, Әлки һәм Спас районнарының бюджет тәшкил итә торган предприятиесе булып тора. Бүгенге көн чынбарлыгы эш географиясен киңәйтү кирәклеген таләп итә, һәм инде менә берничә ел дәвамында предприятие Түбән Кама, Баулы, Мамадыш, Чистай һәм республиканың башка районнары юлларын төзи һәм ремонтлый.

«Без эштән курыкмыйбыз, эш бар, эш гөрли».

**Хөрмәтле Владимир Константинович! Сезне чын күңелдән бик матур бәйрәм – 60 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Сез Алексеевск районын 12 елдан артык җитәклисез, һәм әлеге вакыт эчендә эшегез туган якны үстерүгә юнәлдерелгән иде. Сез – энергиясе һәм планнары белән туган яктагы тормышны яхшырак итәргә омтыла торган җитәкченең ачык мисалы. Чын күңелдән Сезгә алдыгызда торган җаваплы бурычларны чишүдә уңышлар, сәламәтлек һәм иминлек телим!**

Реклама

# ТУГАН ТУФРАК АҺӘҢЕ

**Туган авылына булган мәхәббәтен Зиннур Бәширов бервакыт шигырь юлларына сала, юкса, аңа кадәр дә, аннан соң да бер шигырь дә язмый ул. Ә бу шигырьгә күренекле композитор көй иҗат итә, шулай итеп, «Көрнәле» дигән җыр туа. Җырга видеоклип та төшерелгәч, Бәширов танылып китә.**

Зиннур Бәширов күптән инде Казанда яши, шулай да туган авылы Коры Көрнәлегә бик еш кайтып йөри. Монда аның кече ватаны, әти-әнисенең каберләре. Биредә Зиннур кайчандыр «исән калу мәктәбен» узган.

– Миңа – дүрт баланың иң өлкәненә – унбер яшь булганда, әтиебез үлде, – дип искә төшерә Зиннур Закирович. – Бу Хрущев вакытлары иде. Шул чакта кинәт кенә, хезмәт хакы алып эшләгәнлектән, совхоз эшчеләре азык-төлекне кибеттән сатып алырга тиеш, дип карар кылдылар. Бөтен кешене сыерларын совхозга сатарга мәҗбүр иттеләр. Бер ел-ел ярымнан күрше-тирәләребез яңадан терлек асрый башлады, ә без булдыра алмадык. Авыру әниебезнең пенсиясе бик кечкенә, гаиләне өебездә булган сепаратор гына коткара иде. Алар бөтен авылга икәү генә, ә механизм прокаты өчен аертылган сөтнең һәр чиләгеннән хуҗаларга бер литр сөт белән түлиләр иде. Менә шулай исән калдык.

Левашово авылындагы совхоз идарәсенә 13 яшьлек Зиннур җиде чакрым җәяү килә. Әмма аның гаиләләренә ярдәм соравына каршы директорның җавабы сүгенүгә якын була. Малай чагының күз яшьләрен Зиннур һаман да кичерә алмый аңа. Ә инде ул җитәкче, чыгарылыш классы укучылары янына килеп, авыл хуҗалыгы техникумында укырга һәм белгеч булып совхозга кайтырга лаеклылар исемлеген укыганда, үз фамилиясен ишеткән Бәширов, авыр минутта ярдәм күрсәтмәгәч, миңа сезнең техникумыгыз да, совхозыгыз да кирәкми, дип белдерә...

Казанга китеп, ЭВМ заводында токарь булып эшли башлый һәм кичке мәктәпне тәмамлап чыга. Авылдагы өй инде тузган, һәм 19 яшьлек Зиннур гаиләсен үз янына – су үткәрелмәгән, мичкә утын белән ягышлы һәм бәдрәфе урамда булган йортның унбер метрлы бүлмәсенә алып килә. Эшләп, барысын да тәэмин итә. Сеңелесе һәм энеләре укып белем ала, өйдән китеп, үз гаиләләрен төзи. Зиннур Закирович та өйләнә. Үзешчән театр сәхнәсендә күреп танышкан Нәҗиясе гаилә җылысын булдыра һәм саклый ала. Яшьлегендә күпләр фаразлаганча, халык артисткасы була алмый ул, әмма Бәшировлар өч бала тәрбияләп үстерә, ә хәзер биш оныкларына сөенеп яшиләр.

Ярты гасыр дәвамында Зиннур Закирович озын юл үтә. КИСИны тәмамлап, «Казанхимстрой» трестында, «Татплодоовощхоз» берләшмәсендә эшли, Халык мәгариф министрлыгының төзелеш, ремонт һәм МТС идарәсенә җитәкчелек итә. «Терминал»да генераль директор урынбасары була. 1995–2004 елларда Казан шәһәре хакимиятендә кешеләрне тузган торактан күчерү программасы өчен җавап бирә. Биш ел Авиатөзелеш районы башлыгының беренче урынбасары була. Хәзер Бәширов пенсиядә, ләкин аның белем-тәҗрибәсенә әле дә ихтыяҗ бар – ул төзелеш мәсьәләре буенча коммерцияле структурага ярдәм итеп тора. Аның күпьеллык хезмәте «ТР торак-коммуналь хуҗалыгының атказанган хезмәткәре» исеме, «Фидакарь хезмәт өчен» медале, мактау грамоталары белән бәяләнгән.

Туган авылы Коры Көрнәледә, кайчандыр атасының салам түбәле өе торган калкулыкта, күптән түгел яңа йорт салып куйдылар. Кайчакларда анда бөтен гаилә бергә җыела.

– Энем апрельдән ноябрьгә кадәр гаиләсе белән шунда яши, – ди Зиннур Закирович, – ә без кунакка гына кайтабыз. Йорт булмаганда, күңел урынында түгел иде. Әти-әнинең каберләренә кайткач, әрем баскан туган нигезебезгә киләм дә, үзеннән-үзе күзгә яшь тула иде. Һәм мин үз-үземә йорт төзеп чыгарга вәгъдә иттем. Шуңа ирешүем белән бәхетле мин хәзер.

Борчулары һәм авылына мәхәббәте шигырь юлларына күчкән. Бер утыруда язып куйган аны Зиннур. Соңрак аны композитор Илфат Дәүләтшин музыкага салган. «Көрнәле» җырын беренче булып Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәләхов башкарган. Ә инде узган ел видеоклип төшерелеп, берничә тапкыр телевидениедән дә күрсәтелгәч, Бәширов туган авылында гына түгел, районда да танылган кешегә әверелә.

**Хөрмәтле Владимир Константинович! Сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлыйм! Сезгә сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс энергия, җаваплы һәм җиңел булмаган эшегездә уңышлар телим! Сезнең Алексеевск районы авылларын саклап калырга омтылышыгыз тирән ихтирам уята. Чөнки аларның һәркайсы – кемнәрнеңдер кече ватаны, яшәү көче белән туендыручы тамырлары бит.**

PRESSA.RU



# КЕЧЕ ВАТАН: КҮҢЕЛ ТУКТАЛЫШЫ

А

**70нче елларда мин әти-әнием йорты янына хәтта УАЗ белән дә уза алмый идем. Ләм эчендәге Бутлеров урамын кичеп үтәрлек түгел чөнки. Бүген исә плитка түшәлгән тротуарлар бистәне танымаслык итеп үзгәртеп, биредә гыйбадәтханә, парк, кибетләр һәм кафелар үсеп чыкты. Балачагым үткән йорт һәм элеккеге иптәшләрем генә күпер булып үткәннәрне бүгенгегә бәйләп тора.**



### АТА-АНА ЙОРТЫ – ЮЛ БАШЫ

Әти-әнием – төп Алексеевск кешеләре. Әтием Пётр Владимирович 1918 елда Ромодан авылында күп балалы ярлы гаиләдә туган. Коллективлаштыруда катнашкан, Ерак Көнчыгышта хезмәт итеп кайткан. Ветеринария техникумын тәмамлагач, гомеренең ахырына кадәр Алексеевск районы оешмаларында ветеринария табибы булып эшләгән. Әнием Мария Сергеевна (Марфина) 1921 елда Лебяжье авылында, шулай ук күп балалы гаиләдә туган. Чистайдагы фельдшер-акушерлык мәктәбен тәмамлап, авыл медпунктларында, аннары 30 елдан артык Алексеевск район хастаханәсендә эшләгән.

1941 елда алар туй ясарга җыена, тик сугышның беренче айларында ук икесе дә хәрәкәттәге армиягә чакырыла. Әни госпитальләрдә хезмәт итә. Әти Ленинград өчен барган сугышларда әсирлеккә эләгә һәм, 1944 елда азат ителгәннән соң, НКВД лагерьларында фильтрация үтә, аңа 1946 елда гына туган ягына әйләнеп кайту насыйп була. Нәкъ шул елда алар өйләнешәләр дә. Бер елдан – апам Галина, ә 1950 елның августында мин туам.

Без иске Кама яры буендагы Зеленовка урамында күпер янында яши идек, аның калдыклары әлегәчә елгадан күренеп тора. Су басар алдыннан әти-әниебез Муса Җәлил урамына күченә, апам белән минем балачак үткән йорт бүген дә исән әле.

1957 елда мәктәпкә укырга кердем. Укытучыларым белемгә кызыксыну уята алдылар. Миңа математика, физика фәннәре аеруча җиңел бирелде, бик теләп төрле түгәрәкләрдә шөгыльләндем. Бу миңа мәктәптән соң КАИның очу аппаратлары двигательләре факультетына керү имтиханнарын уңышлы тапшырырга ярдәм итте.

Ул елларда КАИның комсомол оешмасында берничә мең егет һәм кыз исәпләнә һәм райком хокукына ия иде. Мин шактый вакыт сугышчан комсомол дружинасы (БКД) әгъзасы булып тордым, Казанның Бауман районы БКДсы җитәкчесе урынбасары булдым. Беренче курста укыганда ук иң матур курсташым Галинага игътибар иткән идем. 1971 елда без өйләнештек, ә 1972 елда кызыбыз Оксана туды. Эшкә КПБМга (моторлар төзү бюросы) билгеләндек. Аннары комсомол путёвкасы белән мине КамАЗга җибәрделәр, анда ВЛКСМ ҮКның СССРның 50 еллыгы исемендәге Бөтенсоюз төзелеш отряды командиры булдым. Яр Чаллыда икенче кызыбыз – Елена туды.

1974 елда, дәүләт куркынычсызлыгының оператив хезмәткәре вазыйфасына күчеп, тормыш юлымны кискен үзгәрттем һәм 14 ел эчендә, оперуполномоченныйдан башлап, КГБның Яр Чаллы бүлеге башлыгы урынбасарына кадәр күтәрелдем. Аннары – Казанда бүлек башлыгы, соңрак – ТАССР КГБ башлыгы урынбасары вазыйфасы. Болар – үзгәртеп кору һәм СССР таркалу еллары иде.

1998 елдан «Итера» нефть-газ компаниясендә эшләдем. Хәзер Мәскәүдә яшим, балаларым һәм дүрт оныгым да шунда. Әти-әниләребез фани дөньяда юк инде, әмма Алесеевскидагы 60 елдан артык торган йортыбызны мин саклап калырга булдым: ремонтладым, янәшәсендә тагын бер йорт салдым. Алексеевскида без бик еш тулы гаиләбез белән рәхәтләнеп җыелышабыз. Моның сәбәпләре күп.

**ИСКЕ ЯКЛАРГА – ЯҢА КАРАШ**

Егерме еллап элек бистәдә асфальт та, газ да юк иде. Әни кышларын, карны көрәгәнче, өйдән дә чыга алмый иде. Хәзер урамнарны техника җыештыра, бөтен бистәдә – асфальт, йортларга газ кергән. Кама ярлары буенда Алексеевскиның 300 еллыгына салынган ике фатирлы торак йортлар, балалар бакчалары һәм мәктәпләре булган яңа микрорайоннар үсеп чыккан. Сугышта катнашучылар һәм аларның тол хатыннары ванналары-туалетлары булган, салкын һәм кайнар сулар кертелгән тораклар белән тәэмин ителгән.

Алексеевскидагы бөтен нәрсә аның чын хуҗасы барлыгы турында сөйләп тора. Цифрлы элемтә һәм интернет Мәскәү тирәсендәгедән ким эшләми. Күптән түгел ремонт ясалган бассейн инде 15 ел хезмәт күрсәтә. 3,5 һәм 10 кмлы яктыртылган һәм җиһазландырылган трассалы чаңгы базасы бар, биредә районара дәрәҗәдәге ярышлар үтә, чөнки күрше-тирәдә андый трассалар юк.

Монда районның элекке башлыгы Алексей Иванович Демидовның да, 2004 елдан районга җитәкчелек итүне үз кулына алган хезмәттәше Владимир Константинович Козонковның да, социаль программаларны финанслаучы республика җитәкчелегенең дә кертикән өлеше зур.

Һәр кайтуымда мин иң беренче әти-әниемнең каберләрен зиярәт кылам, аннары чиркәүгә керәм, аның настоятеле Павел атакай (Чурашов) белән мин күптәннән таныш. Павел Михайлович белем дәрәҗәсен даими күтәреп торучы кызыклы һәм тирән фикерле шәхес, ул фәлсәфә корырга да, инандырырга да һәм, гомумән, тормыш турында сөйләшеп утырырга да сәләтле кеше. Әлеге үрнәк пастырь, күп балалы әтинең гаҗәпләндерә торган мавыгулары да бар: ул гаджетлар ярата, ноутбугыннан аерылмый, әледән-әле парашют белән сикерә. Аның Әфганстанда хезмәт иткән чагыннан калган хәрби формасы Владимир Козонков ярдәме белән ачылган җирле Сугышчан дан музеенда саклана. Павел атакай һәм Владимир Константинович инициативасы белән Алексеевскида инде 15 ел дәвамында чаң кыңгыравы фестивале үтә, анда Россиянең ерак төбәкләреннән дә бик теләп киләләр һәм катнашалар.

Бер үк вакытта сәнгать мәктәбен дә, музейны да үз эченә сыйдырган Никахлашу сараен төзегән өчен үз вакытында район башлыгын шелтәләгәннәр дә: янәсе, статус буенча андый Сарай каралмаган. Әмма аны бистәнең юбилеена бюджеттан тыш акчаларга төзегәннәр. Хәрби дан музеена мин даими рәвештә элеккеге хезмәттәшләремне чакырам. Яңа ел каникулларына элеккеге һәм хәзерге КГБ-ФСБ хезмәткәрләре килгән иде. Очрашуда Владимир Козонков һәм Алексей Демидов та катнашты. Музей активистлары, Әфганны һәм Чечняны үткән егетләр балаларга хәрби-патриотик тәрбия бирү белән шөгыльләнә, мәшгульлек һәм бюджет турындагы көндәлек мәшәкатьләр арасында, район башлыгы да аларның эшен игътибарсыз калдырмый. Ул «Альфа»ның элеккеге командиры, генерал Геннадий Зайцевка да (аның әтисе Кызылъярда туган) кардәшләрен эзләргә булышты.

Минем дустым Владимир Константинович Козонков үзенә тапшырылган районны ярата, аның белән горурлана. 2015 елда, безнең чыгарылышның 50 еллыгына, элекке Союзның бөтен почмакларыннан күптән түгел үзе дә 100 еллыгын билгеләп үткән Алексеевск урта мәктәбен тәмамлаучылар җыелды. Минем дусларым да бар иде: гомерен Алексеевскига багышлаган һәм аның чәчәк атуы өчен бөтен көчен куйган Виктор Янонис, беренче класстан бирле минем дустым булган Петр Луцук, су асты көймәсе командиры, 2нче ранг капитаны Николай Антонов, КФУ профессоры Владимир Рукавишников, күренекле табиб Михаил Малиновский һ.б. Иртә белән район башлыгы үзе кунаклар өчен туган якны өйрәнү музее һәм Сугышчан дан музее буйлап экскурсия үткәрде. Аннары, рульгә утырып, район буйлап әйләндерде, аның истәлекле урыннары, икътисады һәм авыл хуҗалыгы, өр-яңа технологияләр турында сөйләде. Автоматлаштырылган сөтчелек фермасына алып керде. Эстониядән кайткан сәүдә флоты морягы соңыннан миңа: «Кайткач, эстоннарга Европаның чынлыкта кайда икәнлеген сөйләячәкмен», – дип белдерде.

**Форсаттан файдаланып, Владимир Константиновичны юбилее белән котлыйм һәм аңа ныклы сәламәтлек телим. Бу аңа безнең уртак кече ватаныбыз – Алексеевск районын үстерүгә киләчәктә дә уңышлы хезмәт итү өчен бик тә кирәк!**

# КАМА БУЕ СЕРВИС ҖӘННӘТЕ

**Алексеевск районының елына ярты миллиард сумга якын әйләнешле иң эре сәүдә оешмаларыннан берсе – «Эдем» ҖЧҖ үзенең эшен 2002 елның февраленнән Алексеевск – Биләр һәм Алексеевск – Базарлы Матак юл чатындагы ике кафе һәм Лебедино авылындагы бер кибеттән башлап җибәрә. Юл буе сервисының барлык нокталары кечкенә вагоннарда урнашкан була.**

Кама аша күпер ачылгач, транспорт агымы арта гына бара, ә 2004 елда компания белән җитәкчелекне үз кулына алган Гөлнур Сафина моңа кадәр кулланучылык кооперациясендә эшләү тәҗрибәсен йөз проценты белән эшкә җигә. Эшлеклелек сыйфатлары һәм кешеләр белән мөнәсәбәтләр төзи белүе нәтиҗәсендә Гөлнур Таһировна «Эдем»ны башта – райондагы, аннары Кама буендагы әйдәп баручы оешмалар сафына чыгарып, нокталарны сервис җәннәте оазисларына әверелдерә.

«Эдем» ҖЧҖ, Мәскәү–Уфа, Казан–Оренбург һәм Казан–Самара трассаларын да үз эченә кертеп, 14 кафе һәм 3 мотельне эшләтеп, Алексеевск, Балык Бистәсе һәм Спас районнарын юл буе сервисы белән тәэмин итә. Узган ел күпер буенда 3 катлы «Золотой карп» комплексы һәм Кама ярында «Ял» кафесы төзелә. 10 кибет, кием тегү һәм төзәтү ательесы, чәчтарашханә эшли.

Иң мөһиме – оешма җирле җитештерү продуктлары белән сәүдә итә. Аларның 40 процентын заманча саклагычлары, суыту җиһазлары, балык, ит, сөт, яшелчә эшкәртү линияләре булган үз базасында эшкәртә. Чиста экологияле авыл хуҗалыгы продукциясен җирле җитештерүчеләрдән сатып алу һәм шул ук вакытта Алексеевск, Әлки, Спас районы мәктәпләрен, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрен, картлар йортларын һәм балалар приютларын тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы көйләнгән. 2015 елда әзерләү әйләнеше генә дә – 41,5 миллион сумны, ә бюджет оешмаларын азык-төлек белән тәэмин итү күләме 54,7 миллион сумны тәшкил иткән.

Алексеевск үзәгендә кафесы, банкет заллары, бильярд залы һәм балалар бүлмәсе булган «Оазис» Сәүдә комплексы ачылган. Шушында ук пекарня, кулинария-кондитер цехы, өй ризыклары кибете урнашкан. Анысында камыр ризыклары, голубцы, салатлар, пилмән, кәтлит, фарш, җирле «Ватан» колхозы сөтеннән ясалган исткиткеч тәмле эремчек һ.б.лар тәкъдим ителә.

Ай саен 8әр тонна сөт, 9 тоннадан артык камыр ризыгы һәм макарон, 400 кило пилмән, 80 тоннадан артык икмәк-күмәч продукты сатыла. Көн саен иртән икмәк ташучы биш машина, кайнар икмәк һәм камыр ризыклары төяп, Алексеевскидагы һәм районның башка авылларындагы 92 кибетне, һәм шулай ук Әлки, Чистай, Лаеш, Нурлат һәм Аксубай районнарындагы 97 кибетне әйләнә.

– Балыкны һәм җиләк-җимешне без фуралар белән портлардан, турыдан-туры тәэминатчылардан алабыз, шуңа күрә алар бездә кибетнекеннән арзанрак, – ди Гөлнур Сафина. – Ә калганы – Татарстанныкы: ит, сөт, он, яшелчә. Аңлы рәвештә җирле җитештерүчеләргә ярдәм итәбез, заказлар бирәбез. Узган ел байтак коллегаларыбыз Белоруссия бәрәңгесен, Италия кишерен сатып алды, ә «Эдем» җирле яшелчәләргә өстенлек бирде. Бүген алар 15–20 процентка арзанрак сатыла, һәм бу безгә көндәшлек өстенлеген һәм сыйфат гарантиясен бирә. Без кешеләргә ничек үстерелүе билгесез чит ризык тәкъдим итмибез, ә экологик чиста ризык ашатабыз.

454 хезмәткәрнең күпчелеге – хатын-кызлар. Декрет елларын, балаларының авыруын һәм гаилә мәшәкатьләрен истә тотып, алар белән нәкъ менә хатын-кыз гына җитәкчелек итә ала да инде. Барлык эшчеләрен йөзгә таныган һәм исемнәрен белгән Гөлнур Сафина, алар белән уртак фикергә килеп һәм беркемне дә рәнҗетмичә, тиешле карарлар кабул итү сәләтенә ия.

«Эдем» табышының сизелерлек өлешен хәйрия эшенә: бакчаларны, мәктәпләрне ремонтлауга, бәйрәмнәр үткәрүгә, мәчетнең коммуналь хезмәтләре өчен түләүгә юнәлтә… Быел төрле максатларда 1,9 миллион сум акча кучерелгән.

– Мин әйләнә-тирәдәге кешеләрнең сәламәт һәм бәхетле булуларын телим. Әгәр кеше иртән эшләү теләге белән өеннән чыгып китсә, ә кич җиткәндә, физик һәм рухи яктан ял итәргә дип өенә ашыкса, димәк, тормыш гаҗәеп матур, – ди Гөлнур Таһировна. – Безнең хезмәтебез һәм экологик чиста продуктлардан яратып әзерләнгән өй ярымфабрикатлары-ризыкларыбыз кешеләргә якыннары белән ял итү өчен вакытларын янга калдырырга ярдәм итәдер, дип өметләнәм.

Реклама

# «ВАТАН» НӘРСӘДӘН БАШЛАНА?

**Республиканың уңышлы предприятиеләре арасында тарихы ярты гасырдан артык вакытны үз эченә алганнары күп түгел. Без «Ватан» колхозы җитәкчесе Ильяс Әхмәтовтан Алексеевск районының иң эре һәм иң өлкән авыл хуҗалыгы предприятиеләренең берсе ничек яшәгәнлеге турында сораштырырга булдык.**

**– Ильяс Мортазаевич, үзегез җитәкләгән колхоз турында бераз сөйләп китегез әле.**

– «Ватан» колхозына тиздән 70 яшь тула. Башка колхозлар таркалган яки шәхси инвесторлар кулына тапшырылган вакытларда безнеке миңа кадәр җитәкче булган Камил Сафинның тырышлыгы һәм оста идарәсе нәтиҗәсендә бу кыен чорны уздырып җибәрә алды. Сафин колхозны 1972 елдан алып 2003 елга кадәр җитәкләде. Ул елларда безнең предприятие рентабельле, нәтиҗәле булды, югары уңышларга иреште. Дәлилләр артыннан ерак барырга кирәкми: бер сыерга еллык савым 8 мең килограммнан артык сөтне тәшкил итә, шул ук вакытта эре агрохолдинглардагы нәтиҗәлелек – 5 мең килограмм сөт тирәсе. Бөртеклеләр буенча да без алдынгылар рәтендә: уртача уңдырышлылык – гектарыннан 35–40 центнер.

**– Хәзер колхозда ничә кеше эшли?**

– Ике йөзләп. Бу санның безнең яклар өчен нинди күрсәткеч икәнлеген күз алдыгызга китерер өчен аңлатыйм: эшчеләрнең күбесе Бутлеровка авыл җирлегенең биш торак пунктында яши, алардагы халыкның гомуми саны – 1030 кеше тирәсе. Җирлек өчен «Ватан» чынлыкта бюджет төзи торган предприятие булып тора. Юеш Көрнәледә, Бутлеровка, Балахчино авылларында, Шәһәрчектә, Ивановское поселогында тормыш нәкъ менә колхоз яшәгән аркасында гөрли, дип әйтергә була. Без тагын социаль функцияне дә башкарабыз. Юллар бар, социаль объектлар эшли. Сүз уңаеннан, Бутлеровка авыл җирлегенең милли составы бик төрле, биредә унлап милләт вәкиле яши. Һәм бик тату гомер итәләр алар. Эшләре дә әйбәт бара.

**– Мондый бердәм, нәтиҗәле эшне көйләүгә ничек ирештегез?**

– Бар нәрсәнең нигезендә, әлбәттә, капитал буларак кеше тора. «Ватан» кадрларга тиенде, колхозда югары квалификациягә ия белгечләр эшләде һәм эшли. Хуҗалыкның 12 хезмәткәренә ТР Авыл хуҗалыгының атказанган хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде, алар арасында 5 терлекче, 4 белгеч һәм 3 механизатор бар. Терлекчелек тармагы белән яшь белгечләр И.Шакиров, К.Трусов идарә итә. Финанс-икътисад блогына озак еллар дәвамында Татарстан Республикасының атказанган икътисадчылары А.Зарипова һәм В.Калинин җитәкчелек итә. Менә, мәсәлән, безнең яшь агрономыбыз – Ильмират Кадыйров. Бик принципиаль, җитди белгеч. Берничә бүләк иясе. Шул исәптән аның эше нәтиҗәсендә без «Татарстанның элиталы орлыклары» берләшмәсенә керәбез. Безнең продукциягә ихтыяҗ бар, без бөртеклеләрнең югары нәтиҗәле төрләрен үстерәбез, шәп уңыш алабыз. Боларның барысына да Ильмират Габделхәй улының әлеге процессларның технологиясен үтәүне бик җентекләп күзәтүе аркасында ирешелә. Ягъни белгечләр үз эшләрен җиренә җиткереп башкара икән, без югары керем алабыз һәм үз хезмәткәрләребезне эш белән дә, хезмәт хакы белән дә тәэмин итә алабыз. Хезмәт хакы Алексеевск предприятиеләре арасында иң югарысы да түгелдер, бәлки, әмма ул тотрыклы. Һәр кеше үзенең ни өчен тир түккәнен, димәк ки, хезмәтенең нәтиҗәсе барлыгын күреп тора. Ә җирдәге хезмәт – ул җиңел эшләрдән түгел.

**– «Ватан»да бәйрәмнәр буламы?**

– Әлбәттә. Җирлектәге бер бәйрәм дә, бер Сабантуй да безнең ярдәмнән башка узмый. Ул да зур хезмәт, безне үзара берләштерә һәм җилкендерә торган эш. Ветераннарыбызны, һичшиксез, Җиңү көне белән котлыйбыз. Сүз уңаеннан әйтим, бездә колхоздан өстәмә пенсия ала торган шефка алынган пенсионерлар күп. Башкача булуы да мөмкин түгел, алар бит бар гомерләрен колхозга багышлаган. Хәзер ул, үз чиратында, аларга әҗерен кайтара.

**– Фермер булырга карар кылган кешегә, үз тәҗрибә һәм белемегездән чыгып, нәрсәдән башларга киңәш бирер идегез?**

– Авыл хуҗалыгы – ул бик үзенчәлекле, четерекле өлкә. Андагы эш белән идарә итәргә өйрәнү бигрәк тә шәһәр кешесе өчен җиңел түгел. Ә андыйларга мин башта берникадәр ара «урынга» чыгып торырга, без яшәгән ритмны тоемларга тырышырга киңәш итәр идем.

**Хөрмәтле Владимир Константинович! Чын күңелдән Сезне түгәрәк дата – 60 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Озак еллар дәвамында мин Сезне җаваплы җитәкче, туган як язмышы өчен чын-чынлап җан атып йөргән принципиаль, намуслы кеше буларак беләм. Сез Алексеевск районын инде менә 12 елдан артык җитәклисез, бу вакыт эчендә халыкта Сезгә карата ышаныч һәм хөрмәт ныгыды гына. Чын күңелдән Сезгә ныклы сәламәтлек, иминлек һәм эшегезнең уңышлы баруын телим! Юбилеегыз белән!**

Реклама

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

МАХСУС ПРОЕКТ

— 11нче чыгарылыш —

# Татарстан юбилярлары

Фәрит Миңнегулов

# ХИМИЯ ҺӘМ ТОРМЫШ

**«Казан Оргсинтез» ГАҖ генераль директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Миңнегулов май аенда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.**

Юбилярның карьерасы производство нигезләреннән алып аның иң югары баскычына кадәр алгарышлы хәрәкәт үрнәге булып тора: 90нчы еллар уртасында ул – «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең Синтетик каучук заводында смена башлыгы, ә 2012 елда илебез химия сәнәгатенең иң эре һәм динамик төстә үсә баручы предприятиеләренең берсе – «Казан Оргсинтез» ГАҖнә генераль директор итеп билгеләнгән.

Фәрит Гертовичның хезмәт казанышлары «ТРның атказанган химигы» исеме, ТР Икътисад министрлыгының Почет грамотасы белән билгеләп үтелгән.

**Рушан Шәмгунов,**
«ТАИФ-НК» ААҖ генераль директоры

## Профессионализм чәчәк аткан чор!

Хөрмәтле Фәрит Гертович! «ТАИФ-НК» компаниясе коллективы һәм үз исемемнән сезне 50 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Бу – Сездәге профессионализмның чәчәк аткан һәм киләчәккә ышаныч белән карый алган чорыгыз!

Озак еллар буе белемегезне һәм осталыгыгызны илебез икътисадының иң мөһим юнәлешләренең берсе – химиягә һәм нефть химиясенә багышладыгыз. Югары профессиональлегегез, актив тормыш позициягез, оештыру осталыгыгыз нефть химиясе сәнәгате өлкәсендәге мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл итәргә мөмкинлек бирә. Россия Федерациясенең иң эре химия предприятиеләренең берсе – «Казан Оргсинтез» ГАҖ Сезнең җитәкчелек астында, барлык юнәлешләрдә дә лидерлыгын ныгыта барып, сыйфат ягыннан ышанычлы төстә яңа дәрәҗәгә күтәрелә. Куелган максатларга ирешү юлында эшкә сәләтегез, бары тик алга барырга омтылуыгыз предприятиегә тармакта алдынгы позицияләрне саклап калырга, дәүләт югарылыгындагы иң катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә ярдәм итә.

Хөрмәтле Фәрит Гертович! Бәйрәм көнегездә Сезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм гаилә иминлеге телибез. Җитәкче буларак алдан күрә белүчәнлегегез һәм гаҗәеп кешелеклелек сыйфатларыгыз алдагы барлык бурычларны үтәүдә тугрылыклы юлдашларыгыз булсын.

Юбилеегыз белән Сезне!



## Безне хезмәттәшлекнең күркәм традицияләре берләштерә

**Фәрхәд Самедов,**
«Уфаоргсинтез» ГАҖ генераль директоры

Хөрмәтле Фәрит Гертович!
«Уфаоргсинтез» ГАҖ коллективы исеменнән Сезне 50 яшьлегегез белән котлыйм!
Безнең предприятиеләр һәрвакытта да хезмәттәшлекнең күркәм традицияләре белән аерылып торды. Без охшаш продукция җитештерәбез, бер үк төрле каршылыклар һәм проблемалар белән очрашабыз. Бу исә бер-беребезне яхшырак аңларга ярдәм итә.
Бүгенге истәлекле көндә Сезгә бетмәс-төкәнмәс күңел күтәренкелеге һәм оптимизм, иртәгәге көнгә ышаныч һәм барлык планнарыгызның тормышка ашуын телибез!
Сезнең гаять зур уңышларыгызга ихлас сөенәбез һәм бәйрәм күтәренкелеген уртаклашабыз. Коллективыгызда хезмәт иткән һәм предприятиенең данлы тарихын үз куллары белән язган ветераннарга аеруча нык сәламәтлек һәм бәхет телибез! Бәхет, иминлек юлдаш булсын Сезгә!

## Профессиональлек һәм тәҗрибә югары бәягә лаек

**Вячеслав Моряков,**
«Эко М» ЖЧҖ генераль директоры

Хөрмәтле Фәрит Гертович!
«Эко М» ЖЧҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне истәлекле көнегез белән тәбрик итәм.
Нефть химиясе үсешенә керткән өлешегез хөрмәткә һәм бәяләүгә лаек. Профессиягезнең бөтен нечкәлекләрен Сез үз тәҗрибәгездә өйрәндегез. Смена башлыгы, әйдәп баручы инженер һәм, ниһаять, Россиянең әйдәп баручы компанияләренең берсендә генераль директор булу – Сез үткән юлдагы озак еллык киеренке хезмәтнең лаеклы нәтиҗәсе ул.
Профессиональлегегез һәм тәҗрибәгез Сезгә алдыгызга куелган бурычларны уңышлы үтәргә мөмкинлек бирә, «Казан Оргсинтез» ГАҖ эшчәнлеге нәтиҗәләре югары бәягә лаек булып тора.
Максатчанлыгыгыз, оештыру сәләтегез һәм югары җаваплылык белән эшләвегез предприятиегә алга таба да Россия химия сәнәгатенең флагманы булып калуына ярдәм итәчәгенә ышанам.
Сезгә сәламәтлек, профессиональ уңышлар телибез һәм безнең партнерлык мөнәсәбәтләребезнең алга таба да тотрыклы, үзара файдалы булачагына ышаныч белдерәбез.



Реклама

PRESSA.RU

**В. И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ генераль директоры Ронис Нәкыйпович Шәрипов май аенда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.**

## Сез илнең оборона-сәнәгать комплексы үсешенә әһәмиятле өлеш кертәсез

**Рөстәм Абдуллин,** «Радиоприбор» АҖнең башкаручы директоры

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович! «Радиоприбор» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 50 яшьлек юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм.

Бүген Сезгә – талантлы белгеч һәм абруйлы җитәкчегә – олылау сүзләре әйтергә мөмкинлек бирелә торган көн.

Кайда гына эшләсәгез дә, һәркайда алдыгызга югары максатлар куя һәм шуларга ирешә белдегез. Сез – талантлы оештыручы һәм яхшы белемле профессионал, күренекле реформатор. Сез илнең оборона-сәнәгать комплексы үсешенә зур өлеш керттегез.

Тормыш юлыгыз – максатка омтылучанлыкның, хезмәт сөючәнлекнең, теләсә нинди кыенлыкларны һәм киртәләрне җиңеп чыга белүнең менә дигән мисалы. Төп нәрсәне күрә, катлаулы мәсьәләләрне хәл итүгә конструктив якын килә, министрлыклар, ведомстволар һәм партнер предприятиеләр җитәкчеләре белән дөрес, ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыра белүегез Сез җитәкләгән коллективлар алдында торган бурычларны уңышлы үтәп чыгарга һәм илнең оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре җитәкчеләре һәм белгечләре арасында лаеклы абруй казанырга мөмкинлек бирде.

2009 елда Сез «Радиоприбор» АҖ җитәкләдегез һәм эшлекле сыйфатларыгыз, стратегик мәсьәләләрне хәл итүгә оста якын килә белүегез аркасында предприятиене кыска вакыт эчендә икътисадый кризистан чыгара алдыгыз һәм бу аның алга таба үсешенә тиешле шартлар тудырды. Сезнең инициатива белән предприятиене техник яктан кабат коралландыру буенча инвестицион проектлар «2011–2020 елларга РФ ОСК үсеше» федераль максатчан программага кертелде, һәм аларны уңышлы тормышка ашыру бүген дә дәвам итә. Җитештерелә торган продукциянең исемлеген яңарту, производствоны модернизацияләү һәм борт радиоэлектрон аппаратурасының яңа буынын эшләп чыгаруны үзләштерү процессы башланды. Сезнең җитәкчелек астында предприятиенең уңышлы эшчәнлек алып баруы «Радиоприбор» АҖнә илнең радиоэлектрон тармагында әйдәп баручы предприятиеләрнең берсе буларак үз позицияләрен ныгытырга мөмкинлек бирде.

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович! Сез «Радиоэлектрон технологияләр» Концерны генераль директорының беренче урынбасары һәм В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ генераль директоры булып эшләгән чорда предприятиебезгә ярдәм итүегез өчен аеруча рәхмәтлебез.

Сез нык холкыгыз, үз көчегезгә ышануыгыз, зирәклегегез, стратегик фикер йөртә белүегез, гаять зур энергиягез һәм эрудициягез белән аерылып торасыз. Хезмәт юлыгыз озын – прокуратура органнарындагы җитәкчелек эшендә зур тәҗрибә тупладыгыз, Татарстан Республикасының дәүләт милке белән идарә итү буенча Дәүләт комитетының хокук идарәсен җитәкләдегез, Татарстан Республикасының бурычларны түли алмау һәм финанс хәлен тәртипкә салу эшләре буенча комитет рәисе урынбасары, «Казан оптика-механика заводы» ААҖ генераль директоры, Амур өлкәсе хөкүмәтендә милек мөнәсәбәтләре, табигать ресурслары һәм урман хуҗалыгы министры, соңыннан Амур өлкәсе хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары булып эшләдегез. Фидакарь хезмәтегез, сайлаган профессиягезгә тугрылыгыгыз өчен олы исемнәргә һәм хөкүмәт бүләкләренә лаек булдыгыз: «ТРның атказанган машина төзүчесе», РФ Президентының Рәхмәт хаты, ТРның «Фидакарь хезмәт өчен» медале, «Ел җитәкчесе – 2015» конкурсының «Фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм проект эшләрен керткән өчен» номинациясендә җиңүче, «Казанның 1000 еллыгы хөрмәтенә» медале, РФ ОМның «Сугышчан дуслыкны ныгыткан өчен» медале. Сез Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Казан шәһәр Думасының беренче чакырылышына депутат булып сайландыгыз, анда социаль-икътисадый үсеш һәм муниципаль милек комиссиясен җитәкләдегез.

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович, Сезгә нык сәламәтлек, профессиональ эшчәнлегегездә яңа уңышлар, планнарыгызның тормышка ашуын телибез.

Йортыгыз шатлык-куаныч һәм бәхет белән тулып торсын, хезмәттәшләрегезнең, якыннарыгызның һәм туганнарыгызның ярдәме һәр эшегездә ышанычлы таяныч булсын. Юбилеегыз белән Сезне!

Реклама

**Андрей Гурьянов,**
П.А.Ефимов исемендәге «Электроавтоматика» ТКБ» АҖ генераль директоры

## Авиация сәнәгатенә – 75!

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

П.А. Ефимов исемендәге «Электроавтоматика» ТКБ» АҖ коллективы исеменнән сезне күренекле дата – «Радиоприбор» АҖ төзелүнең 75 еллыгы белән тәбрик итәм.

Илебез авиация сәнәгате тарихында 75 ел – зур хөрмәт казанырлык дата ул. Бөек Ватан сугышы елларында да, аннан соң да туган илебез күген саклаган самолетларның төзелешендә нәкъ менә шушы предприятие җитештергән җиһазлар була бит. Эшләнмәләрнең, авиация радиотехникасы системаларын һәм комплексларын, борт исәпләү системаларын сериялэп җитештерү һәм хезмәт күрсәтү яңа технологияләр үзләштерүне һәм гамәлдәгеләрен үстерүне таләп итә торган югары техник катлаулылык белән аерылып тора. Һәм һәрвакыт алга куелган бурычларны сезнең коллектив намус белән башкарды.

Бу күркәм көнне «Радиоприбор» АҖ хезмәткәрләренә һәм аларның гаиләләренә бәхет, сәламәтлек һәм аяз күк йөзе телибез.

Форсаттан файдаланып, Ронис Нәкыйпович Шәриповны да 50 яшьлек юбилее белән котларга телим. Сезгә сәламәтлек, уңышлар, барлык максатларыгызның тормышка ашуын телим! Һәрвакыт һәм һәркайда уңышлар юлдаш булсын!

Бу тантаналы көндә авиация хакына намуслы хезмәт итүегез өчен олы рәхмәтебезне кабул итегез! Янәшәгездә һәрчак тугры дусларыгыз һәм ышанычлы партнерларыгыз булсын! Сезгә иҗади идеяләр, киң мөмкинлекләр һәм перспективалы проектлар телибез!

**Павел Будагов,**
«Рязань дәүләт приборлар заводы» АҖ генераль директоры

## Ил бәхете өчен алгарыш белән бергә атлау

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович!

«Рязань дәүләт прибор заводы» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм! Нык сәламәтлек, бәхет, иминлек һәм күңел күтәренкелеге телим!

Эш дәверендә Сез үзегезнең мөмкинлекләрегезне, талантыгызны, җәмгыять һәм ил мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә омтылуыгызны тулысынча тормышка ашырыга ирештегез. Эшлекле, төпле һәм эшкә нык бирелгән булуыгыз, һичшиксез, яңа профессиональ казанышларга ирешергә, шулай ук Сез җитәкли торган, быел нигез салынуының 75 еллыгын билгеләп үтүче предприятиенең алга таба да динамик үсешенә ярдәм итәр.

«Радиоприбор» АҖ данлы хезмәт юлы узды. Һәм бүген Сезнең оста җитәкчелегегез, шулай ук бердәм хезмәт коллективының тырышлыгы, заманча җиһазлар куллану һәм яңа технологияләр кертү аркасында предприятие алгарыш белән бергә атлый һәм хәрби, гражданлык һәм җитештерү-техник юнәлештәге югары сыйфатлы продукция эшләп чыгара.

Предприятиенең еллар дәвамында тупланган тәҗрибәсе һәм зур җитештерү потенциалы Казан прибор төзүчеләренә яңа казанышларга ирешергә ярдәм итәр, дип ышанам.

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович, Сезнең барлык башлангычларыгызда уңышка ирешүегезне, якыннарыгызның, хезмәттәшләрегез һәм фикердәшләрегезнең җылысын тоеп яшәвегезне телибез, туган ил бәхете өчен хезмәт итүдә бетмәс-төкәнмәс иҗади энергия һәм илһам һәрчак юлдаш булсын!

PRESSA.RU

**Камо Абрамян,**
«Техприбор» ГАЖ
генераль директоры

## Масштаблы проектлар – масштаблы җитәкчеләргә!

Оборона-сәнәгать комплексы продукциясе җитештерүче предприятие җитәкчесенең җаваплылыгы икеләтә югары. Ул вазыйфасы буенча йөкләнгән бурычлар белән генә түгел, илнең оборона-сәнәгать системасында һәр заводның нинди стратегик роль уйнавы белән дә билгеләнә. Моннан тыш, әлеге төр предприятиеләр югары технологик продукция җитештерүгә нигезләнгән сәнәгать тармакларының үсеш дәрәҗәсен һәм тизлеген билгели.

Сезнең производствоны техник яктан кабат коралландыру, инновацион технологияләр кертү (шул исәптән, «тыныч» тармакларга да), хәрби һәм гражданлык юнәлешендәге авиация өчен радиоэлектрон аппаратура җитештерүдә «Радиоприбор» заводы кебек мөһим звенода сыйфат менеджменты системасын тулысынча модернизацияләү белән бәйле уңышларыгыз – югары дәрәҗәдәге идарә итү осталыгы үрнәге.

Киң колачлы проектлар киң фикерләү дәрәҗәсенә ия җитәкчеләргә генә буйсына. Генераль директор вазыйфасына керешкәч, кыска гына вакыт эчендә Сез предприятиедә реновация процессын башлап җибәрдегез. Авиация навигациясе һәм радиолокация комплекслары, борт исәпләү системалары, махсус юнәлештәге җир өсте радиоэлектрон җиһазлары, автомобиль сәнәгате өчен узеллар һәм детальләр эшләү һәм аларны сериялап чыгару һәм хезмәт күрсәтү җайга салынды.

Реклама

Бүген «Радиоприбор» АҖ «Радиоэлектрон технология концерны» АҖ составына керә һәм очу аппаратлары өчен радиоэлектрон җиһазлар эшләүче төп белгечләр белән актив хезмәттәшлек итә, шулай ук Россиянең барлык әйдәп баручы авиатөзелеш конструкторлык бюролары белән фәнни-җитештерү өлкәсендә тыгыз элемтәдә тора.

Радиоэлектроника сәнәгатенең иң өлкән предприятиеләренең берсе үзенең 75 еллыгын лаеклы каршыласын өчен, Сез үзегездән зур өлеш керттегез.

Әмма кадрлар белән бәйле мәсьәләләрне тирәнтен аңламасаң, үзара ярдәмләшү һәм хөрмәт итешүгә нигезләнгән бердәм коллективны оештыра белмәсәң, идарә итү осталыгының югары баскычында торып калып булмый. Без Сезне предприятиедә килеп чыга торган һәр мәсьәләгә игътибар итә торган яхшы җитәкче буларак беләбез. Шундый ук аңлашып эшләүне, үзара ярдәмләшүнең иң нәтиҗәле юлларын табарга әзер булуыгызны Сез партнер предприятиеләргә карата да күрсәтәсез.

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович! ОСК предприятиеләре башында Сезнең кебек тәҗрибәле, максатка омтылышлы, профессионалларның иң яңа һәм кыйммәтле эшләнмәләрен тормышка ашырырга тырышучы җитәкчеләр тору ил өчен нык әһәмиятле булган әлеге тармак үсешенә гаять зур өлеш кертә. «Техприбор» ГАЖ коллективы исеменнән Сезгә бетмәс-төкәнмәс көч, эшлекле партнерларыгызның ышанычлы һәм тотрыклы булуын, яңа профессиональ югарылыкка ирешүегезне телим. Һәрвакыт яхшы кәеф һәм иҗади күтәренкелек юлдаш булсын. Юбилеегыз белән Сезне!

**Николай Воронов,**
«Фрунзе исемендәге ТНФҖБ» АҖ генераль директоры

## Яңа казанышларга таба!

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович! «М.В.Фрунзе исемендәге Түбән Новгород фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 50 яшьлегегез белән тәбрик итәм!

Сезнең тормыш юлын күп кенә уңышлы эшләр, бай профессиональ тәҗрибә, шәхси казанышлар, туктаусыз алга омтылу тәшкил итә. Бу күренекле датага тормышка ашырылган проектлар һәм идеяләр багажы белән киләсез.

Сез көчле ихтыярлы, искиткеч оештыру һәм идарә итү сәләтенә ия, абруйлы һәм инновацион фикер йөртә белүче кеше буларак аерылып торасыз. Безнең предприятиеләрнең үзара хезмәттәшлек итү тарихы Сезнең намуслы, принципиаль һәм максатка омтылышлы җитәкче икәнлегегезне раслады.

Россия оборона комплексының ике әйдәп баручы предприятиесе – «В. И. Шимко исемендәге «Радио-электроника ФҖБ» АҖ һәм «Радиоприбор» АҖ җитәкчесе буларак, Сез дәүләт тануының заманча системаларын һәм чараларын эшләү һәм җитештерү буенча фәнни-җитештерү кластеры төзү өлкәсендә гаять әһәмиятле эш башкарасыз.

Быел «Радиоприбор» үзенең 75 еллыгын билгеләп үтә. Бүген завод – динамик төстә үсә баручы, оборона-сәнәгать комплексының федераль максатчан программалары буенча дәүләт заказын үтәүдә актив катнашучы предприятие. Легендар тарихы булган завод региональ һәм федераль дәрәҗәдәге югары статуска ия, һәм бу күп яктан Сезнең тырышлык нәтиҗәсе.

Ронис Нәкыйпович, 50 яшь тулган көнегездә Сезгә яңа профессиональ казанышлар, энергия һәм рух күтәренкелеге телибез! Һәрвакытта да гаилә җылысын, якыннарыгызның мәхәббәтен һәм кайгыртучанлыгын тоеп яшәгез!

«Радиоприбор» АҖ коллективына тотрыклылык, иминлек һәм яңа проектлар телибез, нәтиҗәле хезмәттәшлегебез өчен рәхмәт белдерәбез!

Реклама

## Яңа уңышлар һәм зур планнар Сезгә!

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович!

«Радиоприборснаб» АҖ Сезне 50 яшьлегегез белән тәбрик итә һәм бу юбилей елында өметләрегезнең, яңа уңышларыгызның һәм зур планнарыгызның тормышка ашуын тели!

Радиоэлектроника продукциясе җитештерүдә махсуслашкан күп кенә предприятиеләрне саклап калу өчен, Сез күп эшләдегез. Ул предприятиеләрнең берсе – «Радиоприбор» АҖнә быел 75 ел тула. Җитәкче булып эшли башлау белән, Сез кыска гына вакыт эчендә завод эшчәнлегенең үзенчәлегенә төшенә һәм алда торган мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл итә алдыгыз.

Фәнни-җитештерү концерны җитәкчесе буларак, Сезнең эшчәнлек хәрби-сәнәгать комплексындагы төбәк предприятиеләренең фәнни-инновацион потенциалы башка предприятиеләр үсеше өчен таяну ноктасы булуына ярдәм итә. Шул рәвешле, сәнәгать секторы үсешенең чимал моделе акрынлап югары технология моделе белән алыштырыла. Бу барлык базарда катнашучылар, шул исәптән «Радиоприборснаб» АҖ өчен дә әһәмиятле. Безнең компания белән уңышлы һәм нәтиҗәле хезмәттәшлек алга таба да дәвам итәр, дип ышанабыз!

Хөрмәтле Ронис Нәкыйпович! Сезне юбилеегыз белән котлыйбыз һәм ихлас күңелдән нык сәламәтлек, уңышлар һәм яңа максатларга ирешүегезне телибез!

**Ихтирам белән, «Радиоприборснаб» АҖ коллективы**

Реклама

PRESSA.RU





# ФЕДЕРАЛЬ МАСШТАБТАГЫ ҖИТӘКЧЕ

**Борис Тихомиров – «Казан Гипронииавиапром» АҖ генераль директоры – май аенда үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.**

Әлеге проект институтын Борис Иванович инде 1988 елдан бирле җитәкли, һәм авыр 90нчы елларда да предприятиенең үз эшен дәвам итүе – нигездә аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Гарантияләнгән авиация заказы юкка чыккач, җитәкчегә компаниядә квалификацияле белгечләрне саклап калу өчен гаять зур көч куярга туры килә. Тихомировның идарә итү сәләте аркасында, институт озак елларга үсешен дәвам итә алды. Нәтиҗәдә «Казан Гипронииавиапром» гражданлык проектлаштыруында федераль масштабта яңгырый торган үз исемен булдырды.

Борис Тихомировның казанышлары күптөрле бүләкләр белән билгеләп үтелде, алар арасында икенче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены, фән һәм техника өлкәсендәге ТР Дәүләт премиясе бар.

**Илшат Гафуров,** Татарстан Республикасы ректорлары Советы рәисе, Казан федераль университеты ректоры

## Сезнең идеяләр һәм проектлар – тармак драйверы

Хөрмәтле Борис Иванович! Сезне 70 яшьлек юбилеегыз белән ихлас күңелдән котлыйбыз!

Предприятие – аның җитәкчесенең «йөзе». Озак еллар Сез җитәкли торган «Казан Гипронииавиапром» АҖ – Россиянең сәнәгать һәм гражданлык объектларын һәм производстволарын проектлау өлкәсендә һәрвакыт югары стандартлар бирүче иң яхшы проект институтларының берсе. 90нчы елларның авыр икътисадый шартларына карамастан, Сез институт үсешенә яңа сулыш өрә, эшкә тармакның иң яхшы кадрларын тарта, республика проектлаштыру сферасын чын мәгънәсендә яңа дәрәҗәгә күтәрә алдыгыз.

Сездәге энтузиазм, проектларның киләчәген күрә белү сәләте, инновацион технологияләрне өйрәнергә һәм кулланырга әзер тору институтка үз өлкәсендә чын драйвер булырга мөмкинлек бирде. Бүген аның белгечләре Татарстанның иң эре һәм әһәмиятле объектлары өстендә эшли. Соңгы елларда «Казан Гипронииавиапром» АҖ хезмәткәрләре башкарган иң яхшы эшләр арасында «Алабуга» МИЗ, Универсиада объектлары, Иннополис инновацион шәһәре һәм күп кенә башка проектлар бар. Институт проектчыларының В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе планетарие кебек зур күләмле, катлаулы, фәнни, мәдәни һәм тарихи кыйммәткә ия булган объект, шулай ук А.М. Бутлеров исемендәге Химия институтының яңа бинасы проекты өстендә уңышлы эшләүләрен дә билгеләп үтмичә кала алмыйм.

Хөрмәтле Борис Иванович! Сирәк очрый торган шәхси сыйфатларга ия булган чын профессионал, үз коллективын рухландыра белүче һәм шуның белән янадан-яңа уңышларга ирешүче җитәкче буларак, Сезгә ихлас ихтирамыбызны белдерергә рөхсәт итегез. Эшчәнлегегез һәрвакытта да күркәм нәтиҗәләргә китерсен! Бәхет, сәламәтлек, уңышлар юлдаш булсын Сезгә!

Реклама

Андрей Лобов

# БАШКАЛА ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ МЕНЕДЖЕР

**Андрей Лобов Татарстан башкаласының иң эре территориаль берәмлеген – Казанның Вахитов һәм Идел буе районнары хакимиятен җитәкли.**

Андрей Николаевич ведомствосындагы территория, чыннан да, уникаль. Вахитов районы – Казанның төп тарихи-мәдәни, фәнни һәм белем бирү урыны, ә Идел буе районы – шәһәрнең эре торак һәм сәнәгать массивы.

Андрей Лобов, нәтиҗәле эшчәнлеге һәм Казанның социаль-икътисадый үсешенә лаеклы өлеш кертүе өчен, ТР Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән. Май аенда «район менеджеры»на 45 яшь тула.

**Владимир Гинсбург,** «Казан электротехника заводы» ГАҖ генераль директоры

## Шәһәребез хакына яңа җиңүләр һәм казанышлар насыйп булсын!

Хөрмәтле Андрей Николаевич! Казан электротехника заводы коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилей көнегез белән котлыйм һәм шәһәребез хакына яңа казанышларга ирешүегезне телим!

Без сезнең җитәкчелек талантыгызга һәм эштәге профессиональлегегезгә ихлас хөрмәт белән карыйбыз. Абруегыз, хезмәт сөючәнлегегез, иҗади энергиягез һәм максатчанлыгыгыз аркасында, Казанның иң эре ике районы көн саен диярлек үзгәреш кичерә. Җаваплылыгызның зурлыгын һәм иң катлаулы мәсьәләләрне уңышлы хәл итә белү осталыгыгызны белгән хәлдә, безнең төрледән-төрле проблемаларыбызны аңлавыгыз өчен, чиксез рәхмәтлебез. Сез – туган шәһәребез бәхете өчен иҗади эшли белә торган кеше.

Андрей Николаевич, үзара ярдәмләшеп яшәвебезне без югары бәялибез һәм алга таба бу элемтәбез тагын да ныгыр һәм үсәр, дип ышанабыз. Тормышыгыз туган йорт җылысы, дустанә аралашу шатлыгы һәм рухи гармония белән тулып торсын. Ныклы сәламәтлек, бәхет, иҗади уңышлар һәм иминлек телибез!

Реклама

PRESSA.RU

**Рөстәм Габделхаков,**
«Казэнерго» АҖ генераль директоры

# Туган шәһәребез бәхете өчен

Хөрмәтле Андрей Николаевич! «Казэнерго» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 45 яшьлек юбилеегыз белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Менә биш ел инде Сез Вахитов һәм Идел буе районнары хакимиятен җитәклисез. Шушы вакыт эчендә үзегезне актив гражданлык позициясенә һәм стратегик фикер йөртү сәләтенә ия булган эшлекле һәм җаваплы җитәкче итеп таныттыгыз.

Без Сезне чын профессионал, тәҗрибәле хуҗалыкчы, командасына югары классны белгечләр тарта һәм аларны шәһәрлеләр тормышын яхшыртуга юнәлтелгән проектларны тормышка ашыру өчен мобилизацияли ала торган лидер буларак беләбез. Бу озак еллык уртак эшебез мисалында аеруча ачык күренә. Казанлыларны ышанычлы, сыйфатлы һәм отышлы формада җылылык, җылылык энергиясе һәм кайнар су белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү кысаларында, соңгы берничә ел эчендә «Казэнерго» АҖ һәм Вахитов һәм Идел буе районнары хакимияте тарафыннан социаль әһәмияткә ия булган күп кенә уртак проектлар тормышка ашырылды. Әйтик, 2014 елның ноябрендә «Соловьиная роща» торак комплексының кабат төзелгән пар казаннары бинасы файдалануга тапшырылды. Үзгәртеп кору һәм яңарту юлы белән ул биналарга социаль ипотека буенча төзелгән уннарча йорт, шулай ук Универсиада комплексы объектлары тоташтырылды, физик һәм мораль яктан тузган пар казаннары биналары үзгәртеп корылды. 2015 елга расланган үзгәртеп кору һәм ремонтлау планына ярашлы рәвештә һәм район хакимиятенең ярдәме белән, РКБ-1 перинаталь үзәгенең пар казаннары бинасын үзгәртеп кору буенча эш башланды. Кайнар су белән тәэмин итүче традицион челтәрләрне полимер материалдан

эшләнгән үткәргеч торбаларга алыштыруны күздә тотучы кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен яңарту программасы кебек киң колачлы һәм перспективалы проектларны тормышка ашыру да безнең предприятие һәм Вахитов һәм Идел буе районнары хакимиятенең уртак эше булды.

«Казэнерго» АҖ район хакимиятенең һәм Сезнең, Андрей Николаевич, Вахитов һәм Идел буе районнары территориясендәге проектларыбызда компаниябезгә ярдәм итүегезне югары бәялибез. Үзара партнерлык мөнәсәбәтләребез белән горурланабыз һәм уртак эшебез шундый ук рухта дәвам итәр, дип ышанабыз.

Хөрмәтле Андрей Николаевич! «Казэнерго» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Барлык башлангычларыгызның коллегаларыгыз, туганнарыгыз һәм якыннарыгыз тарафыннан хуплануын телибез. Яңа җиңүләр һәм уңышлар юлдаш булсын Сезгә!

Реклама

**Джавидин Кафаров,**
«Знче Казан икмәк заводы» ААҖ генераль директоры

## Алга барырга һәм беркайчан да бирешмәскә!

Хөрмәтле Андрей Николаевич! «Знче Казан икмәк заводы» ААҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән иң изге котлауларыбызны һәм теләкләребезне кабул итегез! Юбилей – үткәннәргә йомгак ясау һәм алга чираттагы мөһим бурычлар кую өчен бер сәбәп ул. Шушы вакыт эчендә Сез күпме юл үткәнсез, күпме изге һәм файдалы эш башкаргансыз! Ә иң мөһиме – актив тормыш позициягез һәм җәмгыятькә файда китерү омтылышыгыз кимемәгән. Алга таба да эзлекле хәрәкәт итүегезне һәм беркайчан да бирешмәвегезне телисе килә. Янәшәгездә һәрчак кыен чакларда ярдәмгә килергә әзер торучы яхшы кешеләр булсын! Районнарыбыз һәм шәһәребез үсеше хакына акыллы карарлар кабул итү сәләтегез кимемәсен. Хөрмәтле Андрей Николаевич! Безнең заман – дөрес карарлар чыгару һәм җаваплы эшләр башкару чоры. Шуңа күрә максатка омтылучанлыгыгыз һәм киләчәк өчен эшләргә теләвегез иң кыю проектларны тормышка ашырырга ярдәм итсен. Тормышыгыз коллегаларыгызның хөрмәте һәм ярдәме, туганнарыгызның һәм якыннарыгызның мәхәббәте һәм җылысы белән тулып торсын. Юбилеегыз белән Сезне!

**Лев Семёнов,**
«Казан ярминкәсе» ААҖ генераль директоры

## Эшегездә уңыш юлдаш булсын!

Хөрмәтле Андрей Николаевич! «Казан ярминкәсе» ААҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән туган көнегез белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Изге хыялларыгыз тормышка ашсын, ә тормыш юлыгызда очрый торган киртәләрне җиңел кичәргә насыйп булсын һәм алар бары тик яңа көч һәм зирәклек кенә өстәсен!

Сез яшьлек энергиясе белән җитлеккән кеше тәҗрибәсен берләштергән яшькә җиттегез. Күңел күтәренкелеге һәм рухи көч, тирән белем һәм күнекмәләр белән бергә кушылып, дөрес карарлар кабул итәргә булышсын. Профессиональ өлкәдәге уңышларыгыз – көндәлек фидакарь хезмәт, югары таләпчәнлек, холкыгызның ныклыгы нәтиҗәсе ул. Сез стратегик фикер йөртү, позитив энергетика, вакытында конструктив карарлар кабул итү белән аерылып торучы заман җитәкчесен гәүдәләндерәсез. Нәкъ менә Сезнең кебек кешеләр иртәгәге көнгә ышаныч тудыра, иң кыю ният һәм идеяләрнең үтәлүенә өмет уята.

Хөрмәтле Андрей Николаевич,чын күңелдән Сезгә һәм гаиләгезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телим! Эшләрегез һәрчак уңсын, ә йортыгыз ашлы-сулы булсын! Барлык кылган яхшылыкларыгыз үзегезгә икеләтә артып кайтсын! Сезгә һәм якыннарыгызга исәнлек-иминлек һәм яхшы кәеф телим!

PRESSA.RU

# «ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ КАЙЛАРДА САТЫЛА

## КАЗАН

**МЕЛЬНИКОВ ШЭ**

*«ЭДЕЛЬВЕЙС»*
Павлов ур., 23
Ибраһимов пр., 1
Чуйков ур., 38
Ямашев пр., 54
Голубятников ур., 21 а
Әмирхан пр., 41
Адоратский ур., 12
Мусин ур., 61 б
Гаврилов ур., 33
Адоратский ур., 11 а
Әмирхан пр., 97
Н. Назарбаев ур., 9/2
Восстание ур., 56
Фучик ур., 30 а
Сәфиуллин ур., 40
Зайцев ур., 10
Максимов ур., 4 а
Кошевой ур., 6
Октябрьнең 40 еллыгы ур., 4
Магистраль ур., 77
Мамадыш тракты, 36 а
Фучик ур., 72
Павлюхин ур., 101
Оренбург тракты, 138 а
Ломжа ур., 2 а
Н. Назарбаев ур., 54
Сәлимҗанов ур., 16
Универсиада пр., 16

*«ПЯТЁРОЧКА»*
Декабристлар ур., 8
Копылов ур., 5/1
Дежнев ур., 2
Һади Такташ ур., 123
К. Цеткин ур., 13
Җиңүнең 40 еллыгы ур., 6 а
(Осиново)
Губкин ур., 44
Кызыл Позиция ур., 9

*«ПЕСТРЕЧИНКА»*
Авангард ур., 54
Декабристлар ур., 184
Энергетиклар ур., 3
Краматорская / Лушников ур., 6
Латыш Укчылары ур., 25
Меридиан ур., 11
Юдино, Красиков ур., 11
Социалистик ур., 7

*«БӘХЕТЛЕ»*
Мәүлетов ур., 45
Павлюхин ур.
Әмирхан пр.
Оренбург тракты

*«БОСФОР»*
Миславский ур., 9

*«МАГНИТ»*
Әмирхан пр., 97
Фучик ур., 49
Татарстан ур., 18
Зорге ур., 33
Ибраһимов пр., 61

*«АЗИНО» СК*
Фучик ур., 155

*7НЧЕ ШӘҺӘР ХАСТАХАНӘСЕ*
Ямашев пр.

*КИОСКЛАР*
Совет ур., 22
Ямашев пр., 54
Гадел Кутуй ур., 24/31
Татарстан ур., 18
Б. Шаһиди ур., 1
Себер тракты, 8
Мәүлетов ур., 9
Чехов ур., 8
«Петрушкин двор» тукталышы
Ломжа ур., 24
Солидарность ур., 4
Шаляпин ур., 9
Әмирхан пр. / Чуйков ур., 71
Юдино, Бирюзовая ур.
Ленинград ур., 32
Парин ур., 6
Фучик / Зорге ур., 34
Курчатов ур., 2
Максимов ур., 1
Адоратский ур., 12
Губкин ур., 48
Сәфиуллин ур., 40
Тула / Авангард ур.
Кол Гали ур., 11/52 а

**«МИР ПРЕССЫ – РЕГИОН» ҖЧҖ**

*«ДЕЙЛИ» КИБЕТЛӘРЕ*
К. Маркс ур., 59
Н. Ершов ур., 78
Зорге ур., 93
«Тукай мәйданы» метро станциясе
Н. Ершов ур., 1 а («Корстон»)
«Горки» метро станциясе
Белинский ур., 4
«Җиңү проспекты» метро станциясе
Чуйков ур., 69
Парк ур., 6
Короленко ур., 81
Фрунзе ур., 5
Мусин ур., 68 б
Лаврентьев ур., 9
Даурия ур., 40

**«ТАТАР КИТАП НӘШРИЯТЫ» ТР ДУП**
Декабристлар ур., 2
Бауман ур., 19
Бауман ур., 29/11

**«ГОРПЕЧАТЬ» ЯАҖ**
Фрунзе ур., 7
Пушкин ур., 2
Сахаров ур., 13
Межлаук ур., 15
Ямашев пр., 49
Вишневский ур., 2
Н. Назарбаев ур., 47
Н. Назарбаев ур., 63
Восстание ур., 83
Кави Нәҗми ур., 7
К. Цеткин ур., 17/20
Восстание, 23 / Декабристлар ур.
Копылов ур., 5/1
Адоратский ур., 29
Максимов ур., 34/24
Липатов ур., 5
Достоевский ур., 74 а
Себер тракты, 7
Декабристлар ур., 189
Татарстан ур., 72
Даурия ур., 36
Даурия ур., 23
Автовокзал
«Казан Оргсинтез»
Горький шоссесы / Можайский ур.
Н. Ершов ур., 53
Кошевой ур., 16
Декабристлар ур.,178 а
Восстание ур., 56
Айдаров ур., 8 а
Окольная ур., 23
Себер тракты, 34
Декабристлар ур., 102
Челюскин ур., 31
Краснококшайская ур., 164
Максимов ур., 4
Ш. Усманов ур., 12
Гвардейская ур., 42
Батыршин, 16 / Коләхмәтов ур.
Революция ур.
Ильич ур., 30
Попов ур., 7
Беломорская ур., 73
Газовая ур., 9
Декабристлар ур., 115
Н. Назарбаев ур., 35
Черноморская ур., 3
Восстание ур., 6
Калинин ур., 73
Мәүлетов ур., 17
Гагарин ур., 22
Гагарин ур., 12
Халитов ур., 34 ж
Белинский ур., 9
Фучик ур., 72
Тынычлык ур., 33
Карбышев ур., 13
«Океан»
Чуйков ур., 38
Н. Ершов ур., 32
Гвардейская ур., 38
Чехов ур., 6
Халезов ур., 21
(Дәрвишләр бистәсе)
Короленко ур., 89
Декабристлар ур., 150

**«ТАТАРСТАН ПОЧТАСЫ» ФПЭИ ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ**
Сахаров ур., 27
Мәүлетов ур., 9
Забайкальская ур., 3
Маршал ур., 25
Һ. Такташ ур., 75
Мехчылар ур., 3
Бауман ур., 37
Меридиан ур., 14
Әмирхан пр., 10 а
Максимов ур., 2
Салмач, Тынычлык ур., 6 а
Адоратский ур., 29 а
Адоратский ур., 12
Мусин ур., 68
Гаврилов ур., 40
Җиңү пр., 17
Ю. Фучик ур., 34
Кремль
Нокса авышлыгы, 1
К. Маркс ур., 44
Яңа аэропорт
Татарстан ур., 11
К. Цеткин ур., 33
Фрунзе ур., 1
Айдаров ур., 22
Декабристлар ур., 191
Юбилей ур., 1/43
Вишневский ур., 14
Волгоград ур., 22
Шатура ур., 155
Качалов ур., 95
«Оргсинтез» заводы
Беломорская ур., 1
Карьер, Нокса ур., 29
Мирный, Яңа Дәүләкәй ур., 16 а
Нагорный, Круговая ур., 12
Павлюхин ур., 116
Рәхимов ур., 33
Ирек мәйданы, 1
Черноморская ур., 3
Петровск, Үзәк ур., 1
Тынычлык ур., 45
Гвардейская ур., 42
Яңа Юдино ур.,140
Красиков ур., 8
Завокзальная ур., 57
Альберт Камалиев ур., 12
Беломорская ур., 73
Зур Урам, 11
Я. Гашек ур., 1
Дәрвишләр бистәсе,
Краевая ур., 8 а
Товарищеская ур., 28/70
Б. Заречная ур., 22
Кадыш, Калинин ур., 1
Кремль
Оренбург тракты

# БЕЗНЕҢ БЕЛӘН БЕРГӘ
# БУ САННЫ ЭШЛӘДЕЛӘР:

– БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ КАҺАРМАННАРЫ

– МЕНДЕЛЕЕВСКИДАГЫ «АММОНИЙ» ИНЖЕНЕР-ХИМИКЛАРЫ

– ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ЮГАРЫ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕНӘ ЛАЕК БУЛГАН ХЕЗМӘТ ВЕТЕРАНЫ

– АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ СӘНГАТИ ТУКУ ФАБРИКАСЫ ТУКУЧЫЛАРЫ

– РЕСПУБЛИКА ЭШКУАРЛАРЫ ҺӘМ РУХИ ЛИДЕРЛАРЫ

– ТАТАРСТАН АВЫЛЛАРЫ УКЫТУЧЫЛАРЫ

– ЯШЬ ТАТАР МИЛЛИОНЕРЫ

– 91 ЯШЕНДӘ ПАРАШЮТНЫ ИЯРЛӘГӘН СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ

– КАЗАНДА ЯШӘҮЧЕ КЫСТЫБЫЙ ПЕШЕРҮ ОСТАСЫ

**ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –**

**«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!**

PRESSA.RU

**«Татарстан» журналына барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин**

Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

**ТАТАРСАНДА ЯШИСЕҢ –**

**«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!**